3˚2019

# ФӘННИ ТАТАРСТАН

ISSN 2499-9741

КАЗАН

*Журнал «2014–2021 елларга Татарстан Республикасында*
*ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү»*
*дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә*

*Массакүләм мәгълүмат чарасын регистрацияләү турындагы*
*таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор,
идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның халык
шагыйре (Казан)
ДӘҮЛӘТ НАДИР, тарих фәннәре докторы, профессор (Истанбул)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
СӘЛАХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор,
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология
һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Мэдисон)

► **БАШ РЕДАКТОР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
ГОМӘРОВ И.Г., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать),
МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият),
ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т., ЛУКЬЯНЧЕНКО Е.Ф.

## БУ САНДА


### ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Миңнуллин К.М., Сәфәров Р.Т.* Татар тел белемендә сүзлекләрнең тоткан урыны һәм тарихи үсеш перспективалары *(дәвамы)* . . . . . 7

*Баязитова Ф.С.* Халык традицияләрендә борынгы төрки һәм этноконфессиональ лексика . . . . . . . . . . . . . . . . . 15

*Пименова М.В. Урда* сүзенең семантик үсеш процессы . . . . . . 24

*Денмөхәммәтова Э.Н., Гәрәева Р.Х.* Кардәш телләргә тәрҗемәләрдә лексик трансформация төрләре . . . . . . . . . . . . 30

*Булатова Ә.К.* Татар телендә семантик диалектизмнар . . . . . . 38

### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Хәбибуллина А.З.* Чагыштырма поэтика категориясе буларак жанр *(рус һәм татар әдәбиятлары мисалында)* . . . . . . . . . . 42

*Мусабәкова Р.Р.* Сәгыйть Сүнчәләй иҗатында музыкага мөнәсәбәтлелек турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53

*Закирҗанов Ә.М.* Т. Миңнуллинның XX гасыр ахыры иҗатында әдәби-эстетик эзләнүләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57

### ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Сәлахова Э.К.* Югары һәм Түбән Мәтәскә авыллары тарихыннан . . 65

*Әхтәмова А.В.* XX гасыр башында Уфа губернасы башлангыч белем мәктәпләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72

### ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Закирова И.Г.* Татар фольклорында Чыңгыз хан образы . . . . . . . 78

*Садекова А.Х.* М.С. Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары» повестенда фольклоризмнар . . . . . . . . . . . . 83

### МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Шәкүрова М.М., Гиниятуллина Л.М.* Мәктәп дәреслекләренең заманча концепцияләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90

### СӘНГАТЬ

*Шкляева Л.М.* XIX гасыр ахыры – XX гасырның беренче яртысында авылда яшәүче татар хатын-кызлары костюмы элементы буларак алъяпкыч бизәгенең стиль үзенчәлекләре *(ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИнең 2014–2018 елларда оештырылган экспедиция материаллары буенча)* . . . . . . . . . . 96

### Г. ИБРАҺИМОВ исем. ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ ОЕШУГА 80 ЕЛ

*Хисамов О.Р.* Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында тел белеме өлкәсендәге тикшеренүләр турында . . . . . . . . . 102

*Рәмиев З.З.* Институт эшчәнлегендә әдәбият белеме мәсьәләләре . 108
*Галимова Э.М.* Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында театр һәм музыка белеме юнәлешендәге фәнни эзләнүләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
*Солтанова Р.Р.* Тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге: хәзерге заман контекстында милли-төбәк сәнгате феномены . . . . 127

**ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ ҺӘМ ТӨБӘКНЕ ӨЙРӘНҮ ИНСТИТУТЫ ОЕШУГА 25 ЕЛ**

*Шәйдуллин Р.В.* Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты тарихы сәхифәләреннән . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137

**ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

*Юсупова Н.М.* Әдәбият белеменең фикер офыкларын киңәйтү юлында *(танылган әдәбият белгече, академик Дания Заһидуллинаның юбилее уңаеннан)* . . . . . . . . . . . 145
*Исхаков Р.Л.* Татар лексикографиясенә өлеш керткән шәхес: Габделхәй Исхаков . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155

**ФӘННИ ЯДКЯРЛӘР**

*Нәҗип Гасрый.* «Хисаметдин менла» *(Акъегетзадә Муса әсәре)* . . 162

**ЯҢА КИТАПЛАР**

*Галимова О.Н.* Э.И. Сафинаның «Татарча-русча-латинча кош атамалары сүзлеге» (Казан: ТӘһСИ, 2018) турында . . . . . . 170
*Ногманов А.И.* «Лашманы в строительстве российского флота: сборник документов и материалов» (Казан: Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2018) китабына рецензия . . . . . . . . . . . 172

**ФӘННИ АЧЫШЛАР ЭЗЕННӘН**

*Ситдыйков А.Г.* Кубрат хан токымнары язмышын ачыклау . . . . 176
*Ризванов А.А.* Күзәнәк ысуллар – кешеләрне дәвалауда . . . . . 177

**ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН**

## В НОМЕРЕ

### ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Миннуллин К.М., Сафаров Р.Т.* Основные этапы развития татарской лексикографии *(продолжение)*. . . . . . . . . . . . . . . . 7
*Баязитова Ф.С.* Древнетюркская и этноконфессиональная лексика в народных традициях . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
*Пименова М.В.* Процесс семантического развития слова *орда* . . . 24
*Денмухаметова Э.Н., Гараева Р.Х.* Виды лексических трансформаций при переводе произведений на родственные языки . . . . . . . . . . 30
*Булатова А.К.* Семантические диалектизмы в татарском языке . . . 38

### ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Хабибуллина А.З.* Жанр как категория сопоставительной поэтики *(на примере русской и татарской литератур)* . . . . . . . . . . . . 42
*Мусабекова Р.Р.* О влиянии музыки на творчесто Сагита Сунчелея . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
*Закирзянов А.М.* Литературно-эстетические особенности творчества Т. Миннуллина конца XX века . . . . . . . . . . . . . 57

### СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Салахова Э.К.* Из истории деревень Верхние и Нижние Метески . . 63
*Ахтямова А.В.* Начальные мусульманские школы Уфимской губернии начала XX века . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72

### НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Закирова И.Г.* Образ Чингизхана в татарском фольклоре . . . . . . 78
*Садекова А.Х.* Фольклоризм в повести М.С. Магдеева «Мы – дети сорок первого года» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83

### НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Шакурова М.М., Гиниятуллина Л.М.* Современные концепции школьных учебников . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90

### ИСКУССТВО

*Шкляева Л.М.* Стилевые особенности декора фартука как элемента народного костюма сельских татар конца XIX – середины XX века *(по материалам экспедиций ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ с 2014 по 2018 гг.)* . . . . . . . . . 96

### ИНСТИТУТУ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА ИМ. Г. ИБРАГИМОВА – 80 ЛЕТ

*Хисамов О.Р.* Об исследованиях в области языкознания в ИЯЛИ имени Г. Ибрагимова АН РТ . . . . . . . . . . . . . . . 102
*Рамеев З.З.* Вопросы литературоведения в деятельности института . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
*Галимова Э.М.* Научные исследования в области театроведения и музыковедения в ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ . . . . . . . 119

*Султанова Р.Р.* Отдел изобразительного и декоративно-прикладного искусства: феномен национально-регионального искусства в контексте современности . . . . . . . . . . . . . . . . . 127

**ИНСТИТУТУ ТАТАРСКОЙ ЭНЦИКЛОПЕДИИ И РЕГИОНОВЕДЕНИЯ – 25 ЛЕТ**

*Шайдуллин Р.В.* Из истории Института татарской энциклопедии и регионоведения . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137

**ПЕРСОНАЛИИ**

*Юсупова Н.М.* Расширяя границы татарского литературоведения *(к юбилею известного литературоведа, академика Дании Загидуллиной)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145

*Исхаков Р.Л.* Габдулхай Исхаков – ученый, внесший вклад в татарскую лексикографию . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155

**НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ**

*Наджип Гасри.* «Хисаметдин менла» *(произведение Мусы Акъегетзаде)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162

**НОВЫЕ КНИГИ**

*Галимова О.Н.* О словаре «Татарча-русча-латинча кош атамалары сүзлеге» (Казань: ИЯЛИ, 2018) Э.И. Сафиной . . . . . . . . . . . . 170

*Нугманов А.И.* Рецензия на книгу «Лашманы в строительстве российского флота: сборник документов и материалов» (Казань: Институт истории им. Ш. Марджани, 2018) . . . . . . . . . 172

**ПО СЛЕДАМ НАУЧНЫХ ОТКРЫТИЙ**

*Ситдиков А.Г.* Судьба потомков Кубрат хана . . . . . . . . . . . . 176

*Ризванов А.А.* Стволовые клетки в лечении людей . . . . . . . . . 177

**НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ**

УДК 811.512.145

***К.М. Миңнуллин,***
***Р.Т. Сәфәров***

# ТАТАР ТЕЛ БЕЛЕМЕНДӘ СҮЗЛЕКЛӘРНЕҢ ТОТКАН УРЫНЫ ҺӘМ ТАРИХИ ҮСЕШ ПЕРСПЕКТИВАЛАРЫ

Статья посвящена основным этапам развития татарской лексикографии. В хронологическом порядке рассмотрены и описаны рукописные и печатные словари татарского языка, определены предпосылки их составления. Отдельно рассмотрена типология наиболее значимых словарей татарского языка, проведена их классификация и описание.

**Ключевые слова:** татарский язык, лексикография, типология словарей, история татарской лексикографии.

The article is devoted to the main stages of the development of Tatar lexicography. The handwritten and printed dictionaries of the Tatar language are reviewed and described in chronological order, the prerequisites for their compilation are determined. The typology of the most significant dictionaries of the Tatar language is considered separately, their classification and description are carried out.

**Keywords:** Tatar language, lexicography, typology of dictionaries, history of Tatar lexicography.

*Дәвамы. Башы алдагы санда.*

Тел белемендә сүзлекләр, төзелү принципларына карап, аерым төркемнәргә аерыла: бер сүзлектә сүзләрнең мәгънәсен аңлату, икенчесендә сүзләрнең килеп чыгышын ачыклау, өченчесендә бер телдәге сүзләрне икенче телгә тәрҗемә итү һәм башка максатлар куелган була. Шул максатларны күздә тотып, төрле-төрле, мәсәлән, аңлатмалы, тәрҗемәле, этимологик, диалектологик, орфографик, орфоэпик һ. б. сүзлекләр төзү гамәлгә кергән.

Телне фәнни яктан өйрәнү тирәнәйгән саен, тел белеменең лексикография тармагы да киңәя, булган сүзлек төрләре яңадан төзелгән саен камилләшә бара, аларның төрләре дә арта тора. Сүзләрнең генә түгел, аның аерым морфемаларының яисә фразеология яки паремияләрнең дә сүзлекләрен төзү көн үзәгенә килеп баса. Лесикография үсеш алган саен, аның фразеография, морфемография һ. б. шундый тармаклары да барлыкка килә. Соңгы елларда бу тармакларны гомумиләштергән *лингвография* атамасы шактый активлашты [Компьютерная лингвография, 1995].

Тел нормаларын саклау чыганакларының берсе буларак, сүзлекләрнең роле торган саен үсә генә бара. Саннары һәм төрләре арту исә сүзлекләрне төрле аспектлардан чыгып төркемләү ихтыяҗын тудыра. Әмма гомуми планда классификацияләү аерым сораулар

тудырмаса да, төрле төрләрне берләштергән белешмәлекләрне, берьюлы берничә функцияне үтәгән сүзлекләрне кайсы төргә кертү һаман да хәл ителеп бетмәгән мәсьәлә булып кала. (Мәсәлән, «Лингвистик терминнарның русча-татарча аңлатмалы сүзлеге» – һәм аңлатмалы, һәм тәрҗемәле сүзлек.)

Тәкъдим ителгән материалда без сүзлекләрне аларның төзелү максатларына карап төркемләүне кулай күрдек. Гомуми классификациядә дә бу – иң зур бүленешләрнең берсе. Кабул итү өчен дә мондый төркемләү авырлык тудырмый дип саныйбыз.

**Аңлатмалы сүзлекләр** телнең сүз һәм мәгънә хәзинәсен, кулланылыш мөмкинлекләрен тулырак күрсәтә торган аерым бер төркемне тәшкил итә. Тулы типтагы аңлатмалы сүзлекләрдә телнең мөмкин кадәр тулы сүз байлыгы һәм аның мәгънә киңлеге аңлатып бирелә. Алай гына да түгел, сүзләр кулланылышындагы төрле мәгънә күчешләре, ул сүз кергән фразеологизмнар һәм аларның мәгънәләре, гомумән сүзнең төп, туры мәгънәсе генә түгел, бәлки күптөрле өстәмә мәгънә төсмерләре дә чагылыш таба. Тулы аңлатмалы сүзлекләрнең үзенчәлекле ягы шунда, аларда сүзнең барлык мәгънәләрен дә барлап күрсәтеп бирергә омтылыш ясала. Бер катлау яисә билгеле бер төркем кешеләргә сүзләрнең бер мәгънәсе билгеле булырга, икенчеләре тарафыннан башка мәгънәсе активрак кулланылырга мөмкин. Сүзләрнең кулланылыштан төшә барган яисә әле яңа гына барлыкка килгән мәгънә функцияләре дә китерелә, ягъни сүзнең мәгънәсе бөтен тулылыгы белән аңлатыла, күпчелек аңлатмалы сүзлекләрдә, иллюстратив материал буларак, мисаллар китерелә.

Аңлатмалы сүзлекләр – халыкның мәдәни үсешенең шаһиты, күрсәткече. Алар сүзлекләр арасында иң дәрәҗәлеләрдән саналалар, лексикография фәненең дә үскәнлеген, алга киткәнлеген күрсәтәләр. Чөнки аларда сүз бөтен яктан тулы тасвирлана ала: язылышы, грамматик характеристикасы, кайбер очракларда килеп чыгышы да күрсәтелергә мөмкин. Шулай итеп, аңлатмалы сүзлекләрдә телнең сүз байлыгы гына түгел, аның күптөрле мөмкинлекләре, семантик арсеналы, үткәне һәм бүгенгесе, үсеш дәрәҗәсе дә чагылыш таба ала. Шуңа күрә әлеге төр сүзлекләр бай, тәҗрибәле, нык үскән лексикография җирлегендә генә төзелә.

Татар тел белемендә аңлатмалы сүзлекләр төзүнең 120 елдан артык тарихы бар. Бу катлаулы да, искиткеч җаваплы да булган өлкәдә беренче тәҗрибәне күренекле галим К. Насыйри башкарган. Ул ике томнан торган «Ләһҗәи татари» дигән аңлатмалы сүзлек төзи һәм аларны 1895 (I том), 1896 (II том) елларда бастырып чыгара. Анда 10 мең чамасы сүз я синонимнарын китерү, я тасвирлау юлы белән аңлатыла. Сүзлекнең зур фәнни-тарихи әһәмияте бар, анда татар теленең шул чордагы сүзлек байлыгының зур өлеше теркәлгән, ул – татар тел белемендә генә түгел, гомумтөрки тел белемендә дә мондый төр сүзлекләргә беренче үрнәк. Төрле юнәлештәге тикшеренүләр алып барганда, телчеләр К. Насыйри сүзлегенә даими рәвештә мөрәҗәгать итәләр.

Татар тел белемендә икенче аңлатмалы сүзлек зур галим, әдәбият һәм тел белгече Җ. Вәлиди тарафыннан төзелә. Ул «Татар теленең тулы сүзлеге» дип атала. Автор хезмәтен күптомлык итеп планлаштырган булса да, аның 1927 һәм 1928 елларда ике кисәктән торган I томы гына басылып чыга. Ни кызганыч, сүзлек зур көч түгеп һәм Казанга килеп укыган башка төбәк татарларын җәлеп итеп, киң катлам лексиканы туплап төзелеп беткән булса да, аның калган томнары сәяси сәбәпләр аркасында бастырылмый. Нәшер ителгән том әлиф, ба һәм та, кириллицага күчергәндә, А, Ә, И, О, Ө, У, Ү, Ы, Э, Б, П, Т хәрефләренә башланган якынча 12 мең сүзне сыйдырган. Анда хәзергә татар телендәге, аның күп кенә сөйләшләрендәге сүзләрне чагылдырган гаять бай материал саклана.

XX гасырның 50 нче елларында Казандагы Тел, әдәбият һәм тарих (хәзер: Тел, әдәбият һәм сәнгать) институтында «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н төзү эше башланып китә. Татар телендә басылган бөтен язма әдәбияттагы барлык сүзләр киң җәмәгатьчелек, мәктәпләр ярдәме белән картотекага салына. Шушы юл белән телебезнең XIX гасыр ахырыннан алып 60 нчы елларны эченә алган чордагы барлык сүз һәм мәгънә байлыгы барлана, 3 миллионнан артык картотека базасы туплана. Бу эш алга таба да сүзлек төзүчеләр тарафыннан зур төгәллек һәм системалылык белән дәвам иттерелә. Мәсьәләне хәл итү юлларын шушы рәвешле дөрес куя белү һәм фәнни, һәм методик яктан гаять югары дәрәҗәдә булган аңлатмалы сүзлек иҗат итүгә бай матди җирлек тудыра, ышанычлы нигез төзи.

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» институт хезмәткәрләре И.А. Абдуллин, Г.Х. Ахунҗанов, С.Б. Вахитова, Ф.М. Газизова, Л.Р. Гайнанова, Ф.А. Ганиев, Р.Р. Мингулова, М.Г. Мөхәммәдиев, Ш.С. Ханбикова, Р.Г. Әхмәтьянов тарафыннан төзелә һәм тәҗрибәле редакторлар коллегиясе Л.Г. Мәхмүтова, М.Г. Мөхәммәдиев, Ш.С. Ханбикова һәм К.С. Сабиров тарафыннан редакцияләнә. Сүзлек өч томнан тора: I томы – 1977, II томы – 1979, III томы 1981 елда басылып чыга. Барлыгы 47 мең сүз һәм тезмә сүзне эченә ала. Анда телебезнең бай сүзлек хәзинәсе барлык грамматик-стилистик билгеләре, киң мәгънә спектры, кулланылыш үзенчәлекләре белән яктыртылган. Сүзләрнең мәгънә эчтәлеген аңлатканда, гаять зур мәгълүмат китерелә. Анда телебезнең тарихи, искергән, диалекталь сүзләре дә урын алган. Сүзлек гаҗәеп мәгълүматлы, чөнки анда турыдан-туры тел өлкәсенә карамаган белешмәләр дә киң чагылыш тапкан.

Туган телебезнең шушындый күп томлы сүзлеген югары дәрәҗәдә, бай эчтәлекле итеп төзеп чыгару, фәнни көчләребезнең сыйфатын һәм мөмкинлекләрен генә түгел, татар тел белеме фәненең дә югары үсешкә ирешүен күрсәтә.

2005 елда әлеге өч томлы аңлатмалы сүзлек нигезендә Ф.Ә. Ганиев җитәкчелегендә һәм редакциясендә бер томлы аңлатмалы сүзлек дөнья күрә. Бертомлык кулланучы өчен шактый кулай итеп эшләнгән, анда, элеккеге сүзлектән аермалы буларак, аңлатмага матур

әдәбияттан үрнәкләр бирү максаты куелмаган. Аның каравы беренче тапкыр тезмә фигыльләр аңлатмасыз гына бирелгән. Сүзлекнең лөгатьлеге 58 мең сүзгә кадәр баетылган. Татарстанның географик атамалары, татар исемнәре һ. б. мәгълүмат кушымта итеп тәкъдим ителгән. Сүзлекне төзүдә өчтомлыкның авторлар коллективы һәм яңа буын лексикографлары катнаша, шуңа күрә әлеге буыннар алмашкан чорда эшләнгән сүзлек алда төзеләсе сүзлек авторлары өчен зур мәктәп тә була.

2010 елда ТӘһСИнең лексикография бүлегендә тагын бер зур хезмәт – «Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге» эшләнеп бетеп, 2013 елда басылып чыга. Бу сүзлек күләм ягыннан кыскарак, куллану өчен уңайлы итеп, мәктәпләр өчен махсус төзелгән. Монда искергән, диалекталь, терминологик сүзләрнең күләме чикле. Ул мәктәп программасы кысаларында укучыларга туган телне үзләштерү, белемнәрен тирәнәйтү өчен ярдәмлек буларак тәкъдим ителә. Башка аңлатмалы сүзлекләр кебек үк, бу белешмәлектән дә татар телендә мәгълүмат алу чыганагы буларак файдаланырга мөмкин.

Аңлатмалы сүзлекләр турында сүз алып барганда, А. Тимергалинның «Миллият сүзлеге»нә тукталмый булмый. Әлеге белешмәлек бертомлык рәвешендә 2007 елда бастырыла, 2016, 2017, 2018 елларда аның тулыландырылган өчтомлыгы дөнья күрә. Бу сүзлек эчтәлеге белән гамәлдә йөри торган аңлатмалы сүзлекләрдән аерыла. Автор 1917 елгы революциягә кадәрге әдәбияттан, фольклор әсәрләреннән, фәнни хезмәтләрдән сирәгрәк очраган, аңлашылып бетмәгән, ләкин актуальлеген югалтмаган сүзләргә, төшенчәләргә аңлатмалар бирә, язылыш вариантларын, кайсы телдән алынганлыкларын һ. б. мәгълүматлар китерә. Сүзлек норматив характерда булмаса да, андагы материал – телчеләргә һәм тәрҗемәчеләргә генә түгел, татар теленең үткәнен күзалларга теләгән һәркемгә кызыклы белешмәлек.

Бүгенге көндә ТӘһСИнең лексикография бүлеге яңа аңлатмалы сүзлек төзү процессында. Алтытомлык итеп планлаштырылган бу фундаменталь характердагы сүзлекнең I–IV томнары 2015, 2016, 2017, 2018 елларда дөнья күрде. 2019–2020 елларда калган V һәм VI томнары да төзелеп нәшер ителер дип көтелә. Сүзлекне төзүдә күп кенә лексикографлар катнашты: Р.Р. Абдуллина, Ю.Ф. Борһанова, Ф.М. Газизова, А.Ф. Гайнетдинова, О.Н. Галимова, Ф.Ф. Гаффарова, Ф.А. Кушелекова, А.М. Сәгыйтова, Г.Г. Саберова, И.И. Сабитова, Э.И. Сафина, Г.Р. Сәмирханова, Р.Т. Сәфәров, Ф.И. Таһирова, А.А. Тимерханов, Г.Д. Фәтхетдинова, Л.Ш. Шәмсетдинова. Беренче һәм икенче томнарны Ф.Ф. Гаффарова, Г.Г. Саберова һәм Ф.И. Таһирова редакцияләде, өченчедән алып калганнарын Ф.И. Таһирова белән Р.Т. Сәфәров редакцияли.

Бу белешмәлек башкалардан күләме, сүз саны белән генә түгел, үзенең бай эчтәлеге, материалның структур төзелеше белән дә аерылып тора. Аны төзегәндә татар һәм төрки лексикографиянең соңгы казанышлары да исәпкә алынган. Бүгенге көндә ул – татар әдәби теленең лексикасын чагылдырган иң тулы, иң бай сүзлек.

**Тәрҗемәле сүзлекләр.** Сүзлекләр төзүнең тарихына ясаган кыскача күзәтүдән күренгәнчә, бу төр сүзлекләрнең башлангыч үрнәкләре бик борынгы чорда ук барлыкка килгән. Билгеле, башта алар кулъязма хәлендә генә йөргәннәр. Төзелү алымнары да гадилеге белән аерылып торган. Төрле илләр белән сәүдә-икътисади мөнәсәбәтләргә керү берничә телле тәрҗемәле сүзлекләр туугa сәбәп булган. Басма сүзлекләр чыга башлау тәрҗемә сүзлекләрнең мәгълүматлылыгын киңәйтергә (төрле сыйфатлаулар, аңлатмалар, грамматик күрсәткечләр кертү һ. б.) генә түгел, сүзләрне бирү тәртибен бердәйләштерергә дә ярдәм иткән.

Югарыда тәрҗемәле сүзлекләрнең элеккеге чорлардагы төрләрен, төзелү тарихларын бераз яктырттык. Алар XX гасырда да дөнья күрә торалар. Бу төр сүзлекләрнең күренеклеләреннән Н.Ф. Катановның 1912 елда чыккан «Краткий татарско-русский словарь в транскрипциях арабской и русской...», С. Рахманкулов белән Г. Кәрәмнең 1911 елда чыккан «Полный русско-татарский словарь с указанием ударений и грамматических свойств каждого языка, со включением иностранных слов, вошедших в употребление в русском языке» (624 б.; 1920 елда кабат басыла), С. Рахманколыйның 10 мең сүзне эченә алган «Татарча-русча лөгать»ләрен (1913) күрсәтергә кирәк.

XX гасыр башында да гарәп һәм фарсы телләреннән тәрҗемә сүзлекләр төзелә. Мәсәлән, 1893 елда Г. Баруди «Лөгате сәляс, си зөбан, өч тел» исемендә гарәпчә, фарсыча, татарча сүзлек бастыра. Бу сүзлек 1897, 1902, 1916 елларда тагын нәшер ителгән. 1912 елда Т. Ильяси «Гарәпчә-татарча мөкәммәл лөгать китабы» (824 б.) дигән хезмәтен төзеп бастыра. Уфада 1911 елда С. Җантуринның гарәп, фарсы һәм рус телләреннән алынган авыр аңлаешлы сүзләрне туплап биргән сүзлеге дөнья күргәнлеге мәгълүм. Шул ук типтагы сүзлекләрдән Габбас Сәйфуллинның «Кечек лөгать» (1912) һәм «Мәктәп лөгате» (1917), шулай ук «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге» (1965, 1993, 2018), Җ. Зәйнуллинның «Шәрык алынмалары сүзлеге» (1994) кебек хезмәтләрне билгеләп үтәргә кирәк [Сәфәров, б. 231].

Өч телле тәрҗемәле сүзлекләрдән М. Иманколыйның «Тәрҗеман руси вә фарси вә төрки» (1913 ел) исемле сүзлеге дә игътибарга лаек.

Тәрҗемәле сүзлекләр төзү эше Октябрь революциясеннән соңгы чорда тагын да тирәнрәк фәнни нигездә дәвам иттерелә. Билгеле, монда үткән дәвердәге татар лексикографиясенең бай традицияләреннән киң файдаланыла.

Узган гасырның 20 нче елларыннан татарлар да, СССР составындагы башка халыклар белән бергә, аеруча зур энтузиазм белән туган телнең байлыгын барлау һәм теркәү юнәлешендә эш алып баралар. Татар теленең дәүләт теле буларак кулланылышка керүе, шуның белән бәйле рәвештә учреждениеләрдә, дәүләт органнарында эшнең татарча алып барыла һәм документларның татарча язылa башлавы республикада яшәүче башка милләт вәкилләренә татар телен өйрәтү мәсьәләсен көн тәртибенә куя. Нәтиҗәдә ашыгыч рәвештә төрле

тәрҗемәле һәм башка сүзлекләр төзү зарурияте туа. Авыл хуҗалыгы (1924), сәясәт (1925), сугыш сәнгате (1926) белән бәйле сүзлекләр, Һ. Максудиның «Фәнни камус» дигән сүзлеге (1927) һ. б. дөнья күрә. 1927 елда М. Корбангалиев, Р. Газизов, И. Күлиев «Татарча-русча сүзлек» (15 мең сүз) чыгаралар. Соңгысы 1931 елда латин графикасында кабат бастырыла. 1929 елда татар галимнәре «Яңа русча-татарча сүзлек» төзиләр. Ул 32 мең рус сүзен эченә ала. Татарча өлеше гарәп хәрефләре белән язылган була.

1938 елда, татар язуы кирилл графикасы нигезенә күчерелгәч, тагын «Русча-татарча сүзлек» дөнья күрә (авторлары Г. Нугайбәк һ. б.). 1941 елда бу сүзлек кабат басыла. 1950 елда Р. Газизов, Н. Исәнбәт, Г. Ишмөхәммәтовларның татарча-русча сүзлеге дөнья күрә.

Тәрҗемәле сүзлекләр төзү эше XX гасыр уртасында кабат җанлана. Бу вакытта СССР Фәннәр академиясе филиалының Тел, әдәбият һәм тарих (хәзер: Тел, әдәбият һәм сәнгать) институты үзенең фәнни эшчәнлегендә тәрҗемәле сүзлекләр төзүгә зур урын бирә: 1955, 1956, 1958, 1959 елларда институт хезмәткәрләре төзегән русча-татарча дүрт томлы сүзлек бастыра. Аның югары дәрәҗәдә башкарылган булуын ассызыклап үтми мөмкин түгел: сүзләрнең мәгънәләре төгәл билгеләнгән һәм мисаллар белән дәлилләнгән, сүзләрнең стилистик һәм грамматик үзенчәлекләре күрсәтелгән, фразеологик берәмлекләрнең татарча эквивалентлары төгәл бирелгән һ. б. Бу сүзлек нигезендә яңа бер томлы русча-татарча сүзлек төзелә һәм 1971 елда – Казанда, 1984, 1985, 1986, 1991 елларда – Мәскәүнең «Русский язык», 1997 елда «Инсан» нәшриятларында кабат нәшер ителә.

1950 елда 20 мең сүзне эченә алган татарча-русча сүзлек чыга. Бер үк вакытта татарча-русча сүзлекләр төзү өстендә дә эш алып барыла. Институт коллективы 1966 елда Мәскәүнең «Советская энциклопедия» нәшриятында «Татарча-русча сүзлек» бастыра. Ул материалның байлыгы, тәрҗемәләрнең тулылыгы һәм төгәллеге белән аерылып тора, куллану өчен бик тә уңайлы.

Институт галимнәре, өч томнан торган аңлатмалы сүзлек чыкканнан соң, аның нигезендә «Татарча-русча сүзлек» (1988) төзеп бастыралар, анда актив кулланылыштагы 25 мең сүз теркәлгән. Сүзлек 1995, 1998, 2002 елларда кабат-кабат нәшер ителгән.

Узган гасырның 80–90 нчы елларында Институт лексикографларына ике томлы «Татарча-русча сүзлек» төзү бурычы куела. Алар тырышлыгы белән төзелгән сүзлек 2007 елда бастырыла. 50 мең сүзне һәм 7 мең фразеологик берәмлекне эченә алган бу хезмәт хәзергә кадәр татар теленең лексик фондын мөмкин кадәр тулы чагылдыра торган бердәнбер сүзлек булып кала килә. Сүзлекне төзүдә И.А. Абдуллин, М.Г. Мөхәммәдиев, Р.Г. Әхмәтьянов, Г.Х. Ахунҗанов, Ш.С. Ханбикова, Ф.М. Газизова, Р.Р. Абдуллина, С.Б. Вахитова, Р.К. Рәхимова, Г.Г. Саберова катнаша.

Татар лексикографиясендә рус теленнән тыш ике телле тәрҗемәле сүзлекләр дә игътибардан читтә калмаган. Аларның кайбер ми-

саллары сүзлекләр тарихы турындагы өлештә күрсәтелде. 1997 елда «Татарча-төрекчә», 1998 елда «Төрекчә-татарча» сүзлекләр басылып чыга, алар 20–22 мең сүзне үз эченә ала. Болардан тыш, 1994 елда Нью-Йоркта басылып чыккан «Татарча-инглизчә, инглизчә-татарча сүзлек»ләрне дә күрсәтергә мөмкин. Соңгы елларда чыккан тәрҗемәле сүзлекләрдән Р.Т. Сәфәров төзегән «Дини текстларга гарәпчә-татарча сүзлек» (2016) игътибарга лаек.

Күптелле тәрҗемәле сүзлекләрнең беренче үрнәкләре Урта гасырларның XIII–XIV йөзләре чигендә үк төзелгән. Соңга таба русча-татарча-калмыкча (П.И. Рычков, 1740), Г.Ф. Миллер сүзлеге (1733; рус, татар, мари, чуваш, удмурт, мордва, пермяк телләре материалларын чагылдыра), Екатерина II инициативасы белән төзелгән «Сравнительные словари всех языков и наречий, собранные десницею всевысочайшей особы» (СПб., ч. I. – 1787; ч. II. – 1789) дигән сүзлек һәм башкалар төзелә. Г. Барудиның «Лөгате сәляс, си зөбан, өч тел» дигән сүзлеге (1893 гарәпчә, фарсыча, татарча сүзлекне тәшкил итә, ул 1897, 1902, 1907, 1911, 1916 елларда кабат басылган. Насыйрия Хәбирә бинте Габделкавинең фарсы-гарәп-төрки сүзлеге (1902), М. Иманколыйның русча-фарсыча-төркичә (1917 елда кабат чыга), Ш. Тукавыйның гарәпчә-татарча-русча (1913) сүзлекләре билгеле.

Күптелле сүзлек төзү традицияләре совет чорында да бераз дәвам итә. 1954 елда Г. Ишмөхәммәтов «Төрки, фарсы, гарәп һәм казахча, татарча, русча сүзлекчә»сен бастырып чыгара. 1965 елда дөнья күргән «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге» киң катлау белгечләргә гаять әһәмиятле белешмәлек буларак хезмәт итә, 1993 һәм 2018 елда тагын бер кабат нәшер ителә.

Күптелле сүзлекләрнең бер өлеше балалар өчен чыгарылган. Авторлар Г.Ф. Фазлеев, Г.Ю. Курамшин тарафыннан сигезьеллык һәм урта мәктәп укучылары өчен «Школьный немецко-русско-татарский словарь» (1970) төзеп бастырылган. 1996 елда басылып чыккан «Тел ачкычы: Русско-татарско-английский картинный словарь» (А.Ш. һәм Ф.А. Әсәдуллиннар, 1996) дигән күптелле тәрҗемә сүзлек башлангыч сыйныф укучыларына тәгаенләнгән. Ф.Ф. Харисов һ. б. тарафыннан мондый типтагы сүзлекнең рәсемле-тематик варианты эшләнә (2001). Ф.С. Сафиуллина белән Г.А. Арслановалар инглизчә-татарча-русча уку-укыту сүзлек-минимумы (1999) төзеп чыгардылар. 2013 елда А.А. Тимерханов һәм С.Ф. Гарифуллин төзегән «Татарча-русча-инглизчә мәктәп сүзлеге» нәшер ителә. Күптелле сүзлекләрдән А.А. Тимерханов, Ф.И. Таһирова, Р.Т. Сәфәровларның «Инглизчә-русча-татарча компьютер терминнары сүзлеге» (2015) исә елның иң күп сатылган китаплары исемлегенә кертелгән була.

Татар теленә кагылышлы тагын бер күптелле сүзлекне күрсәтеп үтәргә кирәк. Ул 1991 елда Төркиядә төзелә һәм бастырыла. Анда 9 төрки телдәге (төрек, азәрбайҗан, башкорт, казакъ, кыргыз, үзбәк, татар, төрекмән һәм уйгур) төп сүзлек фондының үзара һәм русчага тәрҗемәсе латин графикасында бирелгән.

Тәрҗемәле сүзлекләр арасында кечкенә сүзлекчәләр аерым урын алып тора. Шундыйлардан сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы, мәдәният өлкәләренә караган 30лап лексик минимумны күрсәтергә мөмкин. Алар, күбесенчә, ТӘһСИ хезмәткәрләре тарафыннан төзелгән. 1990 елларда татар теле Татарстанның дәүләт теле дип игълан ителгәннән соң, төрле тармакларда эшләүче рус телле кешеләргә кыска вакыт эчендә татар телен үзләштерергә ярдәм итүдә әлеге кечкенә сүзлекчәләрнең әһәмияте бик зур булды. Алар шулай ук аерым тармак терминнарының татарча эквивалентларын табу юнәлешендә кабат эзләнүләр башлануга этәргеч тә булдылар.

Кече күләмле тәрҗемәле сүзлекләрнең аерым бер төркемен кесә сүзлекләре тәшкил итә. Аның беренче үрнәкләре 1915 елда С. Рахманкулов, 1918 елда Г. Камал, 1928 елда М. Гали тарафыннан төзелгән. Ф.С. Сафиуллина (1996, 1997) һәм Р.А. Юналееваларның (1999) кесә сүзлекләрен дә җәмәгатьчелек яратып каршы алды.

*Дәвамы бар.*

**Әдәбият**

Компьютерная лингвография / К.Р. Галиуллин, Д.Р. Валиахметова, Н.А. Обносова, В.Н. Виноградова, С.Л. Наумова, Н.А. Чишковская; науч. ред. Н.К. Замов, К.Р. Галиуллин. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1995. С. 119.

*Сәфәров Р.Т.* Татар лексикографиясе тарихында гарәпчә-татарча сүзлекләрнең урыны // Тюркское языкознание XXI века: тюркская лексикология и лексикография: международная научная конференция. 10–11 сентября 2019 г., Казань: сб. материалов. Казань: ИЯЛИ, 2019. С. 231–234.

***Миңнуллин Ким Мөгаллим улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры*

***Сәфәров Ринат Таһир улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге мөдире*

УДК 811.512.145

***Ф.С. Баязитова***

# ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕНДӘ БОРЫНГЫ ТӨРКИ ҺӘМ ЭТНОКОНФЕССИОНАЛЬ ЛЕКСИКА

Лексический, этнографический и фольклорно-диалектный (этнолингвистический) материал собран нами во время многочисленных экспедиций в районах Татарстана и за её пределами. Татарстан находится на стыке различных культур и народов, здесь сходятся Восток и Запад, взаимодействуют тюркские, угро-финские и славянские народы, мирно сосуществуют исламская и христианская религия, т. е. здесь переплетены истории и культуры разных народов и конфессий. Этнолингвистический подход к изучению духовной культуры на фоне диалектного языка татарского народа значительно расширяет возможности реконструкции архаических корней и интерпретации накопленных материалов.

**Ключевые слова:** родной язык, диалектная лексика, духовная культура, древние традиции, конфессии, праздники, ислам, православие, крещеные татары

The lexical, ethnographic and folklore-dialect (ethnolinguistic) material was collected by us during numerous expeditions in the regions of Tatarstan and beyond. Tatarstan is at the crossroads of various cultures and peoples, East and West converge here, Turkic, Ugro-Finnish and Slavic peoples interact, Islamic and Christian religions coexist peacefully, i.e. here the stories and cultures of different peoples and faiths are intertwined. The ethnolinguistic approach to the study of spiritual culture against the background of the dialectic language of the Tatar people significantly expands the possibilities of reconstruction of archaic roots and interpretation of accumulated materials.

**Keywords:** native language, dialect vocabulary, spiritual culture, ancient traditions, faiths, holidays, Islam, Orthodoxy, baptized Tatars.

Безгә ата-бабаларыбыздан изге мирас булып туган тел һәм гореф-гадәт, йолалар калган.

Тел – халык культурасының, аның психологиясенең һәм философиясенең көзгесе. Күп очракларда ул халык тарихын, аның рухын өйрәнүдә бердәнбер чыганак булып кала.

Халык традицияләрен саклау һәм үстерү, культура казанышларының уртаклыгын булдыру, халыкларның дуслыгын ныгыту хәзерге заманның иң приоритетлы бурычы итеп куела. Галимнәр фикеренчә, халык традицияләренең байлыгы – аларның, бер төрле генә булмыйча, җирле үзенчәлекләре, вариантлары да булуда. Бу очракта исә объектив һәм җентекләп тупланган материаллар гына фәнни яктан таяныч була ала. Шуның өчен, татар халкы яшәгән барлык төбәкләргә экспедицияләргә чыгып язып алынган этнолингвистик, лингвофольклористик материаллар тарихи яктан гаять әһәмиятле рухи мирас, халык педагогикасының бүгенге көнгә килеп җиткән казанышлары дип кабул ителә.

Һәр халыкның да рухи культурасында туган тел төп урынны алып тора. Халыкның туган теле, үз ана теле саклanган очракта гына, милли йөзе, гореф-гадәтләр, йолалар саклана. Татарстанда һәм аннан читтә яшәүче татарларның телендә, сөйләшендә диалекталь, ягъни җирле үзенчәлекләр булган кебек, рухи культура, гореф-гадәтләр, йолалар, бәйрәмнәр дә җирле үзенчәлекләр белән баетыла.

Билгеле булганча, халык телендә, нигездә диалекталь характерда булган культура терминологиясе яшәп килә. Традицион йолалар лексикасы сүзлек составының бик борынгыдан, гасырлар тирәнлегеннән килгән бер катламын тәшкил итә. Йола терминологиясе, йолаларга караган лексика, бер яктан, тел хәзинәсе булса, икенче яктан, халыкның рухи көзгесе, борынгылыкның бүгенге көннәргә килеп җиткән тамырлары дип әйтергә мөмкин.

Халык йолаларын һәм йола терминологиясен этнолингвистик метод белән, ягъни тел, фольклор һәм этнография ягыннан өйрәнү фәндә иң уңайлы һәм нигезле метод дип санала. Аны традицион культура диалектологиясе дип атаулар да күзәтелә [Толстой, Толстая, 1978; Толстой, 1983; Толстой, 1995].

Традицион культура диалектологиясе ышанычлы материалларга нигезләнергә тиеш. Тикшерүнең үзәгендә халык теле, халык хәтере төп таяныч итеп алына. Чөнки традицион йолаларның күпчелеге инде йола буларак үтәлмиләр, бигрәк тә авыллардагы колхозлашу, күмәкләшү елларында аларның зур өлеше инде кулланыштан төшеп калган. Ләкин халык телендә, өлкән буын кешеләренең телендә алар әле сакланып киләләр.

Аерым төбәкләрдә, авылларда сакланып калган бик кызыклы җирле сөйләшләр безгә татар халкының үзенә хас булган эчке тарихын, кабатланмас тормыш чынбарлыгын, гасырлар тирәнлегеннән дәвам иткән борынгы сүзләрне һәм көнкүреш үзенчәлекләре белән бәйле булган йолаларны китереп җиткергәннәр.

Соңгы елларда – башка төбәкләрдә яшәүче татарларның рухи культура һәм тел байлыгы саеккан дип саналган чорда да әле өлкән буыннардан бик күп җәүһәрләрне язып алырга мөмкин икәнлеге безне бик шатландыра. Борынгыдан килгән традицион йолаларыбыз да инде онытыла, юкка чыга бара дип әйтсәк тә, халкыбызның телендә, хәтерендә буыннан-буынга тапшырылып килгән рухи байлыгыбыз саклана икән. Ләкин ул хәзинәләрнең күпчелек өлешен без бары тик халыкның үзеннән өйрәнеп, тел осталарын һәм йола белгечләрен сөйләтеп кенә белә алабыз. Менә шул максат белән, диалектологик экспедицияләрдә, кулга диктофон тотып, Татарстанда гына түгел, ә бик ерак араларга сибелеп утырган татар халкының төрле төбәкләрендә, авылларында йөреп, этнолингвистик материаллар туплау насыйп булды.

Табышлар, уңышлар көтелмәгән дәрәҗәдә кызыклы, җирле сөйләшләребез халык йолаларына караган лексикага, тел һәм фольклор үрнәкләренә гаҗәп бай, бизәкле булып чыкты. Бигрәк тә авылларда

бер төркем өлкән кешеләрне бергә җыеп утыртып, алардан сөйләтеп язып алынган материаллар тулы һәм тел ягыннан да кыйммәтле дип әйтергә мөмкин. Чөнки өлкән кешеләр бер-берсен канатландырып, дәртләндереп, берсе онытканны икенчесе искә төшереп сөйләделәр.

Менә шулай итеп, махсус методика һәм программа белән бөртекләп, җентекләп тупланган материаллар халкыбызның этник культурасын, традицион йолаларны тел байлыгы белән бергә билгеле дәрәҗәдә этнолингвистик яктан реконструкцияләргә, ягъни яңадан торгызып күз алдына китерергә мөмкинлек бирә.

Себер, әстерхан, урта урал, мишәр диалекты, керәшен, нократ, касыйм һ. б. сөйләшләрдәге рифмалашкан теләк-әйтемнәр, ритуал-диалог формасындагы сөйләшүләр, йолалар белән бәйле булган һәртөрле ырымнар һәм ырым сүзләре – гомумән, фольклорның кече жанрларына кертеп карала торган тел һәм рухи байлык йола канвасының эчендә, йолалар һәм тел фактлары, атамалар белән бербөтен итеп өйрәнелә һәм системага салына.

Мәсәлән, себер диалектларыннан язып алынган мисалларда бик борынгыдан калган йола – киленне ут белән ырымлап кертүне чагылдырган сүзләр, йола хәрәкәте һәм йола предметлары – барысы да катнаша:

*– Ҡус (ут) булған, мондай торон (кисәү), аның аша сикереп цыға торған.*

*Ҡайсы кеше цаҡма цаҡтырып (чакма чактырып) торған:*

*«Цаҡма цаҡтым, ут йаҡтым,*
*Көн күрмәгән көн күрсен», –*

*тип таҡмаҡлый торған.*

*– Килен килсә, айағ асҡа торомбаш (утлы кисәү) салып, аша атлаталар:*

*«Йел-ҡус килмәсен күцеп, пәриләр, ченләр килмәсен».*
*– Киленне йилбәйләр (җилпиләр):*

*Шайтанын ҡацырғалы йилбәйләр киленне, йаулыҡ белән йилбәйләр.*

*«Шайтаның касцын.*
*Йирең-сувың киң», –*

*тип йилбәйләр.*

*«Берле булың,*
*Ботаҡлы булың,*
*Малайлар булсын».*

*– Уллы-ҡыслы кешеләр йелбеп кергезәйләр, ырымлап йелбегәннәр. Йәтим-йалғыс кешеләргә йилбитмәгәннәр:*

*«Ташлай батсын,*
*Ҡомлай сеңсен,*

*Көнен күрсен,*
*Утын йаҡсын», –*

*дигәннәр.*

Киленне ут белән ырымлап кертү әстерхан сөйләшендә *очыклау, ошыклау* дип атала.

Шулай итеп, фәнни әйләнешкә өр-яңа, бай этнолингвистик материаллар кертелә һәм алар тел, фольклор һәм этнография тармакларының барысына да таяныч һәм ышанычлы мәгълүмат чыганагы булып хезмәт итәчәкләр дип әйтә алабыз. Чөнки әлеге мәгълүматларның таралыш географиясе, язып алынган урыны, кайсы сөйләштән икәнлеге, авыллар һәм информаторлар исемнәре дә күрсәтелеп, фәнни төгәллек саклау да күз алдында тотыла.

Борынгыдан бүгенге көннәргәчә килеп җиткән йолаларны фәндә традицион йолалар дип атыйлар. Традицион йолаларны, гадәттә, икегә бүлеп карыйлар: гаилә-көнкүреш йолалары һәм календарь йолалар, ягъни елның төрле фасыллары белән бәйле йолалар.

Гаилә йолаларын туй, бала туу, мәет күмү һәм искә алу йолаларына бүлеп карау кабул ителгән. Гаилә йолалары арасында иң катлаулысы – туй йолалары. Туй йолалары дигәндә, без бер туй мәҗлесен генә түгел, ә берсен берсе алыштырып килә торган тулаем бер катлаулы циклны күз алдында тотабыз. Коллективлашу чорларында туй йоласының бик күп чылбырлары өзелгән, юкка чыккан. Шулай да, тормыш күрсәткәнчә, халык йолалары алар бик яшәүчән, традицион йолаларның да бик борынгы һәм матур үрнәкләре төрле төбәкләрдә аерым чылбырлар булып сакланып киләләр, кабат торгызуны, яңартып җибәрүне, игътибарны көтеп яталар.

Халкыбыз өйләнешү, гаилә коруга үтә җаваплы караган, аның ил каршында, җәмгыять каршында үтәлергә тиешле гадәт һәм әхлак нормалары, йолалары калыплашкан. Йолалар белән бергә, аларга караган бик күп сүз-атамалар, гыйбарәләр үзара бергә үрелеп яши, шулай ук туй йолаларының һәр этабында кара-каршы сөйләшү, җырлашу, үткен, зирәк сүзләр уйнату бу йолаларның бизәге булып тора һәм аның аерылмас бер өлешен тәшкил итә.

Җирле сөйләшләрдән җыйналган этнолингвистик материаллар тематик яктан берләштерелеп системага салына. Мәсәлән, кыз ярәшү йолалары: *димче, йаучы//саучы, башкода; кыз димләү, йәрәшү, аклашу, сөлге бирү; никах, кәбен; кийәү килү, кийәүләп йөрү;* килен төшерү: *туй ашлары, туй көймәсе, ырымнар;* туйда катнашучылар: *туй башлыгы, аргыш, арчи, кыз җиңгәсе, нүгәр, кийәү нүгәр, кыз нүгәре, сандык сакчы, кийәү сакчы, җыйын агасы, так агасы* һ. б.; туй ашлары: *саwым, кода ашы, кода күчтәнәче, оликмәк, туй чәкчәге* һ. б.; туй киемнәре: *баш бәйләү, баш сару, тастар сару, кәбен кийем, бит ачу, бөркәнчек ачу* һ. б.; туйдан соңгы йолалар: *түркен, паклун, тел йәшерү, кмау, кан' тоту* һ. б.

Халык йолаларына караган лексиканы рухи культура яссылыгында өйрәнү гаять зур тел байлыгын өскә чыгарырга мөмкинлек бирә.

Мәсәлән, җирле сөйләшләрдән туй мәҗлесе атамаларына караган туксанга якын сүзтезмә язып алынды: *алыр туй, билге туй, бирнә туйы, биткүрем туй, булышлы туй, йараш туй, кайтармыш туй, калын туй, каршы туй, пәти* (фатиха) *туй, так туй, туй keләве, туй корбаны, туй котлок* һ. б.

Халык йолаларында башка төрки халыклар белән уртаклыклар күп һәм алар тарихның бик тирән катламнарына барып тоташа. Мәсәлән, берничә мисал: *кыз кичә* (мишәр диалектында) – туй алдыннан кыз өендә үткәрелә торган мәҗлес, анда кызлар гына була. Кумык телендә *кызлар ичеси* – шул ук мәгънәдә, *тел йәшеру* (урта диалект) – яшь киленнең кайнатасы һәм иренең өлкән ир туганнары белән сөйләшмәү йоласы. Комык телендә *тил туту* – шул ук мәгънәдә һ. б.

Билгеле булганча, традицион туй йолалары ике якның сөйләшүкилешүе, туйга хәзерлек чаралары күрүдән башланып китә. Татар сөйләшләрендә ике гаиләнең килешүе, сүз беркетү, вәгъдәләшү, вәгъдә бүләкләре бирешү бик күп сүзләр һәм сүзтезмәләр белән билгеләнә: *аклашу, ак апкайту, ак алыштыру, ак чыгару* һ. б. Аклашу сүзе әдәби әсәрләрдә дә кулланылган: *Нигъмәтҗанның өйләнер заманнары, ишан кызын аклашып торабыз* (Н. Исәнбәт). Әлеге сүзләр күбрәк казан арты, минзәлә, керәшен сөйләшләре өчен хас. Татар теленең башка сөйләшләрендә: *тастар алу, тастар алырга килү* (ләмбрә). *Тастар* – мишәр диалекты сөйләшләрендә кулдан сугып һәм чигеп эшләнгән, кияүгә чыккан хатын-кызлар башларына бәйли торган сөлгесыман ак тукыма. Шундый ук баш киеме *сурпан* – чувашларда да туй алдыннан кияү ягына вәгъдә бүләге итеп бирелә торган булган. Кыргыз, нугай телендә: *тастарлы* – кияүгә чыккан хатын-кыз.

Бала туу, кешене соңгы юлга озату йолалары лексикасы да этнолингвистик яктан реконструкцияләнеп, рухи культура яссылыгында барлап чыгып системага салынды.

Ел фасылларына караган йолалар һәм бәйрәмнәрнең тарихы бик еракта килә. Ул йолалар буыннар арасында дәвамлылык, бер-берсеннән өйрәнү, үрнәк алу, бердәм рухи халәт тудыруга хезмәт итәләр. Ел фасыллары белән бәйле булган йолалар табигать, ел тәүлегенең үзгәрешенә бәйле рәвештә яшәп киләләр. Игенчелек, терлекчелек белән шөгыльләнгән авыл кешеләренең күмәк уздырыла торган бәйрәмнәре һәм йолалары да кояш нурларына һәм көн җылынуга, үләннәр һәм агачлар яшәрүгә, табигатьнең яңаруына шатлану булып башланып киткәннәр. Кеше һәрвакыт бәйрәмнәрне, рухи бәйләнешне, уртаклыкны кирәксенгән. Татар халкының традицион бәйрәмнәре һәм йолалары Идел буенда яшәгән башка милләт халыклары – башкорт, чуваш, мари, удмуртлар, шулай ук көнчыгыш славяннар белән дә зур уртаклык күрсәтә.

Фәнни әдәбиятта ел дәвамында башкарыла торган йолалар һәм бәйрәмнәрне, үтәлү вакытлары буенча, кышкы, язгы, җәйге һәм көзге сезоннарга бүлеп өйрәнү кабул ителгән. Кайчагында аларны

язгы-җәйге, көзге-кышкы йолалар дип берләштерәләр [Календарные..., 1973; 1977; 1978; 1983; Соколова, 1979; Виноградова, 2001].

Күренекле этнограф Р.К. Уразманова календарь йолаларны һәм бәйрәмнәрне ике бүлектә карый: язгы-җәйге һәм көзге-кышкы [Уразманова, 2001]. Ләкин халыкта авыл тормышына бәйле рәвештә ел дәвамында башкарыла торган хуҗалык эшләрен *урак өсте, сабан өсте, болын өсте, печән өсте* дип атау кабул ителгән. Хәтта ял итү, күңел ачу вакытларын да *уйын өсте, нардуган өсте* дип әйткәннәр.

Борынгыдан килгән (традицион) йолалар һәрвакыт төрле ырымнар, серле тылсымлы теләкләр, такмаклар яки җырлар белән үрелеп бара һәм алар шул йоланың аерылмас бер өлеше, аның бизәге булып та тора [Соколова, 1982: 11–25]. Аларда халыкның әүвәлге заманнардан килгән ышанулары һәм күзаллавы чагыла.

Җирле сөйләшләрдә ел фасылларына караган йолалар лексикасы да гаҗәп бай һәм кызыклы. Мәсәлән, язгы-җәйге йолалардан *әмәл* – себер диалекты, *әмил* – әстерхан сөйләше. Бу сүзләр фарсы телендәге *хәмәл* – март ае дигән сүзгә туры килә, нәүрүз бәйрәме кебек үк үткәрелә. Йола лексикасы: *әмил ботка, әмәл-тукац, әмәл котлок* һ. б. Язгы чәчү, сабан йолалары: *сабан туйы, сабан чабучы, сабан келәме, сабан корбаны, сабан туйы йомыркасы, чәчү йомыркасы, қызыл йомырка бәйрәме, чәчәк бәйрәме, такыйа бәйрәме, йафрак бәйрәме, йаңгыр сорау, кыр келәwе, шыйлык, чук* һ. б. караган истәлек сөйләмнәр йола сүзләре, атамалары белән бергә җирле сөйләш үзенчәлекләрен саклаган хәлдә төркемләп биреләләр.

Башка бик күп халыклардагы кебек, татарларда да кышның яңа ел көннәре төрле тылсымлы йолалар, күрәзәлек итү уеннары белән билгеле, бигрәк тә мишәр диалекты, керәшен, касыйм һәм нократ сөйләшләрендә борынгы ышанулар белән нык үрелеп бара торган нардуган, яңа ел йолаларына караган лексика күп күзәтелә: *бабай булып йөрү, бабайчы wақыты, айу булып йөрү, айу чикмәненә чыгу, истәргәнгә чыгу, тынга чыгу, нардван, нардыван, нардуган, нардуган такмагы, нардуган өе, нардуган башы, нардуганчы; раштау, рошпо, раштуа* һ. б.

Җирле үзенчәлекләр шул төбәктә яшәүче халыкның җанына якын, кадерле һәм изге була. Шулар арасында дини бәйрәмнәр, йолалар һәм йолаларга караган текстлар, сүзләр, сүзтезмәләр, рифмалашкан дини теләкләр, багышлаулар да зур урын алып торалар. Бу табигый, чөнки дини йолалар, бәйрәмнәр халыкның иң борынгы ышанулары, мифология һәм тормыш-көнкүреш, тел-сөйләм үзенчәлекләре белән бергә үрелеп барган.

Ислам динен тотучыларның дини бәйрәмнәре шактый күп. Аларның атамалары төрлечә: *бәйрәм, гайет,* ә кайберләре *кичә, кич, көн* дип йөртелә. Кеше һәрвакыт бәйрәмнәрне, рухи бәйләнешне һәм уртаклыкны кирәксенгән. Шунысы да игътибарга лаек, төп мөселман бәйрәмнәрен татарлар *«гайет»* (< гарәп телендә *гайд*)

дип, ә борынгыдан килгән халык бәйрәмнәрен шулай *бәйрәм* дип (*нәүрүз бәйрәме, әмәл бәйрәме* һ. б.), яки *туй* дип (*карга туй, сабан туй, сука туй* һ. б.) атаганнар. *Бәйрәм* сүзе Идел буендагы күрше халыкларда да кулланыла: чув. *пейрам* – бәйрәм, мар. *ага байрам* – яз бәйрәме һ. б.

Әйтергә кирәк, аерым фәнни хезмәтләрдә, сүзлекләрдә байтак мәгълүматлар булса да, халык бәйрәмнәренә караган йола терминологиясе, йола сүзләре беркем тарафыннан да махсус тупланмаган, системага салынмаган. Ә аларны өйрәнү, барлау фәнни яктан да, практик яктан да әһәмиятле, чөнки йола терминологиясе ул, бер яктан, тел хәзинәсе булса, икенче яктан, аны халыкның рухи көзгесе, борынгылыкның бүгенге көннәргә килеп җиткән тамырлары, дип әйтергә була. Бәйрәмнәр, йолалар, традицияләргә караган сүзләр гасырлар тирәнлегеннән безнең көннәргәчә килеп җиткәннәр. Шуның өчен аларда татар теленең борынгы төрки тел белән уртаклыклары, һәртөрле ышанулар, ырымнар, дини йолалар, төрле конфессиягә караган үзенчәлекләр бергә үрелеп бара.

Хәзерге вакытта, дин иреге кайтарылганлыктан, дини бәйрәм көннәрендә мәчетләрдә вәгазьләр сөйләнә, хөтбәләр укыла. *Вәгазь* (< гар.) үгетләп, димләп, өндәп сөйләнгән сүз (увещевание, проповедь). *Хөтбә* (< гар.) нотык, сөйләнгән сүз, вәгазь (речь, проповедь). Барлык ислам илләрендә *хөтбә* (проповедь) гарәп телендә укылган, Идел буе халыкларында да гасырлар буе шулай барган. XX гасыр башында кайбер прогрессив карашлы дин эшлеклеләре хөтбәне халык аңламаган телдә укуның файдасы юк дигән фикерләр белән чыгалар. Г. Баруди үзенең «Әд-дин вә әл-әдәп» дигән журналында хөтбәне туган телдә укырга өнди, чөнки халыкка мөселман диненең эчтәлеге, әдәп-әхлак мәсьәләләре аңлаешлы булырга тиеш дип яза: «В большинстве случаев татары-мусульмане старались мольбу произносить на малопонятном им арабском языке. Татарские просветители на страницах периодической печати призывали население обращаться с мольбой к Аллаху на родном языке, пытаясь объяснить, что мольба на понятном языке намного искреннее и понятнее, чем заученные формулы» [Мухаметшина, 2014, с. 110, 247].

Билгеле булганча, татар халкы төрле этнографик төркемнәрдән тора: казан татарлары, мишәрләр, нократ, касыйм, әстерхан, пермь, керәшен татарлары һ. б. Аларның күпчелеге Татарстаннан читтә, башка халыклар чолганышында яши. Керәшеннәр – христиан динендәге татарлар. Керәшен сүзе рус телендәге крещен, крещеный дигән сүздән, татар теленең авазлар яңгырашына җайлаштырып, үзгәртелеп кабул ителгән. Керәшеннәрдә христиан диненә караган бәйрәмнәр: *Раштуа* (рус. Рождество), *кершән* (рус. Крещение), *олы көн* (Пасха), *җафрак бәйрәме* (Троица), *питрау* (Петров день) һ. б. йолалар сакланган. Ләкин этнокультурага караган, дин кергәнче булган борынгы катлам, тел-сөйләш үзенчәлекләре барлык татар халкы өчен дә уртак. Бер милләт эчендә ике конфессиягә караган татарларны туган

тел һәм рухи культура, тормыш-көнкүреш янәшәлекләре берләштерә [Баязитова, 1986, б. 248].

Тикшерүче галимнәр күрсәткәнчә, христиан диненә караган бәйрәмнәр нигездә ел фасылларына, календарь йолаларга карый һәм барлык Евразия халыкларының да җир эшкәртү, игенчелек йолаларына барып тоташа [Пропп, 1963].

Билгеле булганча, борынгыдан килгән халык йолаларының, ягъни традицион культурага караган йолаларның өч төрле коды (ачкычы) булган, алар өч яклап башкарылганнар [Толстой, 1995, с. 23].

Беренчесе – нинди дә булса хәрәкәт белән (русча действенный).

Икенчесе – нинди дә булса әйбер белән (предметный).

Өченчесе – нинди дә булса сүзләр, теләкләр белән (вербальный).

Күп очракта йола башкарганда әйтелә торган сүзләр онытылган була, яки аларны бары тик өлкән кешеләр авырлык белән генә хәтерлиләр, әйтеп күрсәтәләр. Мин үзем, филолог буларак, йолаларның менә шушы өченче өлешенә дә мөмкин кадәр зур игътибар бирергә тырышам. Халык традицияләре, бәйрәмнәр, көнкүреш йолалары белән бәйле булган һәртөрле ырымнар, ырым сүзләре, рифмалашкан теләк-әйтемнәр, җырлар, такмаклар, ритуал-диалог формасындагы сөйләшүләр – гомумән, фольклорның кече жанрларына кертеп карала торган рухи байлыклар йола канвасы эчендә, бербөтен итеп биреләләр. Әлеге материаллар халыкның борынгыдан килгән мифологик күзаллавын чагылдыру ягыннан бик әһәмиятле һәм аларны инде югалып, бетеп бара торган жанр, дип әйтергә мөмкин.

Хәзерге вакытта безнең татар халкы да, илебездәге башка бик күп халыклар кебек үк, үзенә күрә бер дулкынлану һәм үткәннәрне сагыну чоры кичерә. Халкыбызның теленә һәм рухи мәдәниятенә галимнәрнең генә түгел, барлык төр профессия кешеләренең дә игътибары бик нык артты. Бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән рухи хәзинәләребезне саклап калу, онытыла башлаган гореф-гадәт, йолаларыбызны һәм аларга караган сүзләрне кире кайтару халыкның үзендә булган байлыкны тулысынча файдаланган очракта гына мөмкин эш булып кала.

## Әдәбият

*Баязитова Ф.С.* Говоры татар-кряшен в сравнительном освещении. М.: Наука, 1986. 248 с.;

*Баязитова Ф.С.* Керәшеннәр. тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты. Казан, 1997. 248 с.

*Баруди Г.* Белмәгән тел белән дога мөмкинме? // Әд-дин вә әл-әдәп. Казан. 1914. № 1; Хөтбә – халык аңлый торган телдә булырга тиеш // Әд-дин вә әл-әдәп. Казан. 1914. № 1.

*Виноградова Л.Н.* Зимняя календарная поэзия западных и восточных славян. Генезис и типология колядования. М.: Наука, 1982.

Календарные обычаи и обряды в странах зарубежной Европы: Зимние праздники. М., 1973; Весенние праздники. М. 1977; Исторические корни и развитие обычаев. М., 1983.

*Мухаметшина А.В.* Ислам в Среднем Поволжье: общее и особенное. Казань, 2014.

*Пропп В.Я.* Русские аграрные праздники. М., 1963.

*Соколова В.К.* Весенне-летние календарные обряды русских, украинцев и белорусов. М., 1979; Заклинания и приговоры в календарных обрядах // Обряды и обрядовый фольклор. М., Наука, 1982. С. 11–25.

*Толстой Н.И.* Язык и народная культура: очерки по славянской мифологии и этнолингвистике. М.: Индрик, 1995. 512 с.

*Уразманова Р.К.* Обряды и праздники татар Поволжья и Урала. Годовой цикл. XIX – нач. XX вв. Историко-этнографический атлас татарского народа. Казань: Дом печати, 2001. 196 с.

***Баязитова Флера Сәет кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145

***М.В. Пименова***

# *УРДА* СҮЗЕНЕҢ СЕМАНТИК ҮСЕШ ПРОЦЕССЫ

В статье анализируются значения слова *орда* в этимологических и толковых словарях русского языка. Слово *орда* в современном русском языке означает: 1. Название крупных тюркских и монгольских феодальных государств в эпоху Средневековья. 2. Ставка, местопребывание их правителей. 3. Название союзов кочевых племен. 4. Вражеское войско; полчище. 5. Многолюдная, беспорядочная и шумная толпа, сборище (в этимологических словарях: «беспорядок, шум»). Русские летописи представляют слово *орда* в значении «войско (не всегда вражеское)». Упомянутые в этимологических словарях значения «стан, кочевье», «дворец/шатер хана/султана» и «военный лагерь» были вытеснены, т.е. налицо процесс десемантизации слова *орда*. Обнаруженные в былинах значения «государство» и «земля» в словарях русского языка не упоминаются вовсе. Как показывает анализ, русская языковая картина мира претерпела изменения – сейчас в ней отобразился европейский взгляд на нашу собственную историю. Корни этого видятся в изменении идеологии, связанной с не до конца ясной историей нашего Отечества.

**Ключевые слова:** тюркизмы, заимствование, десемантизация, языковая картина мира.

The article analyzes the meaning of the word *орда* «horde» in the etymological and explanatory dictionaries of the Russian language. The word *орда* «horde» in the modern Russian language means: 1. The name of the large Turkic and Mongolian feudal states in the Middle Ages. 2. Bet, the seat of their rulers. 3. The name of the unions of nomadic tribes. 4. Enemy army; horde. 5. A crowded, disorderly and noisy crowd, a bunch (in the etymological dictionaries: «disorder, noise»). Russian chronicles represent the word *орда* «horde» in the sense of «army (not always enemy)». The meanings «camp, nomadic», «palace / tent of the khan / sultan» and «military camp» mentioned in the etymological dictionaries were suppressed, i.e. there is a process of desemantizing the word *орда* «horde». The meaning «state» and «earth» values found in bylins are not mentioned at all in the Russian language dictionaries. As the analysis shows, the Russian language picture of the world has undergone changes – it reflects the European view of its own history. The roots of this are seen in the change in ideology associated with an incompletely clear history of our own Fatherland.

**Keywords:** turkism, borrowing, desemantization, language picture of the world.

Ил тарихы тел үсеше процессы белән бергә бара. Тел вакытка бәйле рәвештә үсә, әлеге үсештә сүзләр, халыкның ментальлегендә күзәтелә торган үзгәреш тенденцияләрен чагылдырып, үзләренең мәгънәләрен үзгәртәләр. *Ментальлек* дигәндә, «туган тел категорияләре һәм формаларында урын алган һәм танып белү процессында милли характерның интеллектуаль, рухи һәм ихтыяри сыйфатларының типик чагылышларын бергә туплаган дөнья күзаллаешы» аңлашыла [Колесов 2000: 15].

Мәкаләдә *орда (урда)* сүзе семантикасы үзгәрү аспектында, ягъни рус теле үсеше процессында яңа мәгънәләргә ия булу һәм элеккеләрен югалту күзлегеннән тикшерелә. Сүз ментальлек теориясе кысаларында анализлана.

Рус телендәге төрки сүзләр (тюркизмнар) галимнәрнең игътибарын күптәннән җәлеп итә. Тюркизмнарның үзләштерелү вакытыннан башлап безнең көннәргә кадәрге үсеш тарихы әледән-әле лингвистларда зур кызыксыну уятып килә.

Сүзнең этимологиясеннән башлыйк. Макс Фасмер үзенең мәкаләсендә түбәндәгеләрне күрсәтә: «ордá I, укр. ордá, блр. ордá «беспорядок, шум», др.-русск. орда «стан, кочевье» (Афан. Никит. 9 и др.; см. Срезн. II, 705 и сл.), ординьское, прилаг., грам. 1362-1389 гг.; см. Шахматов, Очерк 186. Заимств. из тюрк.; ср. чагат., азерб., тар., казах. orda «дворец, шатер султана, хана», тур. ordu «военный лагерь» (Радлов 1, 1072 и сл.), уйг. Ordukänt «ординский город=город Кашкар» (Радлов 1, 1075), монг. ordu, orda, калм. ordɔ «двор, лагерь, стоянка, орда» (Рамстедт, KWb. 288)» [Фасмер: электронный ресурс].

Башка авторлар, мәсәлән, Г.А. Крылов, Н.М. Шанский сүзлекләрендә *урда* сүзенең төрки чыгышлы булуы билгеләнә. Татар телендә *орда (урда)* – «лагерь, стан» [Крылов: электронный ресурс]. Н.М. Шанский вакыт барышында үсеш алган мәгънәләр чылбырын китерә: орда – «лагерь» < «ставка хана» < «дворец» (с тронным залом), того же корня, что орун «трон» [Шанский: электронный ресурс].

Югарыдагы этимологик сүзлекләр буенча, *орда (урда)* сүзе рус теленә төрки телләрдән кергән. Башта ул түбәндәге мәгънәләргә ия булган: 1. Тәртипсезлек, тавыш. 2. Стан, күчеп йөрү урыны. 3. Солтан/хан сарае/чатыры. 4. Хәрби лагерь.

Рус елъязмалары, *орда (урда)*сүзенең семантикасын киңәйтеп, әлеге мәгънәләрне тулыландыралар. Борынгы Русь чоры текстларында *урда* сүзе язуда беренче тапкыр XIII гасыр уртасында теркәлә. XIII–XIV гасыр чыганакларында *урда* сүзе семантикасының синкретик характерда булуы күзәтелә: контекстларда «хан ставкасы; дәүләт» һәм «та(р)тар җире, та(р)тар дәүләте» мәгънәләре аерылгысыз (*Золотая Орда* (*Алтын Урда)* гыйбарәсе рус чыганакларында XVI гасырда пәйда була; *ордынский* сыйфаты XIV гасырда ук очрый).

Рус былиналарында *орда (урда )*сүзе еш кына «җир, гомумән ил, татар җире» мәгънәсендә телгә алына: «*Ты откудошный дородный добрый молодец, ты с какой* ***земли*** *да из какой* ***орды***» (Первая поездка Ильи Муромца. Илья и Соловей-разбойник). Былиналарда *урда* һәм *җир* сүзләре, бер-берсенә аңлатма биреп, янәшә килә: «*И не матушка ли* ***орда*** *подымалася, Мать сыра* ***земля*** *от войска потрясалася...*» (Мамаево побоище); «*Как про тебя слава широко-то шла По всим* ***землям-то****, еще по всим* ***ордам****...*» (Святогор примеряет гроб).

*Урдаң* былиналардагы эпитетлары: ***зур (большая), бөек (великая), ерак (дальняя), бай (богатая), караңгы*** (***темная)***. ***Караңгы (темная)*** эпитеты тискәре коннотацияле: «*А кого бы мне послать*

*повыехать Да во тую ли во* ***землю*** *да во дальнюю, да во тую ль во* ***орду*** *во* ***темную, Во темную орду*** *да в хоробру* ***Литву****, Ко тому ли к королю литовскому, Ко тому ли к Ботияну к Ботиянову, – А свезти-то дани ему, выходы...*» (Добрыня и Василий Казимирович. Добрыня в отъезде). Бу контекстта Литваны *орда (урда)* дип атау игътибарны җәлеп итә. Биредә Литва синкретик рәвештә «дәүләт» тә, «җир» дә дип атала.

Югарыда телгә алынган *Золотая Орда* (*Алтын Урда)* гыйбарәсе былиналарда *җирнең* синонимы булып килә: «А и едем мы из дальной **Орды**, **Золотой земли**, от грозна короля Етмануйла Етмануйловича...» (Про Ставра-боярина). В.И. Даль сүзлегендә *орда (урда)* сүзе кергән мәкаль һәм әйтемнәр дә очрый: *Иван был в орде, а Марья вести сказывает. Каков царь, такова и орда. Хоть в орде, да в добре. Старших их в орде почитают. Хоть в орду, так пойду. Где хан, тут и орда. Один от Золотой орды, другой от рыжей бороды.*

Хәзерге рус телендә сүзнең түбәндәге мәгънәләре билгеле. «Кече академик сүзлек» болай дип яза: «орда-ы́, мн. о́рды, ж. 1. ист. Название крупных тюркских и монгольских феодальных государств в эпоху средневековья, а также ставка, местопребывание их правителей. Золотая орда. Крымская орда. || Название союзов кочевых племен. 2. перен.; с определением. пренебр. Вражеское войско; полчище. Фашистские орды. 3. перен.; кого или какая. разг. Многолюдная, беспорядочная и шумная толпа, сборище кого-л.» [СРЯ: электронный ресурс]. Күргәнебезчә, этимологик сүзлекләрдә теркәлгәннәренә яңа мәгънәләр өстәлә: 1. Урта гасырларда эре төрки һәм монгол феодаль дәүләтләре атамасы. 2. Аларның хөкемдарларының урнашкан урыны, ставкасы. 3. Күчмә кабиләләр союзы исеме. 4. Дошман гаскәре, явы. 5. Күп кешеле, таркау һәм тавышлы халык төркеме (этимологик сүзлекләрдә: тәртипсезлек, тавыш). Рус елъязмаларында *орда (урда)* сүзе еш кына гаскәр (һәрвакыт дошман гаскәре түгел) мәгънәсендә очрый. Этимологик сүзлекләрдәге «стан, күчеп йөрү урыны», «хан/ солтан сарае/ чатыры» һәм «хәрби лагерь» мәгънәләре югарыда әйтелгәннәре тарафыннан кысрыклап чыгарыла. Былиналардан алынган контекстлар аша табылган «дәүләт» һәм «җир» мәгънәләре рус сүзлекләрендә бөтенләй юк.

Әлеге мәгънәләрне аңлатмалы сүзлекләрдә түгел, ә политология һәм тарих буенча энциклопедияләрдә эзләп табарга мөмкин. «Орда. Тюркское слово с очень широким спектром значений, включающим ставку, дворец правителя, территорию, занятую определенным племенным или политическим (государственным) образованием, войско, армия, место периодических сборов родственных кочевий, кочевой лагерь правителя, кочевую столицу и в некоторых тюркских языках и диалектах массу иных родственных понятий, связанных с перечисленными. В древнетюркских текстах начала II тыс. это понятие обозначает «средний», «середина». По всей видимости, как средоточие человеческих масс, собрание кочевников оно в дальнейшем

приобретает социально-политический и топографический смысл. Ордами именовались крупные владения, на которые подразделялась при Чингисхане и Чингисидах территория первоначального общемонгольского улуса» [Политология. Словарь].

Энциклопедияләрдә рус теле сүзлекләрендә төшереп калдырылган тагын бер мәгънәне табарга мөмкин. Ул – «җәмгыятьнең беренчел оешу формасы»: «1) у тюркских и монгольских народов первоначально военно-административная организация, затем становище кочевников, в средние века – ставка правителя государства 2) Устаревший термин, обозначающий самую раннюю форму организации общества («первобытное человеческое стадо») 3) В обиходном значении – многочисленное неорганизованное скопище людей» [Большой энциклопедический словарь].

Хәзерге рус телендә *орда (урда)* сүзенең стилистик төсмерле мәгънәләре дә игътибарга лаек: «2. перен.; с определением. пренебр. Вражеское войско; полчище. Фашистские орды» һәм энциклопедиядәге «борынгы ... көтү». Алар кайчан һәм кайдан килеп чыкканнар?

*Орда (урда)*сүзенең шушы ике соңгы мәгънәсе: 1. Җәмгыятьнең беренчел оешу формасы («борынгы кешеләр көтүе»). 2. Дошман гаскәре; яу» аермачык күренеп торган тискәре коннотациягә ия. Ә бу тиңдәш концепт структурасында иронияле компонент барлыкка килү турында сөйли. Урданы «борынгы көтү» һәм «дошман гаскәре» дип атауның сәбәбе татар-монгол изүенә барып тоташа. Әмма булганмы соң ул?

Әгәр изү (иго) булган икән – бу сәяси юнәлеш тоткан тарихчыларның чираттагы уйдырмасы. Шуңа күрә сәбәпне башкадан эзләргә кирәк. Европа телләренә (барысына да – үлеләренә дә, тереләренә дә) мөрәҗәгать итик. Латин телендә *jugum tartaricum* (лат. jugum «җәбер-золым, коллыкка төшерү») сүзтезмәсе бар, ул «тәмуг җәбер-золымы» дип тәрҗемә ителә. Бәлки әлеге гыйбарәне турыдан-туры «тартар явы» дип тәрҗемә итәргәдер? Татар түгел, ә нәкъ менә язылганча – тартар дип. (Грек телендә ταρσαροζ (тартарос) «җир асты патшалыгы» дигән мәгънәне белдерә, чагыштыр. рус. *провалиться в тартарары.* Тартарос – җир астында калган патшалыкмы ул?)

Англиядә тискәре, кире малайны *young Tartar* – «та(р)тар малае» дип йөртәләр. Инглизчә *to catch a Tartar* гыйбарәсе ( «та(р)тар кешесен очрату») «көчлерәк дошман белән очрашу» дигәнне аңлата.

Башка телләр мисалында да *орда (урда)*сүзе белән тамырдаш сүзләрнең булуы күренә: инглиз телендәге *Horde* «урда, җыелган күпсанлы кешеләр/ хайваннар / бөҗәкләр; бик зур гаскәр; банда, шайка». Латин телендә дә *ordo* сүзе бар, ул түбәндәге мәгънәләргә ия: «1. хәрби линия, шеренга; 2. отряд, центурия; 3. разряд, катлау (ordo equester җайдаклар катлавы); 4. тәртип, дөрес гамәл, хәрәкәт, дөрес корылма», *ordino* фигыле «тәртипкә китерү, рәткә бастыру, сызыкка бастыру» мәгънәсен бирә.

Инглиз телендәге *Cossack* «казак»ны аңлата: kazak from Turkic, 'vagabond, nomad'; later influenced by French. Ягъни *казак* сүзе «сукбай, күчмә» мәгънәсенә ия. Ә без бу сүзне «атлы сугышчы» дип беләбез.

Тәре йөртүчеләр – ул үзгә хәрби – рыцарьлар ордены. О́рденнар – XI–XIII гасыр тәре походлары чорындагы Европа рыцарьларының хәрбиләрдән һәм монахлардан торган оешмалары. Александр Невский тарафыннан тар-мар ителгән Тевтон ордены, Ливон ордены белән берлектә, XII–XIV гасырларда бергезлексез Литва, Польша һәм Төньяк-Көнбатыш Рус дәүләтләре белән сугышкан: «В лето 6750 (1242). Ходил Александр Ярославич с новгородцы на немцы и бился с ними на Чудьском озере у Воронина Камени и победил Александр и гнал (немцев) по льду 7 верст, секучи (рубя) их». 1410 елда поляклар һәм литвалылар белән Таненнберг сугышында җиңелүгә дучар булганнан соң, Тевтон ордены Прирейн краена Франкониягә күченә, һәм Наполеон I гә кадәр шунда яши.

Хәзерге заманда аерым казанышлар өчен бирелә торган бүләкләрне (иң элек – хәрби өлкәдә) орденнар дип йөртәләр. Тагын *ординарец* (командирның йомышларын үтәүче гаскәри хезмәткәр) һәм *координация* (килештерү, тәртипкә салу) сүзләре дә бар.

*Орден* сүзе *урдадан (орда)* килеп чыккан. Немец телендәге *Ordnung* шулай ук *урдага (орда)* барып тоташа. *Ordnung* «тәртип, строй, устав» дигәнне аңлата. Рыцарьлар орденнары – шул исәптән Изге Төрбә (Гроб Госпо́день) өчен дә сугышкан дисциплиналы, катгый иерархиягә ия хәрби берләшмәләр алар. Ягъни рус, латин, немец һәм инглиз телләрендә сүзләрнең һәм тиешле гыйбарәләрнең мәгънәләре аерым бер тарихи чорның идеологиясен чагылдыра: *рыцарьлар орденнары (рыцарский орден) гыйбарәсенең* тискәре коннотацияләре юк, ә *казак,* инглизләр күзлегеннән караганда – сукбай, ягъни рыцарь кебек сугышчы түгел: казаклар һәм рыцарьларның максатлары төрле булган.

Һәм тагын бер ремарка. Казакълар үзләрен *алашлар* дип атыйлар. Алаш – сугышчы-җайдак; Алаш Урда – атлылар отряды, гаскәрнең канаты, эскадрон.

Күргәнебезчә, *орда (урда)* сүзенең семантикасына кагылышлы тема белән беренче очрашканда, бер-берсеннән аерылгысыз ике – тарихи һәм идеологик – позицияләр бәрелешә.

### Әдәбият

*Даль В.И.* Пословицы русского народа. [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://www.twirpx.com/file/391080/. Дата обращения: 12.06.2019 г.

*Колесов В.В.* Древняя Русь: наследие в слове. Мир человека. СПб.: Филологический факультет СПбГУ, 2000. 326 с.

*Крылов Г.А.* Этимологический онлайн-словарь русского языка [Электронный ресурс]. Режим доступа: http://rus-yaz.niv.ru/doc/etymologic-dictionary/fc/slovar-206.htm. Дата обращения: 12.06.2019 г.

Словарь русского языка: в 4-х т. / РАН, Ин-т лингвистических исследований; под ред. А.П. Евгеньевой. 4-е изд., стер. М.: Рус. яз.; Полиграфресурсы, 1999. [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://kartaslov.ru/значение-слова/орда. Дата обращения: 12.06.2019 г.

*Фасмер М.* Этимологический онлайн-словарь русского языка [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://lexicography.online/etymology/vasmer/о/орда. Дата обращения: 12.06.2019 г.

*Шанский Н.М., Боброва Т.А.* Школьный этимологический словарь русского языка. Происхождение слов. М.: Дрофа, 2004. [Электронный ресурс]. Режим доступа: http://www.slovorod.ru/etym-shansky/shan-o.htm. Дата обращения: 12.06.2019 г.

***Пименова Марина Владимировна,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Чит телләр институты (Санкт-Петербург) ректоры*

УДК 811.512.145

***Э.Н. Денмөхәммәтова,***
***Р.Х. Гәрәева***

# КАРДӘШ ТЕЛЛӘРГӘ ТӘРҖЕМӘЛӘРДӘ ЛЕКСИК ТРАНСФОРМАЦИЯ ТӨРЛӘРЕ

В сопоставительном изучении языков главную роль играют переводы. Ведь перевод это не только сопоставление и сравнение двух разных языков, но также и диалог двух культур. Тюркские языки имеют общие корни и общее прошлое, но, несмотря на это их развитие отличается друг от друга. Это зависит от экстра- и интералингвистических факторов: разная история, образ жизни, географические особенности и влияние других языков формируют новые изменения в языке. В статье рассматриваются вопросы перевода с татарского языка на другие тюркские языки. Лексические трансформации исследуются на примеры переводов произведений А. Еники на башкирский, казахский, узбекский и турецкий языки. В данной работе мы исследовали виды переводческих трансформаций и лингвистические особенности при переводе татарских произведений на родственные тюркские языки.

**Ключевые слова:** татарский язык, тюркские языки, перевод, лексические трансформации, лингвистика.

In the comparative study of languages, the main role is played by translations. After all, translation is not only a juxtaposition and comparison of two different languages, but also a dialogue of two cultures. Turkic languages have common roots and a common past, but, despite this, their development differs from each other. It depends on extra- and inter-linguistic factors: different history, lifestyle, geographical features and the influence of other languages form new changes in the language. The article deals with the translation from the Tatar language into other Turkic languages. Lexical transformations are studied on examples of translations of A. Eniki's works into Bashkir, Kazakh, Uzbek and Turkish languages. In this paper, we investigated the types of translation transformations and linguistic features in translating Tatar works into related Turkic languages.

**Keywords:** Tatar language, Turkic languages, translation, lexical transformation, linguistics.

Хәзерге вакытта телләрне чагыштырып өйрәнүгә зур игътибар бирелә. «Тәрҗемә эшенең аеруча киң колач җәйгән урыны – күпмилләтле Россия Федерациясе. «Тәрҗемә – илебездә халыклар дуслыгын, аларның туганнарча хезмәттәшлеген ныгыта торган иң әһәмиятле чараларның берсе», – дип яза Р. Юсупов [Юсупов, 2008, б. 7]. Хәзерге вакытта төрки телләрдә сөйләшүче халыклар Европа, Азия, Төньяк Америка, Австралия кыйтгаларында яшиләр. Россия территориясендә генә 30 га якын төрки телдә сөйләшүче халык бар.

Тәрҗемә – телләрне генә түгел, ә шул телләрдә сөйләшүче халыкларның мәдәниятләрен дә чагыштырып өйрәнү ул. Төрки халыклар һәм аларның телләре бер тамырдан булсалар да, вакытлар узу

белән алар арасында шактый зур аерымлыклар килеп чыккан. Моны күзәтү өчен, беренче чиратта, әлеге милләтләрнең әдәбиятына күз салу кирәк, чөнки әдәбият– халыкларның тормышын чагылдыручы төп чыганак, шунлыктан аны өйрәнү төрле ысуллар белән алып барыла. Татар әдәбияты үрнәкләре дә күп телләргә тәрҗемә ителгән һәм хәзерге көндә дә бу юнәлештә зур эш алып барыла. Халкыбыз мирасын таныту, башка милләт, дәүләт, ил вәкилләрен татар халкы, аның яшәеше һәм менталитеты белән таныштыру өчен бу иң кулай юлларның берсе.

Татар теленнән башка телләргә, шул исәптән кардәш төрки телләргә тәрҗемәләр шактый күп булуга карамастан, аларны фәнни яктан өйрәнүчеләр аз. Шунлыктан, Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» һәм «Шаяру» хикәяләре мисалында татар әдәбияты үрнәкләренең башка төрки телләргә тәрҗемәләрендә лингвистик үзенчәлекләрне өйрәнүне кирәк таптык.

Ә. Еники әсәрләре рус теленә һәм башка телләргә күп тәрҗемә ителгән. Бу эш белән Х. Хөсәенова, А. Бадюгина, И. Ваһапов, М. Рәфыйков, М. Зарецкий, Л. Лебедева һ. б. шөгыльләнгән. Ләкин әлеге тәрҗемәләрнең сыйфатын һәм үзенчәлекләрен өйрәнгән фәнни хезмәтләр юк дәрәҗәсендә (И.М. Габделхакованың «Образные сравнения в произведениях А. Еники и их перевод на русский» һәм А.М. Галиев һәм Э.Ф. Нагумановалар тарафыннан язылган «Особенности переводов пейзажных зарисовок (на материале произведений А. Еники и их переводов)»).

Мәкаләнең максаты – Ә. Еники әсәрләрендә һәм аларның төрки телләргә тәрҗемәләрендә лексик трансформацияләрне өйрәнү.

Матур әдәбият әсәренең тәрҗемәсе турында сүз алып барганда, трансформацияләр, тәрҗемә ысуллары буларак, мөһим урын алып торалар. Трансформация термины бу эштә билгеле бер мәгънәдә оригинал берәмлекләреннән тәрҗемә берәмлекләренә күчерергә ярдәм итә торган үзгәртүләр мәгънәсендә кулланыла [Комиссаров, 1990, с. 172].

Тәрҗемә теориясендә күптөрле трансформацияләр аерып күрсәтелә. Һәр галим үз классификациясен тәкъдим итә. Әлеге хезмәттә В.Н. Комиссаров карашларына таянып эш итәбез. Тәрҗемә теориясендә аның классификациясе иң кулай һәм киң таралганнарның берсе булып санала.

Төрки телләрнең барысы өчен дә уртак гомумтөрки лексика бар. Шуңа да карамастан, төрки телләр, күп еллар дәвамында, берберсеннән аерылып, башка телләр йогынтысында үзгәрәләр. Әлеге мәкаләдә каралган кайбер төрки телләр Россия территориясендә таралган (мәсәлән, татар һәм башкорт телләре Россия Федерациясе субъектларының дәүләт телләре булып тора). Аларның бүгенге яшәешендә һәм формалашуында рус теле зур роль уйный. Моннан тыш, төрки телләр классификациясендә татар һәм башкорт телләре икесе дә бер үк кыпчак төркеменең Идел буе-кыпчак кече төркеменә карый.

Шулай ук, әлеге тикшеренү барышында Ә. Еникинең «Шаяру» хикәясен башкорт теленә автор үзе тәрҗемә иткәнлеге ачыкланды, шунлыктан, башка тәрҗемә текстлар белән чагыштырган вакытта (үзбәк, казакъ, төрек телләре белән), башкортчага тәрҗемә иң тулы һәм адекват тәрҗемә дип билгеләнде.

Казакъ теле турында сүз алып барганда, шуны әйтергә кирәк: казакъ теле дә, татар һәм башкорт телләре белән берлектә, кыпчак төркеменә керә, ләкин ул нугай-кыпчак кече төркеменә карый. Октябрь революциясеннән соң 1991 елга кадәр Казакъстан СССР составына керә, географик яктан да казакъ теле рус, кытай, үзбәк һәм кыргыз телләре йогынтысында формалаша. Кыпчак төркемендәге башка телләрдән аермалы буларак, казакъ телендә гомумтөрки сүзләрдә «ч» һәм «ш» фонемалары «ш» һәм «с» фонемалары белән алмашына, сүздәге урынына карап, «м-б-п» һәм «н-д-т» фонемаларының чиратлашуы күзәтелә. Шулай ук, казакъ теле лексикасында гарәп-фарсы алынмалары шактый күп очрый.

Үзбәк теле төрки телләр гаиләсендә карлук төркеменең карлук-харәзм кече төркеменә керә. Үзбәк теленә рус, кытай, казакъ һәм аеруча уйгур телләренең йогынтысы сизелә. Казакъстан кебек Үзбәкстан да СССР составына кергән, XIX гасырның икенче яртысында ул патша Россиясе составында булган, шунлыктан үзбәк теле лексикасының көндәлек-көнкүреш, сәяси-икътисади һәм хәрби өлкәләрендә рус алынмалары күбрәк очрый. Үзбәк телендә дә, ислам динен кабул иткән барлык төрки телләрдәге кебек, гарәп-фарсы алынмалары бар. Башкорт, казакъ, үзбәк телләренең уртак тарихы шактый зур вакыт аралыгын били, шуңа да карамастан әлеге телләр лексикасында аерымлыклар да күп.

Төрек теле угыз төркеменең көнбатыш-угыз кече төркеменә керә. Алда саналып киткән телләрдән аермалы буларак, төрек теле Көнбатыш Европада таралган, һәм аның составында Европа телләреннән алынма сүзләр күп. Төрек телендә гарәп-фарсы һәм Кавказ телләреннән алынмалар да бар.

Шулай итеп, тарихи чорның берничә этабы татар, башкорт, казакъ, үзбәк телләре өчен уртак булган. Шуңа күрә, матур әдәбият текстларын төрки телләргә тәрҗемә иткәндә, моңа зур игътибар бирелә. Мәсәлән, Совет чорында татар, башкорт, казакъ, үзбәк телләренә рус алынмалары күп керә, һәм алар аңлаешлы була, чөнки әдәбиятта да урын алалар. Үз чиратында төрек теле өчен әлеге сүзләр чит һәм аңлашылмый. Димәк, тәрҗемәче алдында бу сүзләрне укучыга аңлату бурычы тора.

Тәрҗемә белемендә лексик трансформацияләр эченә транскрипция, транслитерация, калькалаштыру, лексик алмаштырулар (конкретлаштыру, модуляция һәм гомумиләштерү) кертеп карала. Аларны, аерым-аерым билгеләмәләр биреп, кардәш телләргә (бу очракта төрки телләргә) тәрҗемә иткәндә куллану очракларын күзәтү максатка ярашлы дип табылды.

**Транскрипция** – лексик берәмлекнең формасын чыганак телдәге авазлар ярдәмендә тәрҗемә итү. Бу вакытта тәрҗемәдә чыганак тел сүзенең аваз формасы саклана, үзгәрешсез кала. **Транслитерация** исә лексик берәмлекнең чыганак телдәге график формасын саклап, икенче телгә күчерү ысулы буларак бирелә. Хәзерге тәрҗемә практикасында транскрипция алымы транслитерациягә караганда ешрак кулланыла. Аерым очракларда, бер лексик берәмлекне тәрҗемә итү өчен, транскрипция белән беррәттән, транслитерациянең дә кайбер элементлары кулланылырга мөмкин. Бу һәр телдәге фонетик һәм грамматик системаларның бер-берсеннән шактый аерылып торуы белән аңлатыла, шунлыктан бер телдән икенче телгә сүзнең формасын күчерү һәрвакыт шартлы һәм якынча булып тора.

Ә. Еники әсәрләренең төрки телләргә тәрҗемәләрендә әлеге лексик трансформацияләр күзәтелә: **казакъ телендә**: *«Башкорт»–«Башқұрт», «Юлкотлы» – «Жолқұтты», «Каракош» – «Қарақұс», «Атчабар» – «Атшабар», «Гөлбикә» – «Гүлбике», «Миңлегали» – «Меңдіғали», «Сәетгали» – «Сейтіқали», «Суфиян» «Сопы жан»* һ. б.; **үзбәк теленә** тәрҗемә барышында очраган транслитерация үрнәкләре: *«Иделгә» – «Эдилга», «Диләрә» – «Дилора», «Фәния» – «Фания», «Ханым» – «Хоним»* һ.б.; **төрек теленә** тәрҗемәдә очраган мисаллар: *«Башкорт» – «Başkurt», «Миңлебай» – «Minlibay», «Юлкотлы» – «Yolkutlu», «Каракош» – «Karakuş»;* **башкорт телендә** транслитерация күренеше *«Идел» – «Иҙел»*.

Алда саналып киткән мисаллардан күренгәнчә, Ә. Еники әсәрләренең төрки телләргә тәрҗемәләрендә транслитерация һәм транскрипция алымнары очрый, һәм гадәттә алар бер телдән икенче телгә ялгызлык исемнәрен күчерүдә кулланыла.

**Калькалаштыру** –лексик берәмлекләрнең состав өлешләрен (морфема яки сүзләр) тәрҗемә телендәге лексик эквивалентлары белән алмаштырып тәрҗемә итү алымы. Калькалаштыру алымының асылы тәрҗемә телдә чыганак берәмлекне кабатлый торган яңа сүз яки тотрыклы гыйбарә барлыкка китерүдә. Төрки телләргә тәрҗемә иткәндә дә әлеге алым чагылыш таба. Мәсәлән: **казакъ телендә:** *«**Әсәем!**» [1: 16] – «**Анашым!**» [3: 59]; «Чыкмаган җанда өмет бар дигәндәй» [3: 17] – «Шықпаған жанда үміт бар дегендей». [3: 61]* Төрки телләргә тәрҗемә итү процессында калькалаштыру трансформациясе сирәк очрый. Бу төрки телләрдә уртак мәгънәгә ия булган сөйләм гыйбарәләренең һәм тел формаларының кулланылышы белән бәйле. Мәсәлән, *күз кичерү* гыйбарәсе татар, башкорт, үзбәк телләрендә дә бер үк мәгънәдә кулланыла, шунлыктан тәрҗемә текстларда ул булса да, калькалаштыру алымы кулланылган дип нәтиҗә ясарга ярамый. Телләрнең система һәм лексик охшашлыклары нисбәтеннән төгәл эквивалент төшенчәләр гаять еш очрый.

Төрки телләргә тәрҗемә ителгән текстларда аеруча еш кулланылганы – лексик алмаштыру алымы. Анализланган барлык текстларда да әлеге трансформация төре бар. **Лексик-семантик алмаштырулар** –

оригиналдагы лексик берәмлекләрне тәрҗемә телдәге берәмлекләр белән алмаштыру. Әлеге очракта тәрҗемә берәмләкләре чыганак тел берәмлекләренә туры килми. **Үзбәк телендә**: *«Түбәндә баягы таза **чандыр** егет ялгызы гына әрҗәләр өеменә йөзе белән борылып, әлеге тавис койрыгыдай яулыгына карап тора иде». [1: 63] – «Пастда ҳалиги **чиройли** йигит бир ўзи қутилар томонга ўгирилганча товус думи янглиқ ўша дуррага **кўз узмай тикиларди**». [4: 46]* Әлеге мисалда *«чандыр»* (худощавый) эпитеты *«чиройли» – матур (красивый)* сүзе белән алмаштырыла. *«...(Диләрә ханым) яшьләрнең койрыкта, тимер идәнгә газеталардан **табын** җәеп, күңелле генә ашап-эчеп утыруларын күрде». [1: 66] – «Улар темир тўшама устига **дастурхон** ўрнида газета ёйиб кўнгиллигина нонушта қилиб ўтиришарди». [4: 49]* Күп очракларда тәрҗемә текстның башка урыннарында да ***«табын»*** сүзе ***«дастурхон»*** сүзе белән алмаштырыла. Мәсәлән: *«Апа, рәхим итегез! Безнең **табын** студентларча, такы-токы гына инде, гаеп итмәссез!» [1: 66] – «Узр, опа! **Дастурхонимиз** студентчасига ночорроқ, айбга қўшмайсиз-да энди!» [4: 49]* Урта Азия халыкларында ашъяулык һәм өстәл япмасы дастурхон дип атала. Әлеге сүз үзбәк, казакъ (дастарқан), азәрбайҗан (dəstərxan) һәм кыргыз (дасторкон) телләрендә дә кулланыла.

*«Ә кыз шунда ук егетләргә, **дәү апаларыдай**, җитди генә әйтеп куйды!» [1: 70] – «Қиз йигитларнинг **мураббиясидай** қошлари жиддий чимирилди». [4: 52]* Лексик алмаштырудан кала, әлеге мисалда өстәү кебек тәрҗемә алымы да кулланылган (*қошлари жиддий чимирилди* – җөмләнең әлеге өлеше оригинал текстта юк, алым лексик-грамматик трансформация төрләреннән лексик өстәлүләр алымы булып тора).

*«Җанаш кайгысы – җан кайгысы инде ул!» [1: 70] – «**Париваш** бир **ҳур-маҳлиқо, ишқида** кўп қилди адо...» [53: 1981]* Әлеге тәрҗемәдә *«җанаш»* сүзе *«париваш» (пәридәй матур*), бир *«ҳур-маҳлиқо» (ай йөзле) «ишқида»* (*мәхәббәт*) сүзләре белән алмаштырылып килә. Моннан кала тәрҗемәдә оригинал җөмләнең структурасы да сакланмаган.

**Казакъ телендә:** *«Үзенчә, **мәтрүшкәсен-ниен** эчкәләп, ятып караса да, бер дә юнәеп китә алмый». [1: 8] – «Өзінше **ем-домын** жасап, **дәри-дәрмегін** (дарулар) ішіп, біраз жатып, байқастап көріп еді, онысынан шипа болмады». [3: 50] «Мәтрүшкә»* сүзе им-том һәм дарулар сүзләре белән алмашына.

*«Авырма инде, син – ялгыз **кортка**, карар кешең юк». [1: 9] – «Ауырма енді, сен – жалғыз жансың ғой, **кейуана**, қарасатын кісің жоқ». [3: 52]* Казакъ-рус онлайн сүзлегендә «кейуана» сүзенә түбәндәге ачыклама китерелә. *«Кейуана»* – почтенная старая женщина; мудрая и доброжелательная (о почтенной женщине); обращение к почтенной старой женщине. Тәрҗемәнең башка өлешләрендә дә әлеге сүз очрый: *«Ә син, **әбекәем**, тыныч кына ят. Терел.» [1: 15] – «Ал сен, **кейуана,** тыныш қана жата бер. Тез сақай». [3: 59]*

*«**Чәй урынын** карчык янына, сәке өстенә әзерләрделәр». [1: 18] – «**Шай дастарқаны** кемпірдің қасына сәкі үстіне жасалды». [3: 61] «Урын»* сүзе үзбәк телендәге кебек *«дастарқан»* сүзе белән алмаштырыла. Әсәрнең икенче урынында шул ук *«урын»* сүзе түшәк – *«төсег»* сүзе белән алмаштырыла.

*«Бу минем **күңелем түреннән** чыккан иң кайнар, иң зур, иң соңгы васыятем сезгә!» [1: 36] – «Бұл менің **жүрегімнен** ақ жалынға оранып шыққан ең ыстық, ең зор, ең соңғы өсиетім болмақ!» [3: 82] «Күңел» – «Жүрегім»* сүзләренең, алдагы мисалда кебек, лексик мәгънәләре тәңгәл килмәсә дә, тәрҗемә барышында контекстта алар синонимнар буларак кулланылырга мөмкин.

*«Һәр көнне иртән иртүк ул, **мотоциклның сиртмәле биленә атланып**, такыр юлдан пырылдап, тирбәлә-тирбәлә Сыртланга китеп бара, ә кич белән тагы шулай **җен кебек машинасында** тумырылып кайтып җитә иде». [1: 14–15] – «Her gün sabah motoruna biner, ses duman çıkartarak Sırtlan köyüne giderdi. Ve her gece **aynı cehennet arabasıyla** köye geri gelirdi». [5] «Мотоциклның сиртмәле биленә атланып»* гыйбарәсе төрекчәгә тәрҗемәдә төшеп кала. Ләкин икенче чагыштыруда бер компоненты үзгәртелеп тәрҗемә ителә, *«җен»* сүзе *«cehennet»* сүзе белән алмаштырыла җөмләнең гомуми мәгънәсенә зыян килми.

*«Сәетгали, килеп, **сәке** кырыена гына утырды...» [1: 15] – «Seyitgali geldi, **yatağın** kenarına oturdu». [5] «Сәке»* сүзе татар теленә хас, төрек телендә әлеге сүз юк, һәм әсәрнең тәрҗемә текстында ул *«yatağın»* – ятак сүзе итеп бирелә.

*«Ә залда **мәҗлес** матур гына дәвам итә». [1: 24] – «Salonda ise **kalabalık** devam ediyordu». [5] «Мәҗлес»* сүзе белән төрек телендәге *«kalabalık»* сүзләренең лексик мәгънәләре шактый аерылып тора. Мәҗлесне – әлеге очракта *кичә* дип аңлатып була. *Kalabalık* – ыгы-зыгы, халык төркеме дип тәрҗемә ителә.

Төрки телләр туганлык мөнәсәбәтләрендә булуга карамастан, менә инде шактый озак еллар дәвамында алар бер-берсеннән аерылып, башка телләр йогынтысы астында мөстәкыйль рәвештә көн күрәләр. Шунлыктан, бер үк күренешләр яки предметлар төрлечә аталырга мөмкин, яки киресенчә бер үк сүз, вакытлар узу белән, мәгънә төсмерен алмаштыра ала.

**Конкретлаштыру** – лексик-семантик трансформация төре. Әлеге күренеш вакытында – киң логик мәгънәгә ия булган чыганак телдәге лексик берәмлек тәрҗемәдә мәгънәсе таррак булган сүз яки сүзтезмә белән алмаштырыла. Әлеге трансформация төрен кулланган вакытта, чыганак тел берәмлеге белән тәрҗемә тел берәмлеге бер-берсе белән логик мөнәсәбәттә торырга мәҗбүр (чыганак тел берәмлеге – ыруглык төшенчәсе; тәрҗемә тел берәмлеге – төр төшенчәсе). Конкретлаштыру күренешендә беренчел структурага өстәмә дифференциаль мәгънә кушыла. Мисаллар:

**Үзбәк телендә**: *«**ялгыз ханым**» [1: 59] – «**бир хоним**» [4: 42]; «**бер мәл**» [1: 66] – «**бир дақиқача**» [4: 49]*. Конкретлаштыру алымы

бер генә сүзгә яки сүзтезмәгә карата кулланылудан тыш, җөмләләрне дә ачыклап килергә мөмкин. Мәсәлән: *«Ире аны уч төбендә генә кадерләп тота иде». [1: 60] – «**Хонимнинг еар-ичардан, кийимкечакдан камчилиги йук.** Эри уни кафтида кўтариб юрарди». [4: 43]* Әлеге мисалдан күренгәнчә, тәрҗемә текстта бер җөмләгә ике җөмлә туры килә һәм алдан килгән җөмлә күпмедер дәрәҗәдә икенче җөмләгә ачыклык кертә һәм конкретлаштыра.

*«Йомшак кына җәйге **җил** исә». [1: 7] – «Майда қоңыр жазғы **самал** желпіп тұр». [3: 49]* Казакъча *«самал»* сүзе – салкынча җил, рәхәт җил, бриз дип аңлатыла. *«Машина да машина, ә кешенең үз йөрәгенә, үз кулына **ни кала**?!» [1: 9] – «Makine ve makine, kişinin kendi kalbine, kendi eline **hangi işler kalıyor**?!» [5] «Ни»* сүзе тәрҗемәдә *«нинди эшләр»* дип **төрек телендә** конкртелаштырылып китерелә. Яки *«**Табын** әйләнәсенә утырыштылар». [1:18] – «**Çayın** etrafina oturdular». [5]* мисалында татар телендәге «табын» сүзенең мәгънәсе төрек телендәге *«Çayın»*ның мәгънәсеннән киңрәк булуы күренә.

Ә. Еники әсәрләренең тәрҗемәләрендә конкретлаштыру алымы күбрәк казакъ теленә тәрҗемә иткәндә кулланыла.

**Генерализация** – лексик трансформация төренең берсе, конкретлаштыру алымына капма-каршы күренеш, әлеге очракта сүз яки сүзтезмә тәрҗемәдә логик мәгънәсе киңрәк булган сүз яки сүзтезмә белән алмаштырыла. Тәрҗемә телдә чыганак телдәге төшенчәләргә туры килә торган конкрет төшенчәләр булмаган вакытта, генерализация алымын кулланырга мөмкин. Мисаллар: *«Ә зур кызы Пермь өлкәсенең эчкәре бер районында **балалар врачы** булып эшли...» [1: 25] – «Ал үлкен қызы Пермь облысының ішкергі бір ауданында **дәрігер** боп істейтін». [3: 69]* Тәрҗемәдә *балалар* сүзе төшеп кала. *«Дала буйлап **кылганнар** йөгерә, кылганнар йөгерә». [1: 7] – «Bozkırlarda **otlar** yuvarlanıyor». [5] Ot* сүзе төрекчәдән үлән дип тәрҗемә ителә. Яки *«Маен-күкәен дә шул көнгә дип җыя, итен-казылыгын да балаларым өчен дип каклый, **шомыртын**, эремчеген, кортын да шулар өчен киптереп куя». [1: 12] – «Yağını-yumurtasını da o güne diye topluyor. Etini kazıyı da çocuklarım için diye hazırlıyordu. **Meyvesini** de onlar için topluyordu». [5]* Әлеге очракта тәрҗемәче бер аерым җимешне гомуми җиләк-җимешләр сүзе белән алмаштырып тәрҗемә итә.

Генерализация алымы төрки телләргә тәрҗемә барышында сирәк кулланыла. Ул күбрәк Ә. Еники әсәрләренең төрек теленә тәрҗемәләрендә очрый. Бу татар теле белән төрек теле арасында шактый күп аерымлыклар булу белән аңлатыла.

**Модуляция** – (мәгънәле, логик үстерү) – лексик-семантик трансформация. Модуляция барышында чыганак телендәге сүз яки сүзтезмә тәрҗемә телдәге берәмлек белән алмаштырыла, ләкин әлеге очракта тәрҗемә телендә бирелгән берәмлекнең логик нәтиҗәсе чыганак телдәге берәмлеккә тиңдәш була. Тәрҗемә һәм чыганак телләрдәге берәмлекләр бер-берсе белән сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтендә торалар. Мисаллар: *«Юк, **аллә нишләде** бу замана!» [1: 8–9] – «Hayır,*

*zaman dediğimiz şey çok **değişti**». [5]* Әллә нишләде, димәк, үзгәрде – «*değişti*». Яки *«Биш-алты көн эчендә ул күзгә күренерлек булып суырылды, саргайды, **ашаудын калды**». [1: 14] – «Beş altı gün içinde gözle görünür şekilde zayıfladı, sarardı, **iştahı kesildi**». [5]* Төрек теленнән *iştahı kesildi* – аппетиты югалды дип тәрҗемә итәргә мөмкин.

Ә. Еники әсәрләренең төрки телләргә тәрҗемәләрендә модуляция алымының берничә урында гына кулланылуы ачыкланды.

Гомумиләштереп әйткәндә, төрки телләр уртак тамырдан барлыкка килгән булсалар да, аларның лексикасында билгеле бер тарихи вакыйгалар яки башка телләр йогынтысы астында яңа сүзләр пәйда була, алынмалар очрый. Бу тәрҗемәгә дә нык тәэсир итә, кайбер очракларда тәрҗемә процессын уңайлаштыра. Аерым очракларда эквивалент табу кирәк булмый, телнең лексик составына кереп, халык тарафыннан кабул ителгән сүз кулланыла. Ә. Еники әсәрләренең төрки телләргә тәрҗемәләрендә, трансформацияләрдән кала, башка тәрҗемә ысуллары һәм алымнары да (төшереп калдырулар, өстәүләр) кулланыла.

## Чыганаклар

[1] *Еники Ә.* Әсәрләр: 3 томда. Т. 2: Повестьлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 415 б.

[2] *Еники Ә.* Йөрәк сере: повестьлар. Өфе: Башкорт. кит. нәшр., 1963. 301 б.

[3] Татар повестері. Алматы: Жазушы баспасы., 1979. Б. 49–93.

[4] Йиллар ва йўллар: Татар ёзувчиларининг ҳикоялари. Адабиёт ва санъат нашриёти, 1981. 288 б.

[5] *Eniki E.* Söylenememiş vasiyet [Электрон ресурс]. http://ekitap.kulturturizm.gov.tr/Eklenti/12259,emirhanenikipdf.pdf?0

## Әдәбият

*Габдулхакова И.М.* Образные сравнения в произведениях А. Еники и их перевод на русский язык // Вестник Челябинского государственного университета, 2007. URL: https://cyberleninka.ru/article/n/obraznye-sravneniya-v-proizvedeniyah-a-eniki-i-ih-perevod-na-russkiy-yazyk (мөрәҗәгать итү вакыты 23.06.2019)

*Галиева А.М., Нагуманова Э.Ф.* Особенности перевода пейзажных зарисовок (на материале произведений А. Еники и их переводов) // Zbior raportow naukowych Aktualne problemy w wspoliczesnej nauki. 26.06.2013–30.06.2013. Czesc 5. Warszawa, 2013. С. 102–110.

*Комиссаров В.Н.* Введение в переводоведение. М.: Валент, 1990. 368 с.

*Юсупов Р.А.* Тәрҗемә һәм сөйләм культурасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 240 б.

***Денмөхәммәтова Эльвира Николай кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты доценты*

***Гәрәева Резеда Харис кызы,***
*Казан шәһәре иҗтимагый үзәге редакторы*

УДК 811.512.145′373

*Ә.К. Булатова*

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ СЕМАНТИК ДИАЛЕКТИЗМНАР

В данной статье мы рассмотрим семантические диалектизмы, которые функционируют в говорах татарского языка. Выявление такого типа диалектальных слов, их научное изучение представляет немаловажное значение для раскрытия картин развития татарской лексики.

**Ключевые слова:** татарская диалектология, татарский язык, говор, лексика, семантические диалектизмы, лексикология, полисемия, омонимия.

In this article we will consider semantic dialectisms that function in the dialects of the Tatar language. Revealing this type of dialectic words, their study is of great importance for the disclosure of development picture of the Tatar language.

**Keywords:** Tatar dialectology, Tatar language, dialect, vocabulary, semantic dialectisms, lexicology, polysemy, homonymy.

Әдәби телдәге сүзләр белән әйтелеше бер, әмма мәгънәләре аерымланган диалектизмнарның саны байтак. Әлеге төр лексик берәмлекләр семантик диалектизмнар дип атап йөртелә [Словарь…, 200, с. 88; Рамазанова, 2008, с. 54; Махмутова, 1978, с. 138; Булатова, 2008, с. 74]. Мәсәлән, урта диалектның балтач, минзәлә, бөре, пермь, нократ, богырыслан, златоуст сөйләшләрендә *тупса* сүзе әдәби телдә ‘ишек-тәрәзәнең, гомумән, ике әйберне ачылып-ябылып, җыелып-язылып йөрерлек итеп беркетә торган һәм уртасында күгәре булган җайланма’ [ТТАС, 1981, б. 168] мәгънәсендә кулланыла, диалектларда исә ‘бусага’ лексик-семантик вариантында файдаланыла: *Ишек* ***тупсасына*** *утырганыга йарата бу* [ТТЗДС, 2009, б. 358]. *Бусага* (әдәби телдә – ‘ишек яки тәрәзәнең аскы, яткырып салган борысы’ [ТТАС, 1977, б. 194]) мишәр диалектының ләмбрә сөйләшендә – ‘яшь киленнең беренче кергәндә бирә торган бүләге’: *Ике чын кизе ыштан хәзерли, кайынанага да* ***бусагага*** *да* [ТТЗДС, 2009, б. 139]. *Бүлмә* сүзе номинатив мәгънәдә ‘өйнең, стена белән яки бүтәнчә аерып эшләнгән өлешләренең берсе’ [ТТАС, 1977, б. 221]: *Мин аш* ***бүлмәсенә*** *кердем*. Урта диалектның минзәлә, каргалы сөйләшләрендә ‘чолан’ мәгънәсендә дә кулланыла: *Безнең* ***бүлмә*** *йуг, әнә келәт (*минзәлә сөйләше) [ТТЗДС, 2009, б. 142].

Мисалга китерелгән лексемалар татар диалектларында диалекталь сүз ясалышы, шулай ук әдәби тел сүзләренең семантик деривациясе нәтиҗәсендә барлыкка килергә мөмкин [Сагдеева, 2019, с. 131]. Бу уңайдан шуны да искәртеп китү урынлы булыр, әлеге төр лексемалар татар диалектларының аз өйрәнелгән берәмлекләре булып кала.

Семантик диалектизмнарны тикшерү татар теленең аңлатмалы сүзлекләренә һәм «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге» материалларына нигезләнеп алып барылды.

Әдәби тел лексемаларыннан аермалы буларак, әлеге диалекталь сүзләр киңрәк семантик детальләштерү үзлегенә ия [Хусаинова, 2016, с. 367.] «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»ндә күпсанлы семантик диалектизмнар теркәлгән. Лексиконда әлеге сүзләр үзләренең гомумтел мәгънәләрендә билгеле, әмма шул ук вакытта сөйләшләрдә диалекталь семалары да кулланыла. Шуны искәртү зарур, аларның әдәби телдә һәм сөйләшләрдә кулланылышы диалекталь омонимия күренеше буларак тасвирлана ала. Әлеге лексемалар арасында гомуми мәгънә төсмерләре булмый диярлек. Мәсәлән, әдәби телдә *алма* сүзе түбәндәге мәгънәдәләрдә файдаланыла: 1) ‘алмагачның җимеше’; 2) ‘күзнең түгәрәк рәвешендәге урта өлеше, үзәге’; 3) ‘хайваннарның тиресендәге төп төс өслегендә ак яки кара, күгелҗем һ. б. түгәрәк тап барлыкка китергән йон төкләре’; 4) ‘алмагач’; 5) ‘яраткан, сөйгән ярга эндәшү сүзе’ [ТТАС, 2015, б. 142]. Мишәр диалектының темников, ләмбрә, чистай, сергач, күршә сөйләшләрендә, шулай ук урта диалектның балтач, нократ сөйләшләрендә сүз ‘бәрәңге (бүлбеләре)’ (синонимик вариантлары – *картау, йералма, җиралма, бәрәңке, картоф, картуф*) семасында кулланыла [ТТЗДС, 2009, б. 39]. Татар телендә бәрәңгенең җимешләрен дә *алма* (*бәрәңге алмасы*) дип атыйлар.

*Иген* күп мәгънәле лексик берәмлеге гомумхалык телендә түбәндәге лексик-семантик вариантларга ия: 1) ‘орлыкларыннан он, ярма әзерләнелә торган бөртекле, кузаклы яки техник культура’; 2) ‘шул үсемлекнең орлыгы; ашлык’; 3) ‘шундый культура үсеп утыра торган басу’; 4) ‘иген үстерү эше, игенчелек’[ТТАС, 2016, б. 443–444]. Тубыл-иртыш диалектының түмән сөйләшендә ‘төп йорттан читтә булган бакча’ мәгънәсендәге семантик диалектизм урын алган. Әстерхан татарлары сөйләшендә сүз ‘яшелчә’ семасында кулланыла [ТТЗДС, 2009:, б. 205].

*Инеш* сүзе ‘кечкенә, тар һәм сай елгачык’ны аңлата [ТТАС, 2016, б. 546], тубыл-иртыш диалектының тубыл сөйләшендә исә сүз ‘керү урыны, ишек’ мәгънәсенә ия [ТТЗДС, 2009, б. 211].

*Аш* сүзенең семантик структурасы түбәндәге лексик-семантик вариантларны берләштерә: 1) ‘нинди дә булса юл белән (пешереп, кыздырып), ашау өчен махсус әзерләнгән ашамлык, азык’; 2) ‘гомумән нинди дә булса ашарга яраклы ашамлык; ризык, азык’; 3) ‘беренче итеп бирелә торган шулпалы ризык’; 4) ‘гомумән ашау, ризык кабул итү процессы’; 5) ‘кунак мәҗлесе’ [ТТАС, 2015, б. 273]. Сүз мишәр диалектында ‘камыр ризыклары’, казан арты сөйләшендә ‘төп кодаларның туй күчтәнәчләре (ризыклар)’ мәгънәсенә ия, себер диалектларында ‘токмач’ семасында кулланыла [ТТЗДС, 2009, б. 67]. Әдәби тел һәм диалектларда файдаланылучы лексик-семантик вариантларны ‘ризык, ризык кабул итү’ уртак семасы берләштерә. Алда күрсәтелгән мисаллар белән чагыштырсак, алар өлешчә мәгънә төсмерләре белән генә аерылалар. Уртак мәгънә саклану полисемия (күпмәгъәлелек күренеше) урын алганлыгын дәлилли.

Татар теленең себер диалектларында әлеге сүз белән ашлыкны атыйлар, эчкен сөйләшендә ‘иген’ мәгънәсе дә бар [ТТЗДС, 2009, б. 68].

Тубыл-иртыш сөйләшендә аш сүзе ‘эрен’ мәгънәсендә кулланыла [ТТЗДС, 2009, б. 68]. Бу очракта, алда күрсәтелгән мәгънәләр арасында уртак семалар булмау сәбәпле, диалекталь омонимия урнашкан дип әйтә алабыз.

*Балдак* – 1) ‘халыкара мифологиядә мәңгелек, берлек-бердәмлек, ышаныч, хакимият һәм көч символы’; 2) ‘бизәнү әйбере буларак, бармакка киелә торган кашсыз йөзек’; 3) ‘гомумән һәртөрле йөзек’; 4) ‘техникада һәм көнкүрештә кулланыла торган алка; боҗрага охшашлы деталь’; 5) ‘боҗра, йомры түгәрәк, әйләнә’ [ТТАС, 2015, б. 396]. Сүз диалектларда үзгә семантикага ия. Хвалын, мәләкәс, кузнецк, шарлык сөйләшләрендә куныч, балтырны аңлата, Калда авылы сөйләшендә ‘чалбар балагы’ семасы да бар [ТТЗДС, 2009, б. 99].

*Диңгез* әдәби сүзе ‘дөнья океанының коры җир, су асты калкулыклары белән әйләндереп алынган бер өлеше’ номинатив мәгънәсендә кулланыла [ТТАС, 2016, б. 178]. Шулай ук ‘күп урын, зур мәйдан биләп торган, күплекне белдергән объект’ күчерелмә мәгънәсе дә киң файдаланыла. Минзәлә, бөре, мамадыш, пермь, златоуст сөйләшләрендә түбәндәге семалы күп мәгънәле семантик диалектизм теркәлгән: 1) ‘нигез, өйнең фундаменты’; 2) ‘кышка каршы өйнең тышкы ягына туфрак, кибәк һәм саламнан өелә торган нигез’; 3) ‘төп йорт, туып үскән йорт’ [ТТЗДС, 2009, б. 168].

Сөйләшләрдә семантик диалектизмнар барлыкка килү берничә этаптан тора дип фаразлый алабыз: билгеле мәгънәләрдән тыш гомумтел лексик берәмлекләренең өстәмә диалекталь семасы урнаша; соңыннан әдәби телдәге сүзнең мәгънәсе яңача күзаллана һәм семантик диалектизм барлыкка килә; аннан соң аларда күпмәгънәлелек урнашырга мөмкин.

Югарыдагы күзәтүләрдән шундый нәтиҗә ясарга мөмкин: татар сөйләшләрендә әлеге төр лексемаларның саны шактый; аларның килеп чыгышы аерым ареалда кулланылучы сүзнең семантикасы үсешенең үзгәлеге белән аңлатыла ала. Семантик диалектизмнарның лексик мәгънәләре җирле колорит белән баетылган һәм географик яктан урнашу, тормыш шартлары, гореф-гадәтләр, көнкүреш үзенчәлекләре белән аерылып тора.

**Әдәбият**

*Апресян Ю.Д.* Лексическая семантика. Синонимические средства языка. М.: Наука, 1974. 259 с.

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. Казан: Мәгариф-Вакыт, 2015. Т.1. 543 б; Т.2. 567 б.

*Булатова А.К.* Полисемия в современном татарском литературном языке. Казань: ИЯЛИ, 2018. 108 с.

*Махмутова Л.Т.* Опыт исследования тюркских диалектов: (мишарский диалект). М.: Наука, 1978. 271 с.

*Рамазанова Д.Б.* Вопросы татарской диалектологии. Казань: Алма-Лит, 2008. 271 с.

*Рамазанова Д.Б.* Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. 192 с.

*Розенталь Д.Э., Теленкова М.А.* Словарь-справочник лингвистических терминов. Изд. 3-е. М.: Просвещение 1985. 399 с.

*Сагдеева Ф.К., Хусаинова А.Я., Булатова А.К.* Ключевое слово культурного концепта // Казанская наука. № 2. 2019. С. 130–132.

Татар лексикологиясе: 3 томда / авт.: М.З. Зәкиев, Г.Р. Галиуллина, Р.Ф. Фәттахова, Ә.К. Булатова / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. 1. 352 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты нәшрияты, 2005. 848 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 6 томда. Казан: ТӘҺСИ, 2015. Т. 1. 712 б.; Т2. 2016. 748 б.; Т.3. 2017. 744 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. / төз.: И.А. Абдуллин, Г.Х. Ахунҗанов, Ф.М. Газизова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. Т. 1. 475 б.; Т. 2 / төз.: И.А. Абдуллин, Г.Х. Ахунҗанов, С.Б. Вахитова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 726 б.; Т. 3 / төз.: И.А. Абдуллин, С.Б. Вахитова, Ф.М. Газизова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 832 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз. Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

*Хусаинова А.Я.* Особенности изучения татарских переселенческих говоров // Сохранение и развитие родных языков в условиях многонационального государства: проблемы и перспективы материалы VII Международной научно-практической конференции. 2016. С. 366–369.

***Булатова Әлфия Кәрим кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

*А.З. Хәбибуллина*

# ЧАГЫШТЫРМА ПОЭТИКА КАТЕГОРИЯСЕ БУЛАРАК ЖАНР
## (рус һәм татар әдәбиятлары мисалында)

В статье категория жанра рассматривается в свете концепции сопоставительной поэтики. Установлено, что поэтика, возникшая в поле сопоставительных дискуссий, исследует уникальные черты жанров, подчеркивает возможность их согласия между собой в пространстве диалога литератур. Фактическую основу образуют произведения Г. Тукая «Оборвалась нить священных четок» (1910) и И.С. Тургенева «Мне жаль…» (1878). Сделан вывод о многожанровой и полидискурсивной основе художественного восприятия Г. Тукаем личности Л. Толстого. Главным образом оно происходило из тех мировоззренческих смыслов жанров (касыда, нэсер), разных по форме (прозаические и стихотворные) и типов дискурса, в которых сфера субъективных переживаний поэта не противопоставлялась природе, выражаемой действительности.

**Ключевые слова:** сопоставительная поэтика, корреляция жанров, нэсер, стихотворение в прозе, касыда, мемориальная лирика, диалог.

The article reveals the category of genre in the context of comparative poetics. It is stated that poetics appeared in the field of comparative discussions studies unique genre features, points out the possibility of their correlation in space of the literary dialogue. The actual basis is formed by the analysis of G. Tukai's works «The thread of the sacred rosary broke» (1910) and I.S. Turgenev's «I'm sorry...» (1878). The conclusion is multi-genre and multi-discourse basis of G.Tukai’s artistic perception of Tolstoi. This mainly came from those meanings of genres (kasyda, naser) different in their forms (prosaic and poetic) and discourse types in which the sphere of subjective poet’s experiences wasn’t opposed to nature, expressed reality.

**Keywords:** comparative poetics, correlation of genres, naser, prose poem, kasyda, memorial lyrics, dialogue.

Хәзерге филологиядә жанрларны чагыштырма поэтика ноктасыннан өйрәнү – фәнни тикшеренү эшендә шактый яңа өлкә. Ул тарихи һәм теоретик поэтикадан аерыла. Бу турыда галимә В.Р. Әминева болай дип яза: «для нее [сопоставительной поэтики – *А.Х.*] особенно важны два методологических принципа: «вненаходимости» по отношению оказывающимися в диалоге литературам, т. е. внешне объективной точки зрения, с одной стороны, и «внутринаходимости» по отношению к каждой из них – с другой, что достигается разными способами, например, с помощью эмпатических процедур психологической герменевтики (сопереживание, сочувствие, понимание)» [Аминева, 2018, с. 6–7].

Чагыштырма поэтика тикшеренү даирәсенә кертелгән һәр әдәбиятның үзенчәлеген саклауга юнәлдерелгән чагыштыру методы кагыйдәсенә нигезләнә. Я.Г. Сафиуллин фикеренчә, «сопоставление, – более всего занято различиями в разных литературах, взаимодействиями на уровне различий. Проблемой взаимной дополнительности. Общее в таком случае не цель, не единство в общепринятом смысле слова, в котором разные культуры должны слиться в одно, а постоянный диалог» [Сафиуллин, с. 176–177].

Нәкъ менә уникальлек, ягъни диалогта катнашкан һәр әдәбиятның үзгә, кабатланмас сыйфатлары белән бәйле өлкә жанр категориясен, бигрәк тә жанрларның үзара бәйләнеше мәсьәләсен, әдәбиятара киңлектә аларның булуы мөмкин *корреляциясен* бигрәк тә актуальләштерә. Соңгысы төрлечә барлыкка килә: мәсәлән, укучылар рецепциясе өлкәсендә (биредә ул жанрларның «бәрелешү»н, чит телдәге әдәбиятны кабул иткәндә, аларның «берсе өстенә берсе менү»н белдерә), тәрҗемәче аңында, шулай ук махсус (шул исәптән жанрлар поэтикасы белән бәйле) фәнни тикшеренүләр сферасында.

Чагыштырма поэтика күзлегеннән жанрга мөрәҗәгать итү очраклы түгел. Жанр, универсаль категория буларак, бер яктан, теоретик конструкт булып тора. Ю.И. Тюпа язганча, «образует некоторое «поле стабилизаций» для принадлежащих к нему единичных произведений» [Тюпа, с. 35]. Икенче яктан, әдәбиятлар диалогында гадәти жанр үзгәрә, төрле милли фикер һәм «дөнья картиналары» үзара тәэсир итешкәндә, аңа «җан керә».

Жанрны болай аңлау теоретик фәндә киң билгеле (Ю.Н. Тынянов, О.М. Фрейденберг, Г.Д. Гачев). Әлеге күзлектән чыгып караганда, жанр сәнгати иҗат һәм аны зиһенгә алуның формаль элементлары җыелмасы гына түгел, ул *халыкның милли үзтәңгәллек* хасиятләрен, аның «дөнья образы»н, мәдәният, фикерләү үзенчәлекләрен үзендә туплый. Г. Гачев сүзләренә караганда, «при встрече очень различных национальных культур как раз и обнаруживается, что главная трудность – понять, как мыслит другой народ и, *лишь осилив жанр, структуру мысли, можно понимать ее предмет*» (ассызык безнеке. – *А.Х.*) [Гачев, с. 35].

Шул рәвешле, чагыштырма дискуссияләр кырында пәйда булган поэтика жанрларның уникаль үзенчәлекләрен тикшерә, «янәшә яшәү» мөмкинлеген, диалоглар киңлегендә үзара бердәмлеген ассызыклый. Әйтик, рус һәм татар әдәбиятларында кече һәм уртача формалы күп кенә жанрларга гомумсыйфатлар хас: чәчмә шигырь (стихотворение в прозе) һәм нәсер, өземтә (*отрывок*) һәм кыйтга, элегия һәм газәл. Шуның белән бергә тикшеренүләрдә аларның бер-берсен алыштыра алмавы раслана. Диалогларда алар «яңа» структуралар белән баеп, мәгънәви уникальлеген, милли традицияләргә бирелгәнлеген саклый.

Жанрлардагы «уртаклык» (нинди дә булса әдәби төргә карау, яшәү формасы (чәчмә, шигъри), перформатив охшашлык, жанрда

аеруча якланган гомумкешелек кыйммәтләре) уникальлек, аерымлыклар эзләүгә ниндидер бер этәргеч бирә[1].

Әйтик, әгәр «бер үк предмет», ягъни төрле әдәбиятлардагы «гомумсыйфатлар» дигәндә, жанр эчендәге (форма көнкүрешне һәм кешене үзләштерү рәвеше буларак) ниндидер дөньяга караш идеяләре комплексын күз алдында тотсак, аның төрле, башка әдәбиятларда таркау вариантларда гамәлгә ашырылган сәнгати формалары булырга мөмкин.

Мәсәлән, XX гасыр башы татар әдәбиятындагы кыйтга жанрының инвариант үзенчәлеге буларак, яшәешнең өзек-өзеклеге, фрагментарлыгы турындагы күзаллау XIX гасыр рус романтик поэзиясендәге өземтә жанры белән яраша. Кыйтгада билгеле бер дөньяга карашның нигезе булып хезмәт иткән гомумкешелек кыйммәтләре рецептив аң өчен туган телдәге әдәбият һәм нәфасәти тәҗрибәдәге (дөньяга караш ягыннан – якын, универсаль идея белән охшаш ) сәнгати формаларны яңартуга «сигнал» була.

Шулай итеп, яшәешнең «кыйпылчыклардан торуы», дөньяның фрагментарлыгы турындагы күзаллаулар рус һәм татар әдәбиятларында бер-берсенә туры килә. Соңгысы югарыда аталган кече формаларны үзара бәйләнештә карарга, шулай ук аларның ярашуын тәэмин итүче ниндидер бер абстракт механизмны ачыкларга ярдәм итә. Эчке формалары төрле булса да, аларны мәңгелек идеясе, яшәеш фрагменты буларак дөньяга караш берләштерә. Югарыда бәян ителгән теоретик нигезләмәләрне мисаллар белән ныгытыйк.

Г. Тукайның 1910 елда иҗат ителгән «Мөбарәк тәсбих өзелде» әсәрен алыйк. Ул – ритмик проза үрнәге. Бу турыда шагыйрь эпиграфта үзе дә яза: «Ушбуны яздырды нәсрән вөҗданымның көчләве, / Мәсьәлә бик зур – сыйдырмый тар шигырьләр үлчәве» [Тукай, 1985, т. 2, б. 41].

Әлеге әсәрнең ни рәвешле рус һәм Европа әдәбиятларындагы чәчмә шигырь белән ярашуын күзәтик. «Ярашкан» очракта аларның бер-берсен алыштыра алулары турында, шулай ук төрле әдәби һәм тел системаларында булып, милли һәм мәдәни бердәйлек сыйфатларын, һәр сәнгати формага хас «фикер төзелеше»нең уникальлеген югалтмыйча, бер телдән икенчесенә тәрҗемә итү хакында сүз алып барырга мөмкинме?

Шунысын билгеләп үтәсе килә, бу әсәр күпсанлы фәнни тикшеренүләрнең предметына әверелде (И.З. Нуруллин, О.Х. Кадыйров, Д.Ф. Заһидуллина, Р.К. Ганиева, Г. Халит һ. б.). Әмма аларда жанр аспекты җитәрлек өйрәнелмәгән. Моннан тыш, миниатюраның жанр үзенчәлеген төгәл һәм ныклы аңлату да юк («Мөбарәк тәсбих

[1] Жанрлардагы чагыштырма поэтика концепциясендә мондый мөнәсәбәт күп яктан лингвистикада сүзнең эчке формасы идеясе белән үзара бәйләнештә була. Ул В. фон Гумбольт, А.А. Потебня карашларында үсеш ала. Лингвистика теориясе буенча, бер үк предметны атаган сүзләрдә төрле эчке форманы очратырга мөмкин.

өзелде»). Димәк, аны нәсер, элегия, чәчмә шигырь кебек билгеле формалардан да аермыйлар.

В.А. Гордлевский үзенең «Тукай и русская литература» дигән мәкаләсендә әлеге әсәрне чәчмә шигырь итеп карый, шуның белән бергә галим чагыштыру өчен Державинның «На рождение в Севере порфирородного отрока» дифирамбын фон сыйфатында файдалана» [Гордлевский, с. 527]. О.Х. Кадыйров аны «чәчмә элегия» һәм чәчмә шигырь белән чагыштыра [Кадыров, с. 132]. И.З. Нуруллин «Тукай» монографиясендә Тукайның миниатюрасын мәкалә дип атый.

Татар әдәбияты классигы сайланма әсәрләренең тулы басмасына (2011) аңлатмаларда «Мөбарәк тәсбих өзелде» әсәренең нәсер булуы әйтелә: «Мөбарәк тәсбих өзелде» – нәсер, хәзерге төшенчә белән әйткәндә, чәчмә шигырь. Формасы, башлам рефреннары, аллегория, метафора, сынландыру, эчке рифма, сурәтле сүзләр – барысы да шигырь арсеналыннан» [Тукай, т. 2, б. 339].

Әйтелгәннәрдән күренгәнчә, татар әдәбият белемендә Г. Тукайның киң билгеле әсәре жанры турындагы мәсьәлә ачыкланып бетмәгән; төрле милли әдәбиятларда Тукайның Толстой шәхесенә мөнәсәбәте нигезенә яткан жанрларның гомологик рәтләре өйрәнелмәгән. Рус һәм Көнбатыш Европа әдәбиятларының бер формасы буларак, чәчмә шигырь жанры поэтикасына кыскача гына тукталып узыйк.

Ю. Орлицкий хезмәтендә әйтелгәнчә, әлеге жанрны тудыруда *версе* зур әһәмияткә ия. Ул болай дип яза: «Мы понимаем версе как строфически организованную (как прозаические переводы Библии) стихоподобную прозу, характеризующуюся малым объемом всех или подавляющего большинства строф, примерным равенством размера этих строф с тенденцией большинства из них к совпадению с одним предложением» [Орлицкий, с. 180–181]. Строфаларның күләме ирекле һәм «бары тик мәгънәви яктан гына аерып куелган» «традицион» прозадан гына аермалы буларак, версе прозасы үзенә генә хас конструктив вазифа башкара: «служит созданию в прозе стихоподобного вертикального ритма, возникающего в результате сопоставления соседних строф» [Орлицкий, с. 181].

Версе прозасының үрнәге, – мәсәлән, И.С. Тургеневның «Мне жаль…» әсәре (февраль, 1878).

«Мне жаль самого себя, других, всех людей, зверей, птиц… всего живущего.

Мне жаль детей и стариков, несчастных и счастливых… счастливых более, чем несчастных.

Мне жаль победоносных, торжествующих вождей, великих художников, мыслителей, поэтов…

Мне жаль убийцы и его жертвы, безобразия и красоты, притесненных и притеснителей.

Как мне освободиться от этой жалости? Она мне жить не дает… Она – да вот еще скука.

О скука, скука, вся растворенная жалостью! Ниже спуститься человеку нельзя.

Уж лучше бы я завидовал… право!

Да я и завидую – камням» [Тургенев, т. 2, с. 174].

Тургенев әсәре кечкенә күләмле булуы белән аерылып тора – шигырьдәге кебек, һәр юлы – бер җөмлә. Тышкы яктан да, формасы, эчтәлеге белән дә, анафорага нигезләнгән ритмы аркасында да (беренче дүрт җөмлә, строфа кебек, «Мне жаль» сүзләре белән башлана) ул лиризмга бай һәм хиссиятле шигырь буларак кабул ителә. Биредә лирик сюжет юк, әсәр ниндидер медитатив үзлеккә ия, анда субъектның позициясе («фикере») ачык тоемлана: ул бөтен тереклек дөньясын кызгана: кеше тормышының барлык формаларында әрнү, газаплану бар, аларны читләтеп үтү бик авыр. Күңеле курку хисе белән тулган герой үзенең монологын «Да я и завидую камням» дигән сүзләр белән тәмамлый, алар аны газапларыннан арындыра, ташвишле аңны «азат итә» кебек. Чәчмә шигырьдәге антитеза (кешеләрнең кызгануы – ташларның сүзсез шәфкатьсезлеге) әсәрне фәлсәфи дәрәҗәгә күтәрә, анда кеше генә хәл итә алмаган экзистенциональ сайлау иреге (кешене кызгану яисә ташлар кебек битараф калу) зур эмоциональ көч белән җәелдерелә.

Әсәрнең интонацион корылышы да кызыклы: анда, анафорадан тыш, финал өлешендә икеләтә тавыш, сорау билгесе һәм паузалар бар. Мондый билгеләр субъектның катлаулы кичерешләр дөньясын, аның өзек-өзек сөйләмен бирергә ярдәм итә, алар лирик шигырьдә геройның көчле хисләре белән үрелә.

Әгәр Тукай шигыренә мөрәҗәгать итсәк, аңа тулаем алганда версе (кыска) строфа хас түгел. Күләме кечкенә булуга, үзе версега якын, шигырьне хәтерләткән аерым юлларга бүленүгә карамастан, биредә версе, мәсәлән, И.С. Тургенев иҗатындагы(«Sinilia») кебек чагылыш тапмый.

Тукай шигырендәге озын юллар тышкы яктан күбрәк бәетне (икеюллыкны) хәтерләтә. Ә бәеттә фикер – бөтен, шигырь мәгънә ягыннан тәмамланган була. «Мөбарәк тәсбих өзелде» шигырендә график бушлыклар («функциональ» паузалар) юк, һәр җөмлә тәмамланган фикерне белдерә, аны *рифма* көчәйтеп җибәрә: ул җөмләнең дә (эчке рифма), тулаем әсәрнең дә аерым өлешләрен үзара бәйли.

«Бу ел ноябрь ае керде. Ләкин Русия кояшы бүтән еллардагыча нурын *киметми*, дөнья йөзенә чыраен сытып, салкынлык бирергә *ашыкмый*.

Бу ел ноябрь ае керде. Русиянең агар сулары *бозланмый*, һаман ага да ага.

Бу ел ноябрь ае керде. Ләкин Русия көз көненә махсус ачы вә үзәк өзгеч җилләр *исми*.

Бу ел ноябрь ае керде. Ләкин кыйбла якның кошлары *китми*» [Тукай, т. 2, б. 143].

Әлбәттә, элеге өзектә без якынча эчке рифма турында гына сүз алып бара алабыз: *киметми – ашыкмый. «Бозланмый» – «[җилләр] исми» – «[кошлары] китми»* дигәндә, үзара бәйләнгән юллардагы сүзләрнең ахыргы өлешләре бертөрлерәк яңгырый. Бу шигырьгә бөтенлек һәм мелодик ритмлылык өсти.

Г. Тукайның «Мөбарәк тәсбих өзелде» әсәрендә (автор үзе үк аның проза белән язылуын ассызыклый) нинди чаралар, поэтиканың нинди алымнары ярдәмендә чәчмә шигырь ритмына туры килгән *ритм* барлыкка килә, дигән сорау туа. Әгәр ритмлы прозада җөмләләр традицион озынлыкта икән (кыска, версе түгел), шигырь ритмы туганда метрик «күрсәткечләр» (шигырь озынлыгы) түгел, ә прозага хас (әсәрнең сурәтлелеге һәм аһәңлелегенә караган) сыйфатлар мөһим роль уйный, дип фараз кылыйк.

Г. Тукайның элеге шигырендә, рифманың бер төре буларак, *анафоралы аллитерация* катнаша: прозаик текст тулаем шуның белән сугарылган. Ассонанс белән бергә (әсәрдә «у», «е», «а», «о» авазлары ассызыклана) ул язучының үлеме турындагы фаҗигале хәбәр килеп ирешер алдыннан «катып калган, җансыз» табигатьтәге алмашынуларны, хәрәкәтне көчәйтеп җибәрә.

*«Бу ел ноябрь ае керде*. Ләкин Русия кояшы бүтән еллардагыча нурын киметми, дөнья йөзенә чыраен сытып, салкынлык бирергә ашыкмый.

*Бу ел ноябрь ае керде.* Русиянең агар сулары бозланмый, һаман ага да ага.

*Бу ел ноябрь ае керде.* Ләкин Русия көз көненә махсус ачы вә үзәк өзгеч җилләр исми.

*Бу ел ноябрь ае керде.* Ләкин кыйбла якның кошлары китми.

*Бу ел* табигатькә ят бер хәл вакыйгъ булган. Бер олугъ һәлакәт булачагын алдан сизгән җанварлар кеби, галәме табигать тирән бер хәвеф вә дәһшәт эчендә.

Тавыш та, тын да юк!

*Бу* тугърыда халык уйлый, аптырый. Ләкин бу хәлнең сәбәбен белә алмый.

*Бөтен* җанварларның җаны вә бөтен инсаннар вөҗданы кадерле вә бәһале Толстой җәнабләре түшәктә!» [Тукай, т. 2, б. 143].

Җөмләләр башында ассонанс һәм аллитерация проза текстын «рифмалаштыра»: аның күреп кабул итү өчен катлаулы картинасын «тәгәлләп куя» һәм «җан өрә» кебек. Авазларның кабатланып килүе киеренке шомлылык интонациясе барлыкка китерә. Әйтерсең, акрын гына бөдрәләнеп аккан елганың хәрәкәте табигатьтәге бөтен тереклек дөньясына – кояштан елгаларга, салкын җилләргә, кошларга бирелә: Бу аспекттан караганда, әсәрнең икенче юлы бигрәк тә уңышлы:

«Бу **е**л ноябрь **а**е к**е**рд**е**. Русиян**е**ң **ага**р сул**а**ры бозл**а**нмый, һ**а**м**а**н **ага да ага**» [Шунда ук, б. 143].

«Русия кояшы» һәм салмак аккан су образы белән янәшә «а» һәм «е» авазларын көчәйтү эчтән генә, әмма бик нык елау, ярсу халәте

тудыра. Ул тынлыкка чумган һәм бөек граф Толстойны сагынган биниһая зур дөньяның эченнән чыга кебек. О.Х. Кадыйров Г. Тукай әсәренең бу өлеше турында түбәндәгечә яза: «именно потому, что дух Толстого адекватен лишь могучим силам природы, и оказалось возможной трагедия всеобщего, космического масштаба, картину которой нарисовал Тукай» [Кадыров, с. 135].

Г. Тукай әсәренең мондый поэтикасы аны нәсергә – фонетик алымнар (звукопись), лиризм, ачык ритм зур әһәмияткә ия жанрга якынайта.

Г. Тукайның «Мөбарәк тәсбих өзелде» әсәрендә Толстой образын тудыруда Шәрык поэзиясендәге панегирик формаларның берсе булган касыйдәнең[1] дә тәэсире зур. Г. Тукай әсәренең фаҗигале темасы күп яктан аның касыйдә жанры һәм татар шагыйренең мемориаль лирикасы белән үзара бәйләнешен билгеләүгә сәбәп була[2].

Аерым алганда, Г. Тукай миниатюрасы белән күренекле азәрбайҗан шагыйре һәм мәгърифәтчесе М.Ф. Ахундовның фарсы телендә язылган «Пушкинның үлеме уңаеннан» (1874) дип исемләнгән касыйдәсе арасында охшашлык күрергә мөмкин.

«Мөбарәк тәсбих өзелде» кебек үк, М.Ф. Ахундовның касыйдәсе дә Шәрык поэтикасына туры китереп язылган, ул төрле халәтләрнең – табигатьнең (чәчәкләр, кошлар, әкрен искән җил) хуш исләр аңкыткан матурлыгы белән Пушкинның фаҗигале үлеменнән соң шагыйрь йөрәгендәге тирән сагышның – капма-каршылыгына (антитеза) корылган:

«Поля украшены жасмином, и влюбленный
Нарцисс глаза раскрыл, бессонные от грез.

И в ключе соловья для всех гостей подарки –
Несет он лепестки ему внимавших роз.

---

[1] А. Тамимдари билгеләмәсе буенча, «касыйдә» сүзе «ният» яисә «максат» мәгънәсенә ия, әмма әдәбиятта ул билгеле бер ният белән язылган шигырьне белдерүче терминга әйләнгән. Өстәвенә иң башта кемгәдер дан җырлау турында сүз бара» [Тамимдари, с. 152]. Панегирик мәдхия касыйдәнең төп өлешен тәшкил итә. Биредә шагыйрь, мактау җырланачак затны эпик баһадир итеп күзаллап, эпик жанрга тартыла [Шунда ук, б. 155]. Татар әдәбиятында Котб, Мөхәммәдьяр, Г. Чокрый иҗатларында, – дип яза Х.Й. Миңнегулов, – «мәдхия (гарәп. ода, мактау) – Шәрык әдәбиятларындагы ода жанры киң тарала. Мәдхияләрнең күбесе шигъри формада (бәетләр, дүртьюллыклар) язылган. Кайвакыт м. прозада да, шигырь белән дә, ягъни катнаш формада языла. <…> Бу жанрга караган әсәрләргә гиперболаштыру, күтәренке тон, югары стиль хас. Эчтәлеге һәм характеры белән м. касыйдәгә якын» [Миннегулов, с. 274].

[2] Мондый карашның нигезендә С.Н. Зенкинның «Теория литературы. Проблемы и результаты» (2018) дигән хезмәтендә дәлилләнгән жанр концепциясе ята. Анда ул *дискурс* һәм *текст жанрларын* аеру идеясен карый. «Постольку, поскольку мы рассматриваем текст как незавершенный, он может быть и многожанровым, точнее мультидискурсивным, жанрово определенным он становится только после завершения, когда на вариативность частей, сменяющих друг друга тем и форм дискурса, накладывается окончательность общей формы текста» [Зенкин, с. 243].

Разбухли облака, хотят пролиться ливнем.
Зефир предутренний мне запах трав принес.

Все птицы на заре поют, щебечут, свищут:
Земля, зазеленей! Пришла твоя пора!

Все принесли дары на торжище природы:
У каждого нашлась хоть пригоршня добра.

Тот блещет красотой, другой вздыхает томно
Повсюду пляски, смех, веселая игра <…>

Откуда же сейчас твой беспросветный траур,
Так онемело, так окаменело ты?

– Мой друг единственный, – мне сердце отвечало, –
Оставь меня в тоске, не говори со мной!»
[Ахундов, с. 28–29].

М.Ф. Ахундов, сыгылмалы булмаган метафора кулланып, язгы табигатьнең гаҗәеп матурлыгын тасвирлый. Әмма лирик геройның йөрәге ул матурлыкны күрми.

Касыйдәнең композициясе кызыклы: субъектның хисләрен чагылдыруга караганда, чәчәк (лилия, ясмин, роза), кош, җиңел болыт образларына күбрәк өстенлек бирелә. Бирелә аның [субъект. – *А.Х.*] өчен, Пушкинның үлеме турындагы хәбәрне ишетеп, «таш булып каткан» йөрәге «сөйли», ул язгы гүзәллекне күрер хәлдә түгел.

Шул рәвешле Шәрык метафорасы ярдәмендә Ахундов касыйдәсенә *йөрәк сагышы* мотивы килеп керә. Ул лирик герой сагышы тасвирын «алыштыра», аның кабатланмас үзгә эчтәлеген, шулай ук кичерешләр субъектының очраклы сыйфатларын юкка чыгара.

Касыйдәдә субъектив (лирик геройның «мин»е) һәм объектив башлангычлар аерылмаган. Киресенчә, Шәрык шигыре структурасы табигать дөньясына караган бар нәрсәне искиткеч гүзәллек дәрәҗәсенә күтәрә, шул ук вакытта кешегә хас катлаулы, каршылыклы хис-кичерешләрне дә, үзенчәлекле характерны да гадиләштереп сурәтли. Ахундов касыйдәсе поэтикасында чынбарлыкка мөнәсәбәтнең *аерым төре* каноник формада ачыла дип фаразлыйк. Н.И. Пригарина сүзләренә караганда, «усилия [восточного. – *А.Х.*] поэта направлены не на постижение действительности через метафору, а скорее постижение метафоры с помощью действительности. Естественно, что подобный механизм не позволяет воспроизвести «природу или явление» в их конкретно-чувственной данности, а дает их идеализированный, обобщенный и символизированный аспект» [Пригарина, с. 91].

Г. Тукайның «Мөбарәк тәсбих өзелде» әсәрендә касыйдә поэтикасының Шәрык әдәбиятлары өчен уртак элементлары бар дип раслау дөреслеккә туры килә. Алар арасында: субъектив һәм объектив

башлангычларның (автор һәм чынбарлык) аерылмавы; антитезага мөрәҗәгать итү (ә ул үз тирәсендә бөек Толстойны юксынудан туган гаҗәеп зур, тирән сагыш образын тудыручы башка тропларның (метафора, эпитет, параллелизм) семантик кырын барлыкка китерә); дөньядагы барлык хәл-әхвәлләрдән хәбәрдар Аллаһ исемен телгә алулар да бар[1].

Инде билгеләп үтелгәнчә, Тукай әсәренең нигезенә яткан трагик теманың хәрәкәтчәнлеге аның күп жанрлы һәм күп дискурслы булуын билгели. Әйтик, татар шагыйренең мемориаль лирикасы, аерым алганда «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» шигыре дә Тукайның әлеге әсәренә бик якын. Анда *кутәренкелек дискурсы* чагылыш таба. Әлеге күзлектән чыгып караганда, шигырь касыйдәнең панегирик төрләре булган мәрсия һәм мәдхиягә хас үзенчәлекләрне үзенә якынайта. Галимә В.Р. Әминева аны Н.А. Некрасовның «Памяти Белинского» һәм «Памяти Добролюбова» дигән әсәрләре белән чагыштырып, эчтәлегендә аерым шәркый лиризмны («надличный, растворенный в эмоциональной стихии высокого» [Аминева, 2016, с. 137]) аерып күрсәтә. Ул болай дип яза: «Мифологизация образа Х.Ямашева, признание за ним особой жизне- и нормотворческой роли определили адиалогический тип отношения между автором и адресатом, а также централизацию словесно-идеологического мира произведения с «иерархической позиции высоты» (М.М. Бахтин)» [Аминева, 2016, с. 143].

Автор белән герой арасындагы әлеге адиалогик характердагы мөнәсәбәтләр Г. Тукайның «Мөбарәк тәсбих өзелде» әсәренә дә күчә. Биредә диалогның бу төре автор «мин»енең табигать стихияләре, күктәге йолдызлар, Толстойны сагынган бөтен дөнья белән кушылуында ачыла. «Биеклек позициясе»нә ишарә иткән әлеге очсыз-кырыйсыз дөнья соляр һәм мифологик образлар (кояш, кошлар, җил, галәм тынлыгы, Россиядәге агымсулар) ярдәмендә бирелә. Финал өлештә ул Аллаһны мактау сүзләренә кадәр барып җитә:

«Андреев, Максим Горький, Потапенко, Куприн, Соллогуб, Мережковский, Григорий Петров, Скиталец вә гайре, вә гайре бөтен Русиянең мөхтәрәм мөхәррирләреннән тезелгән мөбарәк тәсбихнең очындагы бисмилласы, Мәрьям анасы, яки имамы өзелде» [Тукай, т. 2, б. 143].

---

[1] Л. Массиньон, Н.И. Пригарина, Е.Э. Бертельс фикеренчә, Шәрык әдәбияты әсәрләре структурасында субъект һәм объект бердәмлеге идеясе ислам динендәге төп төшенчәләргә барып тоташа. Н.И. Пригарина болай дип яза: «Ислам придает существенное значение концепту единства – тоухид, понимая его как единственность бога (его антоним – ширк, многобожие) и как онтологическое единство бытия – единство бога в мире. Из концепции таухида выводится вся метафизика ислама: соотношение единого и множественного, всеобщего и отдельного, возможного и действительного, вероятного и необходимого и т.п. Тоухид – тот уровень единения, на котором исчезают противоречия между категориями» [Пригарина, с. 90].

Шул рәвешле, Тукай шигъриятен Шәрык касыйдәсе белән чагыштыру һәм мемориаль лирика тәҗрибәсенә мөрәҗәгать итү Толстой шәхесенә сәнгати мөнәсәбәтне барлыкка китергән күп жанрлы һәм дискурсив нигезне күз алдына китерергә мөмкинлек бирә. Ул, нигездә, формалары белән (чәчмә һәм шигъри) һәм дискурс типлары ягыннан төрле жанрларның (касыйдә, нәсер) шагыйрьнең субъектив кичерешләр сферасы табигать дөньясына, чынбарлыкка каршы куелмаган кыйммәтеннән һәм мәгънәләреннән килеп чыккан. Аллаһка якын Толстой шәхесенең камил һәм киңкырлы образын татар шагыйре шул нигездә тудырган.

Шуның белән бәйле рәвештә әсәрнең «Мөбарәк тәсбих өзелде» дип исемләнүе аерым бер әһәмияткә ия: текстта «көчле позиция» тоткан «мөбарәк тәсбих»не, ахырда «бисмилла» сүзен искә алу Толстойның Аллаһы Тәгалә дөньясы белән бәйләнешен күрсәтүче символга әверелә. Соңгысы, безнең карашка, Толстой шәхесенә сәнгати мөнәсәбәтнең уникальлеген аеруча ачык күрсәтә. Ул Г. Тукайның төрле мәдәни катламнар һәм жанр традицияләре белән диалогыннан килеп чыга. Алар арасында рус әдәбияты һәм Шәрык классикасы үзәк урынны тота.

**Әдәбият**

*Аминева В.Р.* Габдулла Тукай и русская литература XIX в.: типологические параллели. Казань: Татар. кн. изд-во, 2016. 160 с.

*Аминева В.Р.* Сопоставительное исследование жанров: вопросы методологии // Материалы Международной научно-практической конференции «Творчество Отежана Нургалиева: жизнь в литературе и правда эпохи» (19 октября 2018 года). Актобе, 2018. С. 171–177.

*Гачев Г.Д.* Содержательность художественных форм. (Эпос. Лирика. Театр). М.: Просвещение, 1968. 303 с.

*Гордлевский В.А.* Тукай и русская литература // Гордлевский В.А. Избранные сочинения: в 4 т. М.: Изд-во вост. лит-ры, 1961. Т. 2. С. 522–530.

*Зенкин С.Н.* Теория литературы. Проблемы и результаты: учеб пособие для магистр. и аспирантов. М.: Литагент НЛО, 2018. 362 с.

*Кадыров О.Х.* Лев Толстой в оценке Тукая (стихотворение в прозе «Оборвалась нить священных ниток») // Поэт свободы и правды. Материалы Всесоюзной научной конференции и юбилейных торжеств, посвященных 100-летию со дня рождения Габдуллы Тукая. Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. С. 131–137.

*Миннегулов Х.Ю.* Записи разных лет. (Татарская литература: история, поэтика и взаимосвязи). Казань: «Идель-Пресс», 2010. 407 с.

*Пригарина Н.А.* Образное содержание бейта в поэзии на персидском языке // Всточная поэтика. Специфика художественного образа. М.: Наука, 1983. С. 89–108.

*Сафиуллин Я.Г.* Крутые повороты: арабица, латиница, кириллица // Казанский альманах. Серия бирюза. 2017. С. 171–180.

*Тамимдари А.* История персидской литературы. СПб.: Петербург. востоковед., 2007. 240 с.

*Тукай Г.* Избранное. М.: Сов. Россия, 1975. 176 с.

*Тукай Г.* Әсәрләр: 6 томда / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. З.Р. Шәйхелисламов, Г.А. Хөснетдинова, Э.М. Галимҗанова, З.З. Рәмиев. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 2 т. Шигъри әсәрләр (1909–1913). 384 б.

*Тургенев И.С.* Сочинения: в 30-ти томах / гл. ред. М.П. Алексеев. Повести и рассказы. Стихотворения в прозе. М.: Наука, 1982. Т. 10. 608 с.

*Тюпа Ю.И.* Жанр и дискурс // Критика и семиотика. Вып. 15. Новосибирск: Ин-т филол. СО РАН, 2011. С. 31–42.

*Исследование выполнено при финансовой поддержке РФФИ и Правительства РТ в рамках научного проекта № 18-412-160006*

***Хабибуллина Алсу Зариф кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының рус һәм чит илләр әдәбияты кафедрасы доценты*

УДК 821.512.145

***Р.Р. Мусабәкова***

# СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙ ИҖАТЫНДА МУЗЫКАГА МӨНӘСӘБӘТЛЕЛЕК ТУРЫНДА

В статье дается описание поэтического творчества поэта, приводится анализ некоторых стихотворений, отмечаются богатая природная одаренность поэта и «музыкальность» его поэзии. Автор статьи акцентирует внимание на то, что способность Сагита Сунчелея к игре на разных музыкальных инструментах, и тот факт, что он сам сочинял мелодии – нашло прямое отражение и в его поэтическом творчестве.

**Ключевые слова:** С. Сунчелей, татарская литература, поэзия, музыка, воспоминания.

The article describes the poetic work of the poet, provides an analysis of some poems, notes the rich natural talent of the poet, and the «musicality» of his poetry. The author of the article focuses on the fact that Sagit Suncheley's ability to play various musical instruments, and the fact that he composed melodies himself, was directly reflected in his poetic work.

**Keywords:** S. Suncheley, Tatar literature, poetry, music, memories.

Танылган татар шагыйре, тәрҗемәче, драматург, XX йөз башы җәмәгать эшлеклесе Сәгыйть Сүнчәләйнең (1888–1937) тормышы һәм иҗаты ил тарихының гаять авыр һәм катлаулы чорына туры килә. 40 яшендә ул репрессияләнә, башта үлемгә, соңыннан 10 ел төрмәгә хөкем ителә, ләкин 1937 елның 27 октябрендә Соловкида атып үтерелә. Утыз елга якын аның исеме тыелганнар исемлегендә була һәм шуңа күрә шагыйрьнең гомер юлы һәм күпкырлы иҗади эшчәнлеге дә өйрәнелми. 1958 елда шагыйрь аклангач кына, аның язма мирасы хакында Г. Халит беренчеләрдән булып язып чыга. Соңгы елларда аның иҗатын өйрәнүгә З. Рәмиев, Р. Мусабәкова, Р. Мостафин үз өлешләрен кертте. Бертуган абыйсы Шәриф Сүнчәләй (репрессияләнсә дә исән кала) коточкыч авыр шартларда да энесенең архивын саклап кала алганга күрә, без бүген аның үз вакытында басылмаган язмаларын да (шигырьләрен, тәрҗемәләрен, хатларын, көндәлеген) укый алабыз. Аның иҗатын XX гасыр башы татар зыялылары тормышының тарихи һәм лирик елъязмасы дип кабул итәргә кирәк, анда аларның хыял-ашкынулары, дөреслекне һәм гаделлекне эзләүләре бүгенге укучыны да дулкынландырырлык рәвештә чагылыш таба.

Бер яктан, С. Сүнчәләй шәхси, тарихи, җәмгыяви кызыксыну уята, чөнки аның тормышы һәм иҗаты XX гасыр башы социаль һәм сәяси катаклизмнарын ачарга һәм аңларга ярдәм итә. Икенче яктан, шагыйрьнең күпкырлы язма мирасын аның шәхесеннән аерып карап булмый. Чөнки иҗат ул – шәхси тормышның сәнгати чагылышы да.

С. Сүнчәләй шигъриятенең асылын лирик тойгы-кичерешләр тәшкил итә. Бөтен уйлануларын, борчылу-кайгыруларын ул йөрәк аша уздыра, шуңа күрә аның шигырьләрендә хис кайный. Аның әсәрләре – үзенә күрә бер лирик көндәлекне хәтерләтә. Ул көндәлектә С. Сүнчәләй яхшы һәм яман, яшәү һәм үлем, мәхәббәт һәм нәфрәт һ. б. турында уйлана, күңелендә туган сорауларга бертуктаусыз җавап эзли. Һәр шигырь артында С. Сүнчәләй үзе басып тора сыман. Шигырьләрендә ул еш кына тормышның үзен түгел, ә бәлки тормыш реалийларына шәхси мөнәсәбәтен чагылдыра. Автор әсәрләрендәге лирик герой белән тәңгәлләшә дияргә мөмкин. С. Сүнчәләй лирикасында аның тормыш вакыйгаларының төгәл елъязмасы сакланган.

С. Сүнчәләй тормышы хакындагы мәгълүматлар әллә ни күп түгел, бүгенге көнгә кадәр «ак таплар» да сакланып килә. Ләкин иҗатын өйрәнү аның нинди кеше булганлыгын беркадәр күз алдына китерергә ярдәм итә. Беренче заттан чыгыш ясап, шигырьләрендә тормышка мөнәсәбәтен ышандырырлык итеп белдерә, аларда ул ярата һәм нәфрәтләнә, сөенә һәм тирән ачу белдерә, бәхәсләшә һәм ышандыра, соклана һәм кимсетә.

Тормышны ул салкын караш белән күзәтеп тормый, кешенең кайгысына, газаплануына битараф кала алмый. Мәсәлән, «Җырларым – күз нурларым!» шигырендә (1912) ул болай дип яза:

«Моң белән сез җырлагыз! Тик үз татар халкым өчен
Җырлагыз сез – яңрасын тормышны баскан вәхши төн.
Җырлагыз, атсын таңы, чыксын кояш, бетсен газап,
Җырлагыз, күз нурларым! Бик бит кыен, бик бит кыен!..»

Икенче бер шигырендә аның уй-кичерешләре аеруча калку чагылыш тапкан:

«Йоклый алмыйм: ут сулыйм, хәсрәткә бирелеп утырам,
Йоклый алмыйм: ил гамен, дөнья гамен мин кайгырам».

Холык-табигате белән дә С. Сүнчәләй хисчән кеше, чын романтик була. Һәм бу сыйфаты 1911–1916 еллада язылган шигъри әсәрләренең эмоциональ яңгырашын көчәйтә. Нәрсә борчый шагыйрь күңелен, нәрсәгә битараф булып кала алмый соң ул?

С. Сүнчәләйнең чирек гасырлык әдәби-иҗади эшчәнлеген ике дәвергә бүлеп карарга була: 1910–1916 еллар һәм Октябрьдән соңгы дәвер. Иң мөһиме – беренчесе. Бу елларда аның шигърияте тулысынча диярлек табигатькә, сөю-мәхәббәткә, сәнгатькә нисбәтле мотивлар белән сугарылган, дини мотивлар да урын ала. Лирик кичерешләрнең тирәнлеге, тәэсирлеге белән күпчелек шигырьләре XX гасыр башы татар поэзиясенең казанышлары булып бәяләнергә тиешле.

С. Сүнчәләйнең тормышында, иҗатында, иҗтимагый, мәдәни эшчәнлегендә музыканың да зур урын биләве мәгълүм. Замандашлары истәлекләрендә дә аның күңелендә ике дәрт – шигърият һәм музыка яшәве турында әйтелә. Еш кына шигырьләренә гармун белән

скрипка образ-сурәтләре килеп керә. Шагыйрь тормышта гармония урнаштырырга омтыла, аның ритмын сиземли. Музыка аның эчке дөньясын баета, шигъри палитрасын бизи. Хәер, бу сыйфат романтик шагыйрьләргә аеруча хас.

Замандашлары аның скрипка һәм мандолинада уйнавын искә алалар. Шәкерте – язучы Риза Ишморат шагыйрьнең Пермь губернасының Сараш авылы земство мәктәбендәге музыка дәресләрендә скрипкада уйнавын хәтерли, Тукай сүзләренә язылган җырларны бергә җырлаулары, сүзләрен дә, көен дә үзе иҗат иткән җырларны өйрәтүе турында яза. Күңеле тулганда, ул балаларга «Тәфтиләү», «Зиләйлүк», «Карурман» көйләрен уйнарга яраткан [Ишморат, б. 272].

«Әлфиям көе» (1913) шигырендә лирик герой кайчандыр аңа сөйгән яры җырлаган көйне ишетә, әмма аның инде тыңлыйсы килми, чөнки ул хәзер бүтәнне ярата. Ә Әлфия көе аңа һаман да тынгылык бирми, күрәсең, заманында ул кыз аның яратуына мәхәббәт белән җавап кайтармаган. Шигырь ахырында ул Әлфияне һаман да оныта алмавы хакында сөйли. Бу көй аның хәтерен яңарта, ләкин күңелгә җиңеллек китерми. «Кайвакыт» (1910) шигырендә лирик герой элек сөйгән ярын искә ала. Хәзер ул еракта. Сагыну хисе геройны газаплый. Фәкать күз яше һәм көй генә аңа бераз җиңеллек китерә. «Йоклый алмыйм» (1914) шигырендә геройның төшендә сөйгән яры җыр көйли. Икенче бер әсәрендә («Мэри», 1914) лирик герой яшьлегендә пароходта барганда танышкан кызны искә ала, аның палубада җырлаганын хәтерендә яңарта. С. Сүнчәләй геройлары музыкада күңелләренә тынычлану эзлиләр («Кем җылый?» (1913), «Таһир» (1924), ләкин еш кына аны таба алмый интегәләр, чөнки чынбарлык күбесенчә дисгармониягә корылган булып чыга. Аерылышу мотивы С. Сүнчәләй шигырьләрендә, гадәттә, музыкага уралып бирелә («Бер-ике күрдем...» (1915), «Сагыш» (1924). «Бер көй» (1913) шигырендә лирик герой ялгызлык кичерә, аны нәрсәдер баса кебек, ул авыр хистән арына алмый. Юаныч эзләп, ул көйли:

«Әллә нинди яхшы ул көй, әллә ник моңлы, газиз;
Шундый моңлы: шундый һәйбәт, шундый хәсрәтле, нәфис».

Бу сигезьюллык шигырьдә «моң» тамырыннан ясалган сүзләр алты тапкыр, әмма яңадан-яңа лирик ситуациядә кулланыла. «Төн» (1914) шигырендә герой төнлә фронтка китеп барган рекрутлар җырын ишетә, ул аның күңел тирәнлегендә сакланган хатирәләрне яңарта: үткәннәрне, сөйгәннәрне искә төшерә, ниһаять, герой түзми, үзе дә әкренләп көйли башлый. Музыкаль тәэсирләр геройны беркайчан да битараф калдырмый, аның җаны, камертондай, шәһәр тормышындагы музыкаль күренешләрне шигырьләрендә чагылдыра («Татар сәхнәсе» (1918), «Операда» (1920). Музыка белән бәйле уйкичерешләр күп вакыт лирик герой күңеленә моңсулык алып килә. Мәсәлән, «Яз» (1911) шигырендә язын герой уяна, кулына думбра алып, җырлап җибәрә:

«Җырлары яңрый, оча, күктә гизә –
Җан вә күңлен җыр белән тик тергезә».

«Уенчылар мәҗлесендә» (1911), «Авыл җыены» (1911) шигырьләре татарларның җырлы милли бәйрәмнәренә багышланган.

С. Сүнчәләй шул чор татар халкының музыкаль тормышында чагылыш тапкан хәл-әхвәлләр белән дә кызыксынып яшәгән. Мәсәлән, аның «Музыкабыз» (1914) исемле мәкаләсендә соңгы елларда татар җырчылары эшчәнлегендәге уңай һәм тискәре моментларга кыскача анализ ясала, башкару осталыклары турында кызыклы фикерләр әйтелә. Хәтта Соловкидан туганнарына язган хатларында нинди авыр шартларда да лагерьдагы музыкаль чараларда катнашуын әйтә, радиодан Чайковскийның опера һәм симфонияләрен рәхәтләнеп тыңлавы турында яза, кызының музыка белән шөгыльләнүен хуплый.

1917 ел инкыйлабын С. Сүнчәләй шатланып каршы ала, аңа зур өметләр баглый. Аның фикеренчә, инкыйлаб җәмгыятьтә хөкем сөргән барлык киртәләрне, каршылыкларны юк итәргә тиеш була. Аның 1917–1924 еллардагы шигырьләренә шактый дәрәҗәдә декларативлык хас. Аларда лирик башлангыч өстенлек итми [Мусабекова, с. 33]. Табигать Сүнчәләйне бай хисси темперамент белән бүләкләгән, ләкин ахыр чиктә аның ният-омтылышлары, ашкынулары акрынлап трагик характер ала бара. Үзенең кыска гомерен ул күбесенчә шундый халәттә уздыра.

Кыска гына бер күзәтүдә С. Сүнчәләйнең иҗади мирасында, дөньяга карашларында, образ-сурәтләр, мотивлар системасында музыкаль-сәнгати дөньяга нисбәтле хосусиятләрне тикшереп чыгу мөмкин түгел, билгеле. Бәлкем, киләчәктә, XX гасыр башы татар шигърияте һәм музыка, дигән темага караган гыйльми тикшеренүләр ясалыр. Шул чакларда С. Сүнчәләй иҗатына да игътибар ителер.

**Әдәбият**

*Рәмиев Зөфәр.* Соловкида атылган татар шагыйре // Мәдәни җомга. 2019. 23 август. № 33.

*Сүнчәләй Сәгыйть.* Әсәрләр һәм хатлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 367 б.

*Ишморат Р.* Гомер сукмаклары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 408 б.

*Мусабекова Р.Р.* Сагит Сунчелей: судьба и творчество. Казань: Уңыш, 2001. 157 с.

***Мусабәкова Рәисә Рәшит кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Татар энциклопедиясе*
*һәм төбәкне өйрәнү институтының төбәкне өйрәнү*
*һәм социомәдәни тикшеренүләр бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***Ә.М. Закирҗанов***

# Т. МИҢНУЛЛИННЫҢ XX ГАСЫР АХЫРЫ ИҖАТЫНДА ӘДӘБИ-ЭСТЕТИК ЭЗЛӘНҮЛӘР

Статья посвящена анализу творчества Туфана Миннуллина конца XX века. На основе выявления общественных условий развития драматургии данного периода, исследуются поиски Т. Миннуллина в области тематики и жанрового своеобразия, конфликта и героя, а также художественных средств.

**Ключевые слова:** Туфан Миннуллин, татарская драматургия, эпоха, жанр, конфликт, герой, прием.

The article is devoted to the analysis of Tufan Minnullin's work of the late twentieth century. Based on the identification of the social conditions for the development of the dramaturgy of this period, T. Minnullin's searches in the field of themes and genre identity, conflict and hero, as well as artistic means are investigated.

**Keywords:** Tufan Minnullin, Tatar dramaturgy, era, genre, conflict, hero, reception.

XX гасырның икенче яртысы – XXI гасыр башы татар драматургиясенең үсеш-үзгәрешен, сәнгати эзләнүләр юнәлешен, тормышчанлык һәм халыкчанлык белән сугарылуын билгеләгән әдипләрнең берсе – Туфан Миңнуллин. Татар драматургиясе һәм театры башлангычында торган Г. Камал һәм Г. Исхакый, М. Фәйзи һәм К. Тинчурин, Ф. Борнаш һәм Т. Гыйззәт, Н. Исәнбәт һәм Х. Вахит кебек классиклар традицияләрен уңышлы дәвам итеп, ул татар сәхнә әдәбиятын үзенчәлекле тема-мотивлар, кабатланмас образлар, сәнгати алымнар белән баета, татар яшәешенә караган әхлакый һәм фәлсәфи мәсьәләләрне гомумкешелек кыйммәтләре яссылыгында сурәтләп, татар әдәбиятын ил күләмендә, күпсанлы халыклар арасында танытуга зур көч куя.

Т. Миңнуллин иҗатын өч этапка бүлеп өйрәнү уңышлы: 1960–1980 еллар, XX гасыр ахыры һәм XXI гасыр башы. Алар ил-халык тормышындагы иҗтимагый-тарихи вакыйгалар белән тыгыз бәйле булып, барыннан да элек драматургның дөньяга карашы, яшәеш мәсьәләләрен кабул итеп бәяләве һәм аларны сәнгати чагылдыру үзенчәлекләре белән аерылып тора. Т.Миңнуллин 1960 еллар уртасында әдәби иҗатка килә һәм хикәяләре, юморескалары, фельетоннары, кече күләмле сәхнә әсәрләре, балалар өчен язылган «Азат», «Айга сәяхәт» кебек әкият-пьесалары, өлкәннәр өчен «Безнең авыл кешеләре» (1962), «Очканда-кагынганда» (1965) драмалары языла, кайберләре сәхнәгә куела. Әлеге әсәрләр булачак драматургка үзен сынап карау, сәхнә закончалыкларына төшенү мөмкинлеге һәм тәҗрибәсе бирә. Ә инде 1967 елдан башлап Т. Миңнуллин профессиональ язучы сыйфатында иҗат итә башлый һәм Әлмәт театры сәхнәсенә менгән «Күрше кызы» (1967), Г. Камал исемендәге театрда куелган

«Миләүшәнең туган көне» (1968), Драма һәм комедия театрында (хәзер К. Тинчурин исемендә) сәхнәләштерелгән «Нигез ташлары» (1968) пьесалары драматургиягә талантлы, үзенчәлекле каләм остасы килүен хәбәр итә. 1970–1980 елларда Т. Миңнуллин иҗаты тулысынча ачылып, дистәләгән пьесасы сәхнәләргә менә, китап җыентыклары басылып чыга. Әдипнең төрле тормыш материалына, гыйбрәтле хәл-күренешләргә, вакыйгаларга мөрәҗәгать итеп язылган пьесалары тиз арада үз тамашачысын табып, озак еллар сәхнәләрдә уңыш белән уйнала.

XX гасырның 80 нче еллары уртасында башланып киткән үзгәрешләр йогынтысында Т. Миңнуллин иҗатында яңа бер этап башлана. Алдагы чор иҗаты белән совет системасы урнаштырган тәртипләрне, идеологияне шактый кискен тәнкыйтьләгән, шул ук вакытта халкыбыз тормышын төрле яклап сурәтләп, гасырлардан килгән традицияләрне саклауга, рухи дөньяның тирән катламнарын ачып, яшәешкә өмет-ышаныч уятып килгән Т. Миңнуллин үзгәртеп кору процессын хуплап каршы ала. Дөресрәге, бөтен иҗаты белән ул моны әзерләшә, аның котылгысызлыгын дәлилли, шуңа да тормышның демократик юнәлештә үсешенә, фикер төрлелегенә, кеше ирегенә ирешүгә әсәрләре белән дә, иҗтимагый-сәяси позициясе белән дә ярдәм итә. Бу елларда әдип ялкынлы публицист буларак киң танылу ала. Төрле трибуналардан яңгыраган чыгышлары үз халкын ярату, аның тормышын җиңеләйтү, татар һәм башка милләтләргә үсү, яңару мөмкинлеген таләп итү һәм җәмгыятьне тигезлек, гаделлек, бердәмлек идеяләрендә яшәтү рухы белән сугарылган.

Үзгәртеп корулар башлангычында язылган әсәрләре тема-мотивлар төрлелеге, публицистик пафосы, укучы-тамашачы белән җитди әңгәмә коруга нигезләнүләре белән үзенчәлекле. Алар әлеге катлаулы чорны аңлау омтылышы белән бәйле булып, автор икътисади һәм сәяси яңалыклар йогынтысында кеше аңында барган шактый авыр үзгәрешләрне чагылдыруга йөз тота. Бу елларда язылган «Без китәбез, сез каласыз» (1986), «Тал бөресе имәндә» (1987), «Вөҗдан газабы» (1987), «Гармун белән скрипкә» (1988), «Авыл эте Акбай» (1989) пьесалары теге яисә бу дәрәҗәдә әлеге идеягә хезмәт итә. Т. Миңнуллин алдагы традицияләргә таянып, халык рухына тәэсир итәрдәй темалар эзли, яңа эчтәлеккә, заман мәсьәләләрен чагылдыруга омтыла. Үзгәреш җилләренең асылын аңлау һәм аны тамашачыга җиткерү максатында таяныч эзләп, татар дөньясында танылган шәхесләрнең эш-гамәлләрендә чагылган гыйбрәтле образларына мөрәҗәгать итә. Моңа 1986 елда бөек Тукайның тууына 100 ел тулу да этәргеч бирә. Шундый шартларда «Без китәбез, сез каласыз...» тарихи-биографик драмасы языла. Тукайның Идел буенда мануфактуралар тоткан Акчуриннарга сәфәре вакыйгасын үзәккә алган пьесада автор, Тукайның уй-фикерләренә бәйле, үзгәртеп корулар куйган сорауларга да җавап эзли. XX йөз башының көчле үзгәрешләре уртасында калган шагыйрь дә даими уйланган, эзләнгән, еш кына икеләнеп тә калган.

Әмма төп мәсьәләдә аның ышанычы нык һәм ачык: милләт язмышын үз язмышы итеп яшәү генә кешегә иман ныклыгы, фикер ачыклыгы, яшәү яме бирә.

1980 еллар уртасында яшәешнең төрле өлкәләрендә башланып киткән үзгәрешләр моңа кадәр гадәтләнгән яшәү рәвешен, җәмгыятьтә урнашкан системаны һәм барыннан да бигрәк кешенең боларга бәйле аң-акылы үзгәрүен таләп итә. Соңгысы иң авыры булып чыга. Бу исә ул чорда күп төрле кыенлыкларга, еш кына фаҗигаләргә дә китерә. Аеруча партия-совет оешмаларында эшләүче җитәкчеләр күнеккән эш стилен, административ-команда системасын үзгәртүдә зур кыенлык кичерә. Т. Миңнуллин сәхнә әдәбиятында беренчеләрдән булып әлеге күренешләрне «Вөҗдан газабы» (1987) драмасында сурәтләргә алына. Исеменнән күренгәнчә, үзәктә партия райкомының беренче секретаре Тимергазинның яңа шартларга бәйле эшләргә омтылу юлында кичергән рухи кыенлыклары тора. Партия секретаренең якыннары һәм эштә хезмәткәрләре белән мөнәсәбәте, кылган гамәлләре артында моңа кадәр яшәп килгән системаның гаделсез, мантыйк булмаган яклары ачылып, алар тәнкыйтькә дучар була. Драма чор авазын чагылдыруы, үзгәрешләрнең котылгысызлыгын ачуы, кеше шәхесенә игътибарның арта баруын үзенчәлекле образларда сурәтләве белән заманча яңгыраш ала һәм укучы-тамашачыны төп идеяне аңлауга китерә: «үзгәртеп кору һәркемнең үзеннән башланырга тиеш» [Әхмәдуллин, б. 151].

Драматург чор каршылыкларын сатирик формада сурәтләү юлларын да эзли. Аның «Кәҗә туган түгел, бәҗә мал түгел» комедиясе хакимият тирәсендәгеләрнең эш-гамәлен сатирик планда сурәтләве белән үзенчәлекле. Үзгәртеп кору турында һәрдаим сөйләп, шул ук вакытта идарә итү системасында ялган, күз буяу, юк белән баш катыру, ягъни совет чорындагы бюрократлык күренешләренең дәвам итүен тәнкыйтьли автор. Мандас Мумиев докладында мәкальнең дөрес куллану-кулланылмавына бәйле күтәрелгән бәхәс ике якның да чын йөзен ачу, аларны фаш итү белән тәмамлана. Автор арттыру, сүз уйнату, геройларның бер-берсен һәм үз-үзләрен фаш итү алымнары һәм әдәби шартлылык аша власть өчен көрәшүче чиновникларның тулы бер галереясын мәйданга чыгара, алардан ачы итеп көлә. Чынбарлыктагы абсурд хәленә җиткән күренешләрне сурәтләү аша, драматург социаль, мәдәни, милли мәсьәләләргә килеп чыга, аларны җәмәгатьчелек каршына куя.

Җәмгыятьтәге үзгәрешләр нәтиҗәсендә милли үзаң үсү, дәүләтчелекне торгызу идеясенең киң яклау табуы әдәбиятта милли тематиканың киң чагылуына китерә. Милләтебезне инкыйраздан ничек коткарырга? Аның телен, менталитетын, яшәү рәвешен, традицияләрен ничек саклап калырга? Әлеге сораулар бу чор драма әсәрләренең күпчелеген иңләп үтә. Милләтебезнең ассимиляцияләнүен тизләткән катнаш никах мәсьәләсе – җәмәгатьчелекне җитди борчыган һәм бер төрле генә бәяләп булмый торган сораулардан. Татар һәм рус телендә-

ге вакытлы матбугатта да катнаш никахларга әлегәчә төрле мөнәсәбәт чагылып килә. Т. Миңнуллинның «Илгизәр плюс Вера» драмасы катнаш никах кебек гаять җитди, четерекле мәсьәләне сәнгать чаралары ярдәмендә тәэсирле итеп сурәтләве белән генә түгел, бәлки яшь геройларның рухи йөзен, психологиясен гыйбрәтле күренешләрдә ачуы белән җәмәгатьчелекнең хөрмәтен казана.

Үзенең тарихында дәүләтчелеге булган вакытта татар халкының төрле сословиеләргә бүленүе табигый хәл. Шулар арасында феодаллар сыйныфын тәшкил иткән морзалар үзгә урын алып тора. Гасырлар дәвамында рус дәүләтенең кысу-изүгә корылган сәясәте аркасында, аларның бер өлеше христиан динен кабул итеп руслашкан, икенчеләре исә хокукларыннан мәхрүм ителеп, бөлүгә дучар булган. Әмма нинди генә хәлдә дә үзләренең аксөяк нәсел билгеләрен, милли горурлыкны гасырлар аша алдагы буыннарга җиткерергә тырышкан. Кызганыч ки, тоталитар дәүләт системасы әлеге социаль катлауның соңгыларын да юк итүгә, таркатуга ирешә. Драматург «Шәҗәрә» драмасында милләтнең ачы язмышын ачык чагылдырган әлеге катлау вәкилләре тормышын сурәтли. Г. Камал традицияләрен дәвам итеп, кинокадр лентасын хәтерләткән күренешләрне бер-бер артлы тезеп, автор морза нәселенең төрле вәкилләре тормышын гаять гыйбрәтле вакыйгалар аша күрсәтеп кенә калмый, бәлки аларны үзара якынайту, берләштерү юлларын да эзли. Р. Хәмид язганча, *«Шәҗәрә» халкыбызның үз тамырларын эзләргә омтылуын оригиналь сюжет аша күрсәтә...*[Хәмид, б. 158]. Татар халкының тирән катламнары, дәүләтчелек белән бәйле затлылыгы бар һәм ул бүгенгегә килеп җиткән – әсәр нигезенә салынган фәлсәфи һәм әхлакый мәгънәнең асылы әнә шунда. Ә ул исә бер затлы нәсел язмышы аркылы бөтен бер милләт язмышын, аның фаҗигасен чагылдыру һәм халкыбызның, нинди генә шартларда яшәсә дә, үзенә хас яшәү рәвешен, җыр-моңын һәм башка рухи кыйммәтләрен саклап калуын күрсәтү белән бәйле.

Әсәр нигезенә салынган тирән фәлсәфи мәгънә ерак авылдан Казанга килгән Сәет Шәрәфетдиновның әтисе кушкан йомышны үтәве белән бәйле. Егетнең ерак бабасы күп еллар элек морза Сәетбәковтан бурычка акча алып торган һәм аны вакытында кире кайтара алмаган. Әлеге бурычны түләү, бер буыннан икенчесенә күчә барып, Сәеткә килеп җиткән. Егет шәһәр буйлап Сәетбәковлар нәселе дәвамчысын эзләп йөри, гаять гыйбрәтле язмышлы кешеләр белән очраша һәм ахырда морза дәвамчыларыннан яңа гына өйләнешкән гаиләгә бурычын кайтара. Берничә буыннан килгән васыятьне үтәү вакыйгасы артында татар халкының гаҗәеп матур сыйфатлары турында җитди сүз алып барыла. Бу, беренче чиратта, намус төшенчәсе белән бәйле, ягъни үзеңнең бурычыңны кайтаруда һәм сиңа тиешле булмаган акчадан баш тарта алуда кешеләр сынала. Морза нәселе вәкилләренең аянычлы язмышы беркемне дә битараф калдырмый. Алар кичергән фаҗигаләр артында ил-халык тормышы, тоталитар җәмгыятьнең кешелексез яклары ачыла. Шул ук вакытта Т. Миңнуллин гаҗәеп

үзенчәлекле авыл егете образын тудыра. 18 яшьлек Сәет авторның эстетик идеалын чагылдыра: ул тәвәккәл, максатчан, намуслы, нәсел-нәсәбен яхшы белүе өстенә, аның белән горурлана, киләчәгенә өмет белән карый. Драматургның күпчелек әсәрләрен иңләп үткән төшенчә буларак, егетнең киләчәгенә, үз көче белән матур тормыш корачагына һәм аның нигезенең гаиләдә салынуына укучы-тамашачы күңелендә ышаныч тудыра. Кешене кеше итеп саклаган сыйфатлар рәвешендә намус, җаваплылык, сүзендә тора белүне яшәеш принцибы иткән Сәет образы чорның үзенчәлекле тибы буларак яңгыраш ала.

Бөтен ил буйлап чәчелеп урнашкан, гомер иткән татар халкы эчендә керәшеннәр һәм мишәрләр дигән катламнар булып, алар үзләренә хас сөйләм үзенчәлеге, кием-салым, беренчеләре исә христиан динен тотулары белән аерылып тора. Т. Миңнуллинның керәшеннәр турындагы «Гөргөри кияүләре» (1995), мишәрләр тормышыннан алып язылган «Йөрәк маем» (1996) кебек комедияләре халыкның җанлы тормышын эчтән торып сурәтләве белән тамашачы тарафыннан яратып каршы алына. Пьесалар татарларның күп бизәкле, гаять гыйбрәтле, үзенчәлекле яшәү рәвешен торгыза, аерым штрихлар белән бирелгән образлар аша чор рухын, халыкның көчен, эчке рухын чагылдыра.

Т. Миңнуллинның бу чор сәнгати эзләнүләрендә интеллектуаль башлангыч билгеләре киң урын ала. Алдагы елларда язылган «Миләүшәнең туган көне», «Дуслар җыелган җирдә» пьесалары белән трилогия тәшкил иткән «Хушыгыз» (1990) драмасы үзәгендә шәхес фаҗигасе ята. Гомере буе музыка сәнгатенә хезмәт итеп тә, хәзер инде яшәвенең мәгънәсезлеген, тулы канлы олы тормышның янәшәдән үтеп китүен бик соңарып аңлаган, җәмгыять һәм «дуслары» тарафыннан онытылган Миләүшә – авторның зур табышы. Гомер күяшы баюга баруын ачык тойган халәттә ул ялгызлыктан, чарасызлыктан газаплана. Тирән сагыш, рәнҗү белән янган күңелендә якты нур булып яшьлек мәхәббәте саклана. Ә инде Миләүшә белән Галиулланың яшьлекләрен искә төшерү, беренчесенең сәхнәгә чыгу вакыйгасын уйнап күрсәтүе кебек күренешләр әсәрне романтизм иҗат юнәлешенә хас хис-кичерешләр, хыял дөньясы, мәхәббәт тойгысы, эмоциональлек белән баета, геройның җан хәрәкәтләрен тулырак аңлау мөмкинлеге бирә. Шуның белән бергә, Т. Миңнуллин үзенчәлекле сурәтләү ысулына да мөрәҗәгать итә. Миләүшә характерында, эш-гамәлендә Ялгызлык сыйфатын күтәреп куеп, укучы-тамашачы каршында яшәү белән үлем чигендә тормыш мәгънәсенә төшенү – Хакыйкатькә омтылу мизгелен ача. Пьесаны иңләп үткән төп лейтмотив булып сызлану (экзистенциализм) фәлсәфәсе тора. Ахыр чиктә Миләүшә язмышы ул – тулы бер буынның яшәү рәвеше, тормыш моделе дә бит. Гомере буе җавапсыз мәхәббәт белән янган Галиулла да бәхетсез. Әлеге ике геройны теләк-омтылышларының тормышка ашмавы, өметсезлек, мәхәббәткә ирешә алмау һәм шуларга бәйле Ялгызлык берләштерә. Т. Миңнуллин Миләүшә язмышы аша

гомернең чикләнгәнлеген, Яшәешнең бер мизгел генә булуын, аның мәгънәсезлеген күрсәтсә дә, әлеге герой фаҗигасен булдырмау юлларын да эзли. Аның башлангычы – рухи сафлыкта, яшьлек мәхәббәтенә тугрылыкта, күңелдә өмет хисен саклауда. Дөрес, әлеге пьесаны Й.Нигъмәтуллина башкача бәяли. Ул Миләүшә һәм Галиулла белән бәйле эпизодларны геройларның уены буларак анализлап, моның белән геройлар үзләренең башка тормыш юлын үтү мөмкинлеген күрсәтәләр дигән фикергә килә һәм болай дип яза: «Миләүшә бер уенны кире кагып, алмашка икенче уен тудыра. Герой, тормышның асыл мәгънәсен аңламыйча, вафат була» [Нигматуллина, с. 154].

XX гасырның 90 нчы елларындагы икътисади торгынлык, матди һәм рухи кыйммәтләрнең үзгәрүе, әфган һәм чечен сугышы нәтиҗәләре йогынтысында тулы бер буын рухи кризис кичерә. Әлеге «югалган буын», аның сәбәпләре турында уйланулар З. Хәким, Д. Салихов, Аманулла, Ю. Сафиуллин, Т. Миңнуллин кебек драматурглар иҗатында бөтен кискенлеге белән куела. Әдипләр каршылыклы, еш кына фаҗигале язмышлардан гыйбрәт алырга, андыйларга миһербанлылык күрсәтергә чакыра. Укучы-тамашачы күңелендә хис-кичерешләр өермәсе кузгатып, әйләнә-тирәгә башка күз белән – ялгышу-хаталануын аңлап та, аны төзәтә алмыйча җәфаланучы кеше күзе белән карарга, рухи сафлыкка этәрә. «Кешенең рухи дөньясы, хис-кичерешләре белән бәйле каршылыклы яшәү рәвеше пьесаларның төп конфликтын тәшкил итә һәм ул еш кына яшәешне экзистенциаль кабул итү – сызлану фәлсәфәсе (Заһидуллина) булып алга чыга. Шунысы игътибарга лаек, сызлану хәзерге татар драматургиясенә хас шартлылык, төсләр байлыгы, шәркый сурәтлелек, аллегория, хикмәтле сүз әйтү һ. б. алымнар белән кушылып, тулы канлы милли төсмер хасил итә. Милли сыйфат-билгеләре белән аерылып торган, шул ук вакытта гомумкешелек кыйммәтләренә хезмәт итүче әсәрләр һәм спектакльләр киң җәмәгатьчелектә яклау табып, киң яңгыраш ала» [Закирҗанов, б. 33]. Һәрбер иҗатчы кебек Т. Миңнуллин да заман героен эзли. Чорның актуаль мәсьәләләренә бәйле нинди генә тема-мотивларга мөрәҗәгать итмәсен, әдипне катлаулы вакыйгалар уртасында калып, җитди сынауларга насыйп булган кеше кызыксындыра. Алдагы чор иҗатындагы кебек XX–XXI гасырлар чигендәге әсәрләрендәге кеше образлары да төрле булып, һәрберсе үз йөзе, эш-гамәле, яклаган кыйммәтләре белән аерылып тора. Шулай да драматург яшь геройларны аеруча яратып мәйданга чыгара. Киләчәкнең яшьләр кулында булуын яхшы аңлап, аларның олы тормышка килүен, каршылыклар аша үзләрен табуын, еш кына ялгышларга дучар булуларын тәэсирле алым-чаралар ярдәмендә тамашачыга тәкъдим итә. Заманның яшь геройлары турында сүз алып барганда әдипнең «Эзләдем, бәгърем, сине» (2000) драмасындагы Рәхимҗан белән Нурсинә образларын читләтеп үтеп булмый. Драматург гаҗәеп үзенчәлекле, беркемне дә битараф калдырмый торган тормыш материалына мөрәҗәгать итә – төрле сәбәпләр аркасында

инвалид коляскасына беркетелгән яшь геройларны сурәтли. Тормыш каршылыклары һәркем алдына кыенлык-михнәтләрне таудай өеп куя. Көнкүрешнең күптөрле мәшәкатьләре, эшсезлек, хезмәт хакын вакытында түләмәү һ. б. нәтиҗәсендә яшәү мәгънәсен, киләчәккә өметен югалтучылар да бихисап, үзенә үзе кул салучыларның артуы да шул турыда сөйли. Ә бит инвалид-авыруларга икеләтә авыр. Т. Миңнуллин әнә шундый геройларның җан сыкрануларын, катлаулы һәм каршылыклы күңел тибрәнешләрен укучы-тамашачы алдына куя. Сугыш афәтендә ике аягын югалтып, протез кияргә мәҗбүр булган Рәхимҗан – авторның табышы. Горур, үз шәхесен бәяли һәм яклый белә торган, авырлыкларга тешен кысып түзүче, акыллы һәм олы йөрәкле егет ул. Күренешләрдә Нурсинә дә ихтыяр көченә ия, сабыр, тыйнак, шул ук вакытта башкаларны тыңлый һәм аңлый белүче кыз булып күңелдә кала. Драматург, оста психолог буларак, геройларының рухи халәтен ачык тоемлап, белеп һәм укучы-тамашачы күңеленә эмоциональ тәэсирле итеп чагылдыра. Беренче күренешләрдән алып соңгысына кадәрге хәл-сурәтләрдә геройларның рухи эволюциясе бирелә. Автор кеше рухының көченә, бөеклегенә ышана, үз-үзләрен һәм бер-берсен таба алган егет белән кызга соклануын яшерми. Кешене өмет-ышаныч яшәтә, үзебездә һәм башкаларда әлеге хис-сыйфатны булдырырга, сакларга тиешбез, ди кебек драматург. Телефоннан гына сөйләшеп туган мәхәббәт хисе Рәхимҗан белән Нурсинәне тормышка башка күз белән карарга этәрә, рухларын ныгыта. Драма ахырында очрашкан егет белән кыз – олы тормышка бергәләп атлаучы, чын мәхәббәтнең кадерен белүче, «аякларында» нык басып торучы һәм шуның белән укучы-тамашачы күңелендә дә теләктәшлек табучы яшь геройлар.

Шулай итеп, Т. Миңнуллин әлеге чор иҗатында укучысы белән бергә заман куйган сорауларга җавап эзли. Шул максатта ул чорның каршылыклы якларын ачып, кыенлыклар алдында калган геройларны мәйданга чыгара, аларны төрлечә сыный. Әдип тормыш мәгънәсен әхлакый кыйммәтләрне яклап һәм саклап, үзең, гаиләң, шулай ук халкың алдында җаваплылык тотып яшәүдә күрә. Шуңа да Тимергазин, Илгизәр, Вера, Миләүшә кебек геройлары борчылу, әрнү хисе уятса, Рәхимҗан, Нурсинә, Сәет кебекләр, авырлыклар аша үтеп, тормышка туры караучылар буларак хәтердә кала. Драматургның сәнгати эзләнүләрендә яшәешне реалистик сурәтләрдә бирү өстенлек итә, гәрчә ул әсәр контекстында романтик хислелекне һич тә кире какмый. Пьесаларда иркен рәвештә метафора булып килгән вакыйгалардан, «уен» алымыннан, шартлылыктан файдалану күзәтелә.

**Әдәбият**

*Әхмәдуллин А.* Дөреслеккә ирешү юлында // Казан утлары. 1989. № 11. Б. 148–153.

*Закирҗанов Ә.* Хәзерге татар драматургиясендә дини һәм фәлсәфи фикер синтезы // Роль ислама в стабилизации социальных процессов: сборник статей и тезисов II Международной научно-практической конференции, 18 марта

2017 г. / под ред. Р.Ш. Шайхевалиева. Набережные Челны: Ак мечет, 2017. Б. 32–35.

*Нигматуллина Ю.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. Казань: Фэн, 2002. 176 с.

*Хәмид Р.* Татар драматургиясе миллиме? // Казан утлары. 2002. № 4. Б. 155–163.

*Мәкалә «2014–2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

*Публикация осуществлено в рамках мероприятия 3.5.4 Государственной программы «Сохранение, изучение и развитие государственных языков Республики Татарстан и других языков в Республике Татарстан на 2014–2021 годы»*

***Закирҗанов Әлфәт Мәгъсүмҗан улы***,
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге мөдире*

УДК 94(470.41)

*Э.К. Сәлахова*

# ЮГАРЫ ҺӘМ ТҮБӘН МӘТӘСКӘ АВЫЛЛАРЫ ТАРИХЫННАН

Статья посвящена истории татарских деревень Заказанья – Верхние и Нижние Метески. Автор дает информацию о ранней истории названных населенных пунктов, показывает взаимосвязь деревень Большие Метески нынешнего Тюлячинского района РТ с деревнями Арского района – Верхние и Нижние Метески. В публикации большое внимание уделяется к истории периода XIX – начала XX в. Статья содержит богатый материал о духовных лицах, об их просветительской деятельности в регионе, также об истории мечетей и повседневной жизни населения.

**Ключевые слова:** история населенных пунктов, история Метески, история татарского народа, краеведение, образование, медресе, шакирды.

The article is devoted to the history of the Tatar villages of Zakazanye – Upper and Lower Meteski. The author gives information about the early history of these settlements, shows the relationship of the Big Meteski villages of the current Tyulyachinsky district of the Republic of Tatarstan with the villages of the Arsky district – Upper and Lower Meteski. The publication pays great attention to the period of history of the XIX – early XX centuries. The article contains rich material about clergy, about their educational activities in the region, as well as about the history of mosques and the daily life of the population.

**Keywords:** history of settlements, history of Meteski, history of the Tatar people, local history, education, madrassas, shakirds.

Казан артында хәзерге Арча районына керә торган ике Мәтәскә авылы яшәп килә: аның берсе – Югары Мәтәскә, икенчесе – Түбән Мәтәскә. Е.И. Чернышев Казан ханлыгы авыллары исемлегендә Мәтәскә атамасы кергән сигез авылны атый. Гадәттә, исемнәре охшаш авыллар арасында якын бәйләнеш була, ул я территориаль яктан, я нәсел туганлыгы белән дә билгеләнергә мөмкин. Халык риваяте буенча, Түбән Мәтәскәне нигезләүчеләр Югары Мәтәскә авылы кешеләре булган, ә Югары Мәтәскә җирләренә килеп авыл булдыручылар хәзерге Теләче районының Олы Мәтәскә кешеләре [Гарипова, б. 650–652]. Е.И. Чернышев күрсәтүенчә, бу авыллар Казан ханлыгы чорында ук яшәгән, әмма аларның нигезләнүе күпкә иртәрәк булуы да ихтимал. Кызганыч ки, моны документ белән раслау мөмкинлеге юк. Арча районына керә торган Югары һәм Түбән Мәтәскә авыллары гомер-гомергә бергә яшәгән, аларга бүлеп бирелгән җирләре дә уртак булган. 1793 елда уздырылган ызанлау вакытында бу ике авыл халкын берләштергән игенче общинасына барлыгы 1640 дисәтинә 1936 сажин җир туры килгән, шуның 1594 дисәтинә 2155 сажины – чәчүлек җирләре. XIX гасырның икенче яртысында мәтәскәлеләр

файдаланган басулар янәшәсендә эре җирбилгечеләрнең дә хосусый җир кишәрлекләре урнаша. Югары Мәтәскә янында элек алпавытлар А.К. Тюфянов, А.Е. Комаровскийныкы булган җирләр соңрак Арча мещаны И.Я. Горшеновка күчә. Шунда ук сәүдәгәр Гобәйдулла Габдулла улының печәнлекләре була, ул 1874 елның 20 июлендә сатып алган бу җирләрне 1881 елның 8 августында икенче гильдия Казан сәүдәгәре, Арча сәүдәгәре С.И. Кисловка 1000 сум алтынга сатып җибәрә. Шифалы үләннәр үстергән С.И. Кисловны җирле халык үләннәр белән дәвалаучы табиб буларак әле дә хәтерендә саклый, бу җирләрдә хәзер инде чытырманлык булса да, халык ул урыннарны «Кислов дачасы» дип атый. Түбән Мәтәскә авылы янындагы 63,5 дисәтинә җир кишәрлеге И.И. Аппаковныкы була. Анда тегермән дә эшли.

Мәтәскә халкы, нигездә, җир эшкәртеп көн күргән, кышкы сезонда, өстәмә табыш алу максаты белән, халык башка һөнәрләр белән шөгыльләнергә тырышкан, читкә китеп бәхет эзләүчеләр дә булган.

Тарихи яктан Югары Мәтәскә алданрак нигезләнгән булса да, XIX гасырда кеше саны, икътидаси мөмкинлеге ягыннан Түбән Мәтәскә өстенлек ала. Бу – нигездә, Себер юлы тракты өстендә урнашкан Түбән Мәтәскәдә почта станциясе төзелү белән бәйле. XIX гасыр ахыры рәсми документларыннан күренгәнчә, авылның 7 крестьяны ямщик хезмәтендә торган [Материалы.., б. 4–5]. XX йөз башында Түбән Мәтәскә авылының почта станциясе Николай Васильевич Михайлов милкендә була, станцияне карап торучы булып Василий Добрынин хезмәт итә. Биредә почтага хезмәт күрсәтү өчен 16 пар ат тотылган.

Почта йорты Казанның беренче гильдияле сәүдәгәре В.А. Савин тарафыннан төзелә. 1825 елгы тасвирламада бу йорт түбәндәгечә сурәтләнгән: «Озынлыгы тугыз сажин һәм бер аршин, киңлеге җиде сажин һәм бер аршин булган кирпич фундаментлы бер бина. Түбәсе кызылга буялган калайдан». Бина алты бүлмәдән торган, мич белән җылытылган. Йортка керә торган ишек башына зур «А» хәрефе һәм дә ике башлы бөркет сурәте куелган була. Утарда ямщиклар өе, кирәк-яраклар саклау бинасы һәм ат абзары урнашкан [Из истории..., с. 51]. XX йөз башында Казан губернасында 8 почта станциясе булса, шуларның икесе Казан өязе Түбән Мәтәскә һәм Карадуган авылында урнаша. Авыл аша почта юлы үтү бер яктан отышлы булса, крестьяннар өчен акча эшләү мөмкинлеген арттырса, икенче яктан, авыл тормышына тынычсызлыклар да алып килә. 1891 елның 13 декабрендә Карадуган арасы белән Мәтәскә арасын үткәндә берничә кеше, талау максаты белән, почтальоннарның юлына чыга. Талаучыларны куркыту өчен, почтальоннар һавага атарга да мәҗбүр булалар. Талаучылар урманга кереп качалар. Бу хәлдән соң почтальоннарны саклау һәм трактның куркынычсызлыгын тәэмин итүне көчәйтергә дигән боерык алына.

Казан арты авылларына хас булганча, мәтәскәлеләрдә дә, җир эшкәртүдән тыш, төрле һөнәрчелек эшләре белән шөгыльләнү киң

таралган. Халыкның бер өлеше авылда эшләсә, икенчеләре читкә китеп кәсеп иткән. XIX йөз ахырында Югары Мәтәскә кешеләре тире эшкәртүдән елына 200 сум керем алган, шулай ук татар крестьяны җир эшкәртүдән калган вакытында итек басу, агач эше, урман кисү, читән үрү, йон эшкәртү, пыяла кою белән дә шөгыльләнгән. Тегүчеләр, авылдан-авылга йөреп, заказга кием теккәннәр. XIX йөз ахырында Югары Мәтәскә авылында тирә-якта танылу алган зәркәнче яшәгән, аның көмештән ясаган бизәнү әйберләре сәнгати югарылыкта булган. Шулай ук, Югары Мәтәскәнең ике атаклы миччесе булуы билгеле. Түбән Мәтәскә авылы миччеләренең исемнәре дә тарихка кергән, алар – Әхмәтша һәм Сираҗетдин Әхмәдиевләр. Түбән Мәтәскәнең бер кешесе төрле татлы ризыклар, хәлвә әзерләп, Казан шәһәренә илтеп сату иткән. Авылларда умарта тотучылар да була, бу – табигать шартларына карап, төрле елда төрле күләмдә гаилә казнасына күпмедер табыш керткән. Мисал өчен, XIX йөз ахырында Югары Мәтәскә авылында 11 гаиләнең умарта тотуы билгеле. Үзләреннән арткан товарны базарда сатудан кергән акчаны гаиләне тоту, салым түләү өчен файдаланганнар.

Казан артындагы күп кенә авылларга хас булганча, Мәтәскә авылы кешеләре Казан шәһәренең завод-фабрикаларына китеп тә эшләгәннәр, байларда хезмәтчеләр дә булып торганнар. Вакытлыча кышкы сезонда гына эшләргә килгән татар крестьяннары Казан шәһәрендә яшәп тә калган. Кызганычка каршы, татар крестьяны җәй җир эшкәртеп, кышка кергәч, читкә китеп, мөмкинлеге булганда һөнәрчелек белән шөгыльләнеп яшәсә дә, әллә ни зур байлык җыя алмый. XIX йөз ахыры мәгълүматлары буенча, ике Мәтәскә авылында да йортларның өчтән бер өлешенең түбәсе салам белән ябылган [Материалы..., с. 4–5]. Шуның өстенә әле 1879 елда Түбән Мәтәскә авылында зур янгын чыгып, 60 йорт янып бетә [Список мест..., с. 7–8].

Түбән Мәтәскә авылында көндәлек кирәк-ярак сату өчен кибет (лавка) тотучылар да була. 2 кибет хуҗасы Мәгърифә Халитова һәм Ногман Шакиров үз авылы кешеләре булса, Нәбиулла Хәйбуллин – чыгышы белән Наласадан [ТР ДА. 3 ф. 1 тасв. 2243 эш. 207–226 кгз.]. Түбән Мәтәскә кешесе Гайнетдин Шәмсетдинов Казиле авылында Арча мещаны Дмитрий Федорович Кустовтан су белән эшләүче тегермән арендалап торган. Югары Мәтәскәдә дә Ия елгасы буенда бер су тегермәне эшләгән [Список населенных мест…, с. 156–157]. Түбән Мәтәскә авылы янындагы Аппаков дачасында бер кәгазь җитештерү «фабрикасы», бер вак-төяк сата торган кибет һәм бер тимерчелек алачыгы эшләп торган [Список мест..., с. 158–159].

Югары һәм Түбән Мәтәскә авыллары халкы тулы рухи тормыш белән дә яшәгән. Халыкның уртак бәйрәмнәре, җыеннары булган. Ике Мәтәскә авылы да Казан артының «Күкчә җыены»на караган, аны икенче төрле «Кыр җыены» дип тә атап йөрткәннәр. Монда Мәтәскә авылларыннан кала, Өчиле, Бирәзәбаш, Урта Бирәзә, Югары

Әзәк, Түбән Әзәк, Мөндеш, Кәче, Күкчә-Бирәзә авыллары кергән [Гарипова, б. 652].

Мәтәскә авылларында мәчетләр борын-борыннан эшләп килгән. Авыл халкы аның кайчан салынганын да белми, гадәттә, авыл нигезләнү белән үк мәчет ачыла торган була. Алдан ул гадәти бер йорт рәвешендә булса, халыкның мөмкинлеге булуга, манаралы бина итеп зурайтылган. Мәчетләрне җимергән тарихның караңгы бер чорында, XVII–XVIII йөзләр чигендә, 20 хуҗалыгы булган Югары Мәтәскә авылының мәчете юк ителә, ә шулай ук 20 хуҗалыктан торган Түбән Мәтәскә авылы мәчетенә кагылмыйлар [Экстракт...]. Кабат Югары Мәтәскә авылында кайчан мәчет салынуы билгеле түгел, XIX йөзнең уртасында авылда бер мәчет эшләгән, бу мәчет мәхәлләсе үз эчендә 189 ир-атны, 174 хатын-кызны берләштергән. 1857 елдан башлап мәчетнең имам-хатыйбы булып Хөснетдин Шәмсетдинев торган [ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 8 эш. 69 кгз.], 1866 елдан аны Таип Фәхретдинев алыштыра [ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 273 эш. 253б–255 кгз.].

Таип Фәхретдинев Түбән Мәтәскә авылы имамы Мөхәммәдшакир Хәләфев, Күпербаш мулласы Камалетдин Нәҗметдинев, Кармыш-Казанбаш авылының Мөхәммәдситдыйк Хафизов белән берлектә мәхәллә кешеләренең милкен бүлүдәге хилафлыклары өчен гаепләнәләр, алар өстеннән Диния назарәтенә шикаять керә [ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 6781 эш. кгз. 18]. 1897 елгы материаллар буенча, Югары Мәтәскәдә имам урыны буш торган, имамның, югарыда аталган сәбәп аркасында, эштән азат ителгән булуы ихтимал. 1898 елда Югары Мәтәскә авылына имам-хатыйб булып Казан өязе Казиле авылы кешесе Габделхак Гатаулла улы мәдрәсәсен тәмамлаган Әүхәди Мифтахетдинев (Указы 1898 елның 6 октябреннән) килә [ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 734 эш. 23б кгз. ]. Аннан соң аны Мөхәммәди Мифтахетдинев (Указы 1904 елның 6 октябреннән) алыштыра [ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 8464 эш. 54б–55 кгз.].

Авылның яңа җамигъ мәчете 1856 елда төзелә. Озынлыгы 5 сажин булган мәчетнең намаз укый торган өлеше 3 сажин, ә калганы – керү, кием һәм аяк киемнәрен калдыра торган урын. XX йөз башында 78 хуҗалыгы булган авылда мәчеткә йөрүче кеше саны 150 гә җиткән [ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 7606 эш. 5 кгз. ]. Элеккеге мәчет инде бу кадәр халыкны сыйдыра алмый башлаган. 1906 елның 23 февралендә мәхәллә халкының мәчетне зурайту һәм ремонтлауга рөхсәт сорап язган үтенеченә уңай җавап алынган. Элеккеге мәчет бинасы 9 сажинга кадәр озынайтылган, һәр якка өчәр тәрәзә өстәлгән һәм михрабка да тәрәзә куелган. Мәчет түбәсе калай белән капланган. Шулай ук мәхәллә халкы исәбенә мәчет бинасы тулаем төзекләндерелгән [ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 7606 эш. 5 кгз.].

Түбән Мәтәскә авылы мәчетендә 1841 елдан башлап Мөхәммәдхәләф Сөләйманов (билгеләнү турында указы 1841 елның 17 июненнән), аннан аның улы – Мөхәммәдшакир Мөхәммәдхәләфев (1873 елның 30 ноябреннән) хезмәт иткән. 1895 елдан бу вазифаны

Сәлахетдин Гыймадетдинов (1895 елның 18 июненнән), Мөхәммәдфатыйх Мөхәммәдшакировлар ала (1905 елның 5 мартыннан). Мөхәммәдшакир Мөхәммәдхәләфев бер үк вакытта Күтернәс авылы мулласы вазифасын да үти. Ихтимал, Күтернәс авылы кечкенә авыллардан булып, аларның аерым мулла тоту мөмкинлеге булмаган, бу авыллар арасы бик якын булганга, алар бер мәхәллә исәпләнгән булса кирәк [ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 1887 эш. 302б–303 кгз.]. Соңрак Күтернәс авылы халкына Күпербаш авылы мулласы хезмәт күрсәтә башлый. Мөхәммәдфатыйх Мөхәммәдшакиров (ул Мөхсин фамилиясе белән дә билгеле) 1871 елда туган, Казиле авылында Габделхак хәзрәттә белем алган, ә Сәлахетдин Гыймадетдинев (Ишморатов) Казан өязе Түбән Ядегәр авылыннан, Малмыж өязенең Күшкетбаш мәдрәсәсендә белем эстәгән. Сәлахетдин мулла авыл җәмәгатьчелендә үз гамәлләре белән ризасызлык уята, аның хәмер эчүе дә, мәхәллә әгъзаларыннан акча алырга яратуы да халыкның ачуын кабарта. 1903 елның 10 октябрендә авыл җәмәгатьчеленең зур күпчелеге аны вазифасыннан азат итәргә, муллалыктан алырга дигән карарга килә [ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 6870 эш. 4 кгз.]. Мөхәммәдшакир Мөхәммәдхәләфев тә Югары Мәтәскә, Күпербаш, Кармыш-Казанбаш муллалары белән бергә гаилә малын канунсыз бүлүдә гаепләнә, әмма аларның гаепләре расланмый. Бу – алар өстеннән дошманнарының донослары гына булырга тиеш.

Казан арты авыллары үзләренең мәдрәсәләре белән данлыклы була. Уку-укытуның куелышы, шәкертләр әзерләү ягыннан Курса, Кышкар мәдрәсәләреннән калышмаган, татар җәмгыятендә абруйлы мәдрәсә Түбән Мәтәскә авылында да эшләп килгән. XIX гасырның 80 нче елларында Мөхәммәдшакир Мөхәммәдхәләфев 15 ир баланы укыта, шул вакытта 17 кыз да дин дәресләре ала. Сәлахетдин Хисаметдинов укыткан 90 нчы елларда шәкертләр саны 34 кә җитә, әмма мулланың югарыда әйтелгән кырын эшләре аркасында, шәкертләр саны кинәт кими [ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 5568 эш. 32б–38 кгз.]. Әлеге мулладан соң билгеләнгән Мөхәммәдфатыйх Мөхәммәдшакиров мәдрәсәнең авторитетын бик тиз кайтара, ул эшләгән 3 ел эчендә шәкертләр саны 20 дән 42 гә җитә, ә гадәттә еллар дәвамында укучы кызларның саны тотрыклы рәвештә 17–18 кеше булса, ул эшләгәндә кызларның саны да 36 га җитә. Бу казанышлар – әлбәттә, мөгаллимнең зур хезмәте һәм абруе нәтиҗәсе. Мулла, мөгаллимнең янында булып, җәмгыятьнең анасы булачак кызларны укытуда, аларны тәрбияле, белемле итүдә абыстайларның фидакяр хезмәтен аерым билгеләргә кирәк. Татар авылында белем бирү, мәктәп-мәдрәсә тоту һәр имамның бурычы саналган, бу бурыч күңел ихтыяҗы белән эшләнгән, һәр авылның мулла, мөгаллим, абыстайлары – татар җәмгыятенең үсешен булдыручы төп көчләр.

Мәтәскә авылларының тарихлы икәнен күрсәтүче тагын бер чыганак – ул таш билгеләр, кабер ташлары. Сәнгати дәрәҗәдә эшләнгән кабер ташлары тарихы зур булган, маллы кешеләр көн күргән, югары рухи тормыш белән яшәгән авылларда сакланып калган. Түбән

Мәтәскә авылы зиратында XVI йөз урталарында ук куелган кабер ташлары безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Каберташ язмалары белгече А. Гайнетдинов Түбән Мәтәскә авылында тарихи яктан игътибарга лаеклы 9 кабер ташын күрсәтә. Шулар арасында иң борынгы кабер ташлары 1541–1542 елларга карый, алар – Аман хуҗа Кунак Хуҗабай улына һәм Җаян хуҗа Кунак Хуҗабай улына куелган ташлар. Кызганычка каршы, Түбән Мәтәскә имамнарына куелган барлык кабер ташлары да сакланып калмаган, әмма XX йөз башында бу авылда имамлык иткән дамелла Мөхәммәдфатыйх мулла Мөхәммәдшакир улы Яхинга (имамлыкка Указы 1905 елның 5 мартыннан) 1934 елны вафатыннан соң куелган таш Түбән Мәтәскә авылының тарихи ташлары рәтендә тора [Гайнетдинев, б. 231–233]. Кызганычка каршы, Югары Мәтәскәдә тарихи ташлардан бары тик берсе генә ачыкланып, аның 1915 елга караганлыгы билгеләнде [Гайнетдинев, б. 333]. Каберстан татар җәмгыятендә һәрвакыт тарихның үзе итеп кабул ителгән, зиратлар тәртиптә тотылган, чистартылган, кабер ташларына сак карарга тырышканнар. Түбән Мәтәскәнең кәгазьдә саклау мөмкинлеге булмаган чорда үз тарихын ташларда саклап кала алуы – бу авыл кешеләренең хөрмәткә лаек булуы хакында сөйли.

Татар җәмгыятенең рухи тормышы, мәгариф һәм мәдәният үсеше, тарихи сәбәпләр аркасында, авыл җирлеге белән бәйле. Шунлыктан, татар тарихын өйрәнүдә аның һәрбер авыл тарихы мөһим. Һәр авылның имамы, ул тоткан мәктәп-мәдрәсәсе татар дөньясы томышында, аның үсеш-үзгәрешендә хәлиткеч роль уйнаган.

## Әдәбият

*Гайнетдинов А.М.* Арча районы эпиграфик истәлекләре. Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2016.

*Гарипова Ф.Г.* Авыллар һәм калалар тарихыннан. Т. I. Казан: Матбугат йорты, 2001.

Из истории почтовой связи (К 125-летию образования Казанского почтово-телеграфного округа): Сборник документов и материалов / отв. сост. Л.В. Горохова; сост. О.В. Федотова, Н.А. Шарангина; под общ. ред. Д.И. Ибрагимова и Н.А. Никифорова. Казань: Главное архивное управление при КМ РТ, 2010.

Материалы для сравнительной оценки земельных угодий в уездах Казанской губернии. Вып. 3. Уезд Казанский. Казань: Типография Г.М. Вячеслава, 1887.

*Рәхим Г.* Балалар күңеле. 18–19 нчы китап. Габдерәшид бабай. Казан: Мәгариф, 1919.

Список мест населенных пунктов Казанского уезда, с кратким их описанием. XII Кармышская волость / сост. И.А. Износков. Казань: Типография Губернского Правления, 1885.

Список населенных мест Казанской губернии. Вып.1. Уезд Казанский. 1878 г. / сост. Н.Н. Вячеслав. Казань: Губернская типография, 1878.

ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 8 эш.

ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 273 эш.

ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 1887эш.

ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 5568 эш.

ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 6781 эш.

ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 6870 эш.
ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 7606 эш.
ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 8464 эш.
ТР ДА. 3 ф. 1 тасв. 2243 эш.
ТР ДА. 204 ф. 177 тасв. 734 эш.
Экстракт в правительствующий сенат из Казанской губернской канцелярии о татарских мечетях // Эхо веков. 2006. № 1.

***Сәлахова Эльмира Кадим кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Татарстан Республикасы халыкларының тарихи-мәдәни мирасы бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 373.3

*А.В. Әхтәмова*

# ХХ ГАСЫР БАШЫНДА УФА ГУБЕРНАСЫ БАШЛАНГЫЧ БЕЛЕМ МӘКТӘПЛӘРЕ

Статья посвящена изучению начальных мусульманских школ (мөселман башлангыч (ибтидаи) мәктәпләре) Уфимской губернии начала XX века. Под влиянием обсуждения законопроекта «О введении всеобщего начального обучения в Российской империи» мектебе становятся объектом широкого общественного интереса. В конце 1911 года на Уфимском губернском земском собрании было принято решение об изучении состояния местных мектебов. По данным земской статистики, из 2615 мектебов 1610 считались организованными, большинство из них были мужскими (1335), а 1005 – неорганизованными (домашнее обучение), с преобладанием женских (557) и смешанных (337) мектебов.

**Ключевые слова:** образование, мектеб, Уфимская губерния, Уфимское губернское земство, статистичекие данные, татарская дореволюционная пресса.

The article is devoted to the study of elementary muslim schools in the Ufa province of the early XX century. Under the influence of the discussion of the bill «On the introduction of universal primary education in the Russian Empire», the metebe becomes an object of wide public interest. At the end of 1911, at the Ufa Provincial Zemstvo Assembly, a decision was made to study the state of local mektebs. According to Zemstvo statistics, out of 2615 mektebs, 1610 were considered organized, most of them were male (1335), and 1005 were unorganized (home schooling) with a predominance of female (557) and mixed (337) metebas.

**Keywords:** education, mekteb, Ufa province, Ufa provincial zemstvo, statistical data, tatar pre-revolutionary press.

XIX йөз ахыры – XX гасыр башы – татар милли мәгарифенең чәчәк ату, тәрәккыйпәрвәрләр, зыялы затларның йолдызлыгы кабынган тарихи чор. Татар халкының гасырлар дәвамында калыпланган милли белем бирү системасы, аның башлангыч баскычы булган ибтидаи мәктәпләрдә уку-укытуны камилләштерү XX гасыр башында төрки-татар җәмәгатьчелеген борчый, бу өлкәдә эзләнүләр, уй-фикерләр алышу бүген дә әле эзлекле дәвам итә.

1906–1913 еллар аралыгында «инородецлар» өчен башлангыч училищелар турында «Кагыйдәләр» кабул ителә (1906 ел, 31 март; 1907 ел, 1 ноябрь; 1913 ел, 14 июнь). Туган теленә вә иманына афәт янаганын сизеп алган татар зыялылары вакытлы матбугат аша, Дәүләт думасы мөнбәреннән, төрле җыелышларда һәм съездларда, патша хөкүмәтенең мәгариф өлкәсендәге сәясәтен фаш итеп, халыкның милли үзенчәлеген саклап калу мәсьәләләрен күтәреп чыга.

Уфа губернасы мөселман мәктәпләре турында бай статистик мәгълүмат земство хезмәткәрләре тарафыннан туплана. Бүгенге көн-

дә архив чыганакларыннан тыш, милли матбугат, земство оешмалары материаллары – ата-бабаларыбызның белем бирү системасы турында кыйммәтле чыганак. Мәкаләбез, беренче нәүбәттә, XX гасыр башы татар вакытлы матбугаты һәм Уфа губернасы земствосының статистика мәгълүматларына нигезләнә.

Уфа губернасының тәүге үзенчәлеге – мөселманнар иң күп яши торган төбәкләрнең берсе булуында. Россия империясендә 1897 елгы Беренче гомуми халык санын алу материаллары буенча губернада яшәгән халыкның яртысы – мөселманнар (49,88%) [Первая..., с. VII–VIII, 48–57].

Татар вакытлы матбугатында мәгариф мәсьәләләренең чагылышын өйрәнгән галимебез Н.Ә. Ваһапов: «Рус булмаган халыкларның мәгарифенә карата дәүләт сәясәтенең чагылышы дәүләткүләм гомуми мәҗбүри башлангыч укуга күчү ниятендә һәм земстволар үткәргән сәясәттә дә күренгән. Бу планнар да, земстволарның мәгарифкә мөнәсәбәте дә матбугатның игътибар үзәгендә торган», – дип яза [Ваһапов, б. 47].

Мөселман мәктәпләре хакында мәгълүмат туплау мәсьәләсе 1911 елның 17 декабрендә Уфа губерна земствосы җыелышында күтәрелә һәм уңай карар кабул ителә. Соңрак бу хакта мөселманнарның фикерен белергә теләп, Уфа губерна земство управасы киңәшмә үткәрә. Губерна һәм өяз земство вәкилләреннән тыш, бу иҗтимагый чарада «Мәхкәмә-и шәргыя»дән ике вәкил, Уфа губернасы мәхәлләләреннән өч имам һәм 14 мөселман зыялысы (шул исәптән укытучы-мөгаллимнәр) катнаша. Нәтиҗәдә, махсус комиссия төзелеп, мөселман мәктәпләрендәге уку-укыту барышын өйрәнү буенча җитди эш башкарыла [Вакыт, 1913, 8 декабрь; Обухов, с. 5].

Әлеге комиссия тарафыннан мәхәлләләр өчен сөальнамә (115 сораудан торган программа) һәм мөрәҗәгатьнамә әзерләнә. Аларны адресатларга тарату максатыннан, «Мәхкәмә-и шәргыя Ырынбургыя»ның мәгълүматларына таянып, губерна управасы Уфа губернасындагы мәктәп мөдирләре исемлеген дә төзи. Ниһаять, 1912 елның ноябрь аенда һәр имамга татар телендә мөрәҗәгатьнамә, сөальнамә, мөгаллимнең шәхси карточка формасы, «Нәрсә ул земство» («Что такое земство») исемле рисалә тапшырыла [Обухов, с. 5, 123].

1913 ел азагына Уфа губернасындагы 2615 мәктәптән хәбәр килә, әмма тулы «канәгать итәр дәрәҗәдә» җавапны 500 чамасы мәктәп мөгаллиме генә бирә. Шул ук вакытта «Вакыт» газетасы, Минзәлә өязе земство управасының рәсми чыганакларына таянып, «300 ләп мәхәлләнең мәктәпләре барлык-юклык хакында бөтенләй мәгълүмат килгәне юк», дип яза [Вакыт, 1913, 8 декабрь]. Искәртик, 2615 мәктәптән 1610 сы монтазам (рәтле, тәртипкә салынган) мәктәп икәне (ирләр мәктәбе күпчелекне алып тора (1335)), 1005 мәктәптә тәгълим хосусый йортларда (аның күбрәге хатын-кызлар мәктәбе (557) һәм катнаш мәктәп (337)) оештырылган булуы ачыклана [шунда ук]. Гомумән, статистик анализ 90936 укучысы (ягъни алар Уфа губернасындагы

барлык мөселман халкының 5,8%ын тәшкил итә) булган 1568 мәктәп[1] биргән тулырак материаллар нигезендә ясала [Обухов, с. 23]. Әүвәл җыелган документларга тәфтиш һәм гомуми нәтиҗә ясау Уфа губерна земство управасы хезмәткәре М.И. Обуховка (1871–1943) йөкләнә.

Үткәрелгән тикшеренүгә йомгак ясап, М.И. Обухов күпчелек милли мәктәпләргә ислях кылу (яңарту) идеясе үтеп керүен искәртә. Аның раславынча, губернада барлыгы 285 иске (кадими, конфессиональ) мәктәп кенә исәпләнә (18,1%) [шунда ук, б. 31]. Бер үк вакытта, «ысуле тәгълим ягыннан караганда», катнаш мәктәпләрнең саны күп булуы да мәгълүм. Мәсәлән, «Вакыт» газетасы хәбәр иткәнчә, 1912/1913 уку елында Минзәлә өязендә ысуле кадим (50) һәм җәдиди мәктәпләрдән тыш (230), 579 катнаш мәктәп гамәлдә була [Вакыт, 1913, 8 ноябрь].

Шул рәвешле, стастистика хезмәткәре төбәктәге мәктәпләрнең яртысыннан артыгы монтазам ибтидаи мәктәпләр исәбендә булуын вә аларның дөньяви фәннәргә йөз тотуын ассызыклап, хезмәтендә мондый типтагы мәктәпләрнең санын китерә: Бәләбәй өязендә – 211, Бөре өязендә – 168, Златоуст өязендә – 25, Минзәлә өязендә – 215, Стәрлетамак өязендә – 137, Уфа өязендә – 93 (губернада барлыгы – 849) [Обухов, с. 42]. Димәк, губерна күләмендә дөньяви белем бирү юнәлешендә соңгы дистә елда җитди адым ясала.

М.И. Обухов фикеренчә, мөселман мәктәбе ул халыкның белемгә ихтыяҗын канәгатьләндерә торган һәм башлангыч рус мәктәбе белән тигез хокукта гомумгуберна уку йортлары челтәренә керә алырлык рациональ типтагы инородецлар башлангыч училищесы булырга мөмкин [шунда ук].

Әлеге уку йортларында шәкертләр нинди китаплардан файдаланганнар соң? Биредә тәгълим-тәрбия эше Әхмәтһади Максудиның «Мөгаллим әүвәл», «Мөгаллим сәни», Риза Фәхретдиннең «Тәрбияле бала», Фатыйх Кәриминең «Тарихе әнбия», Нәҗип Думавиның «Безнең мәктәп», Шаһидулла Вахитовның «Гыйльми хисаб» дип аталган хезмәтләре һ. б. уку әсбаплары буенча алып барыла [Любимов, с. 2–4].

Мәгариф өлкәсендәге земстволар эшенә әйләнеп кайтыйк. Уфа губерна земствосының мөселманнар ихтыяҗларын исәпкә алырга омтылуын милли матбугат һәрдаим яктыртып барган. Шунысы игътибарга лаек, «милли мәгарифкә азрак булса да булышканлыктан, Уфа губернасының өяз земстволары башкаларга үрнәк итеп күрсәтелгән» [Ваһапов, б. 61]. Мисал өчен, Уфа земствосы «татар теленә әдәбият вә уку китаплары тәрҗемә кылырга ел саен аерым сумма тәгаен кыла» башлаган [шунда ук, б. 177], мөселман җәмгыятендә гыйлем-мәгърифәт тарату нияте белән 1914 елда сигез авылда китапханә ачкан, алты данә рисалә нәшер итәргә ярдәм иткән. Якын киләчәктә түбәндәге чаралар кирәк дип табылган: русча-татарча мәктәпләрнең

[1] Земство тарафыннан барлыгы 1579 мәктәп теркәлә.

укытучылары өчен татар теле курслары һәм китапханәләр ачу, моңардан тыш 13 кичке китапханә булдыру, гомуми мәгариф турында рисалә вә китаплар бастыру һ. б. [Тормыш, 1914, 2 ноябрь].

Уфа губерна земствосы тарафыннан «Дүртъеллык башлангыч мөселман мәктәбе өчен программа» да төзелә, ул түбәндәге предметлардан гыйбарәт: дин тәгълиматы, туган тел, хисап (арифметика), Россия тарихы, география, рус теле, җыр, гигиена, табигать белеме, рәсем [БР МА, И-132 ф., 1 тасв., 15 эш, 1 кгз.].

Земство мәктәпләренә килгәндә, татар вакытлы матбугатында алар «татарлар арасында мәкъбулияткә кереп китә алмый» дигән фикер дә күренә. Моның сәбәбе – биредә дин дәресләренә, ана теленә игътибар аз булу. Нәтиҗәдә, ата-ана баласын, земство мәктәбеннән алып, мәхәллә мәктәбенә укырга бирә [Тормыш, 1914, 23 февраль]. Әлеге теманы дәвам итеп, «Тормыш» газетасы гайре мөселманнарның мөрәҗәгате вә газап-борчулары белән укучыларын таныштыра: «Әгәр дә без үземезгә бирелгән кадерле сәгать, кадерле минутларның кыйммәтен тәкъдир итүен тиешлесенчә файда алырга тырышмасак, безнең өчен кем кайгырыр?» [Тормыш, 1914, 16 март].

Шушы елларда татар вакытлы матбугатында «Мәктәпме, школамы?» темасына иҗтимагый моназара рәвешендә мәкаләләр дөнья күрә. Хосусан, Ш.Й. Мәхмүтов[1] (Мәхмүдов) мөселман авылларында ачылган рәсми мәмләкәт школаларында «дин вә милли тел укытыр өчен куелган вакыт бик аз», ди. «Бу аз вакытта, никадәр мәгълүматлы вә иҗтиһадлы мөгаллим булса да, күп нәрсә үгрәтергә, күп нәрсә белдерергә муафыйк булачак түгел. Моның өстенә рәсми мәмләкәт школаларында мөселман динен укыту мәҗбүри түгел, имтихан программасында кертелми, шәкерт дин дәресен белмәсә яки укымаса, класста калдырылмый <...> Школадан кайткач, укырга дәрес бирелсә, балаларның милли укуына вакыт калмый <...>. Шул сәбәпле, рәсми мәмләкәт школаларында милли уку, милли язуны кирәгенчә укытыр өчен юллар күренми. Милли укуны дәвам иттерү, балага милли рух бирү өчен милли мәктәпләрнең булулары лязем, милли ибтидаи мәктәпсез милләт яши алмас», – дип яза автор [Тормыш, 1914, 26 ноябрь].

Нәкъ менә шушы кыйблада иҗат итүче, үзенең бар аңлы гомерен милләтенә фидакяр хезмәт итүгә багышлаган тагын бер зыялы шәхесебез Гайсә Еникеев[2] фикерләрен дә китерик: «Минемчә, милли мәдрәсәләребезгә, яһүд, рус мәктәпләренә кирәчәк татар балаларының ибтидаи тәрбиясе саф ана телендә булып, аларга чын татар рухын сеңдерү тиеш кенә түгел, бәлки фарыз. Чөнки кечкенә балалар бик тиз әзерләнүчән һәм төрле нәрсәгә, кирәк яхшы, кирәк начар булсын, өйрәнеп калучан булалар» [Тормыш, 1915, 17 март].

---

[1] Шәрәфетдин Йәләлетдин улы Мәхмүтов (1853–1932) – педагог, җәмәгать эшлеклесе, Уфа губернасыннан III чакырылыш Россия империясе Дәүләт думасы депутаты.

[2] Гайсә Хәмидулла улы Еникеев (1864–1931) – педагог, мәгърифәтче, этнограф, Казан губернасыннан III чакырылыш Россия империясе Дәүләт думасы депутаты, Оренбург губернасыннан IV чакырылыш Россия империясе Дәүләт думасы депутаты.

Хөкүмәт мәктәбенә йөргән мөселманнар хакында Г.Х. Еникеев туплаган статистик мәгълүмат кызыксыну уята. 1913 ел азагы – 1914 ел башында Санкт-Петербургта уздырылган Беренче бөтенроссия халык мәгарифе съездында, земство материалларына таянып, докладчы түбәндәге саннарны китерә: «Уфа губернасында укыган мөселманнарның проценты башкаларга караганда байтак югары. Анда да русча укый-яза белмәгәннәрнең проценты шаккатырлык зур. 1911 елда земство статистикасы күрсәтүенә караганда, хөкүмәт мәктәбенә инородец балаларының 5,5 проценты гына йөргәннәр. Хәлбуки, рус авылларында уку яшендәге балаларның 50,5 проценты школага йөри. Димәк, бу губернадагы мөселман балаларының 94,5 проценты школага бармыйча, яки бөтенләй укымый калалар, яки үзләренең хосусый мәктәпләрендә генә укып калалар. Башка җирләрдә хәл моннан да начаррак» [Тормыш, 1914, 18 гыйнвар].

Кайбер эшлекleләр бер үк вакытта дини һәм дөньяви уку йортларының кирәклеген ассызыклый. Мәсәлән, күренекле татар галиме, мөгаллим, «Йолдыз» газетасы нашире һәм мөхәррире, җәмәгать эшлеклесе Әхмәтһади Максуди (1868–1941) карашы буенча, мөселман халкына, тел һәм динне саклау өчен, мәхәллә мәктәпләрендә дә, дөньяви гыйлем, рус телен үзләштерү өчен, «ышкуллар»да да укырга кирәк, ә киләчәктә «мәктәпләрне дә, ышкулларны да ислях кылу» зарур [Казан утлары, 2018, № 9, б. 170, 173].

«Школа»ны яклаучылар арасында мөселман рухани вәкилләре, башкорт һәм татар мөгаллимнәре һәм земство хезмәткәрләре була [Карагыз: Азаматова, б. 102].

Шулай итеп, XX гасыр башында күпмилләтле һәм күпдинле регионнарның берсе булган Уфа губернасында милли мәктәп сан буенча да, сыйфат буенча да үсә, сизелерлек казанышларга ирешә. Төрки-мөселманнарда гасырлар буе калыпланган гомуми башлангыч белем бирү системасы, башлангыч мәктәпнең миллилеген саклап калу белән беррәттән, уку-укыту процессын европалаштыру, аны яңарту буенча олы бер хәрәкәткә әверелә.

## Әдәбият

*Азаматова Г.Б.* Земское самоуправление в многонациональном регионе России (на примере Уфимской губернии, 1874–1917 гг.): дис. ... д-ра ист. наук / Ордена Знак Почета Институт истории, языка и литературы Уфимского федерального исследовательского центра Российской академии наук. Уфа, 2018. 586 с.

Бөтенрусия мөгаллимнәренең беренче гомуми съезды // Тормыш. 1914. 18 гыйнвар.

*Вәһапов Н.Ә.* Татар вакытлы матбугатында мәгариф һәм тәрбия мәсьәләләренең чагылышы (1907–1916 еллар). Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2010. 188 б.

Земство школалары // Тормыш. 1914. 23 февраль.

Земство школаларына дин мөгаллиме тәгаен иткәндә // Тормыш. 1914. 16 март.

*Любимов А.* Мактабы и медресе г. Уфы и 1-го района Уфимского уезда. Уфа, 1914. 10 с.

Мәктәпме, школамы? // Тормыш. 1914. 26 ноябрь.

Мәктәпме, школамы? // Тормыш. 1915. 17 март.

БР МА. И-132 ф., 1 тасв., 15 эш.

*Обухов М.И.* Мектебы Уфимской губернии. Народное образование в Уфимской губернии в 1917 г. / сост.: С.В. Вахитов, Ю.В. Ергин. Уфа: Вагант, 2006. 136 с.

Первая всеобщая перепись населения Российской Империи, 1897 г. / под ред. Н.А. Тройницкого. СПб.: Изд-е ЦСК МВД, 1904. Т. XLV. Уфимская губерния. Тетрадь 2. [3], XI, 189 с.

Уфа губерниясендә мөселман мәктәпләре // Вакыт. 1913. 8 ноябрь.

Уфа губерниясендә мөселман мәктәпләре // Вакыт. 1913. 8 декабрь.

Уфа земствосы вә мөселманнар // Тормыш. 1914. 2 ноябрь.

Әхмәдһади Максуди мәкаләләре (Ленар Гобәйдуллин кереш сүзе белән) // Казан утлары. 2018. № 9. Б. 170–175.

***Әхтәмова Алсу Вазыйх кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге*
*Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 398.8

*И.Г. Закирова*

# ТАТАР ФОЛЬКЛОРЫНДА ЧЫҢГЫЗ ХАН ОБРАЗЫ

В татарском народном творчестве отведено много места образу Чингизхана. Он изображается сыном неба и его приход к власти объясняется богоизбранностью, харизмой этой личности. Фольклорные произведения, связанные с образом Чингизхана возникли на основе сложившихся ранее фольклорно-мифологических традиций. Народ видит в Чингизхане воплощение идеального правителя.

**Ключевые слова:** Чингизхан, татарский фольклор, харизма, сказания, историческая личность.

In Tatar folk art, a lot of space is given to the image of Genghis Khan. He is portrayed as the son of heaven, and his rise to power is due to God's chosenness, the charisma of his personality. Folklore works related to the image of Genghis Khan arose on the basis of previously established folklore and mythological traditions. The people see in Genghis Khan the embodiment of an ideal ruler.

**Keywords:** Genghis Khan, Tatar folklore, charisma, legends, historical figure.

Алтын Урда чоры көчле тарихи шәхесләргә, үз артыннан йөзмеңнәрне иярткән лидерларга бай. Бөек империягә нигез салучы Тимучин-Чыңгыз хан, әлбәттә, бу плеяданың башында тора. Бөек даһи, стратег, олуг хан, талантлы полководец, явыз басып алучы, күп гасырларга бер генә туа торган шәхес. Аның уллары һәм оныклары – Бату хан, Җүчи хан, Үгәдәй хан, Туктамыш хан, Мәнгү Тимер, Бәркә, Үзбәк хан, Җанибәк, Танибәк, Бирдебәк һ. б. үзләре турында яхшы яки яман ат калдырып дөньядан кичкән. Бу – чыңгызилар. Алар Алтын Урда тәхетенә хокукны кан варислыгы белән алалар.

Әлеге шәхесләрнең Алтын Урда тарихында тоткан урыннары, дәрәҗәләре, тарихка кергән хезмәтләре, батырлыклары, тарихтагы рольләре төрлечә. Әмма аларның исемнәре фольклорга кереп безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Халык авыз иҗатындагы мәгълүматлар тарихи фактлар белән туры да килмәскә мөмкин. Әмма аларда әлеге шәхесләргә һәм аерым вакыйгаларга халыкның мөнәсәбәте чагыла.

Чыңгыз хан турында ишетмәгән кеше юктыр. Бу шәхес хәзерге вакытка кадәр хакимлек, бердәмлек, көч символы буларак мәгълүм. Бөек хаганга халык иҗатында да, тарихта да күп урын бирелгән. Чыңгыз ханга багышланган язма истәлекләрнең иң борынгылары һәм иң әһәмиятлеләре – XIV йөз монгол язма истәлеге – «Юань-чао би-ши», XIII йөз кытай язма истәлеге – «Мэн-да бэй-лу», XVII йөзгә караган һәм авторлыгы галим лама Лубсан Данзанга нисбәт ителгән «Алтан тобчи», фарсы тарихчылары Җүвәйни (XIII йөз), Рәшит-әд-дин

(XIII ахыры – XIV башы), гарәп тарихчысы Ибне-әл-Әсир (XII йөз ахыры – XIII йөз башы), италияле де Плани Карпини, Марко Поло, фламанд Вильгельм Рубрук һ. б. хезмәтләре. Төрки, рус, әрмән, әфган, грузин һ. б. елъязмачылары үзләренең язмаларында да Чыңгыз хан турында мәгълүмат бирәләр. Бу мәкаләдә, Чыңгыз хан турында төрки һәм монгол халыклары фольклорында сакланган материалларга таянып, хөкемдарның эпик образын торгызырга омтылдык.

Алтын Урда дәүләте төзелү иң бөек империяләрнең берсе булган монгол империясенә нигез салган Тимучин, ягъни Чыңгыз хан исеме белән бәйле. Бөек хаган образына халык иҗатында да шактый урын бирелгән. Кайсы гына халыкның Чыңгыз ханга багышланган фольклор әсәрен алсак та, алар нигезендә бу бөек затның гадәти кеше булмавына инану ята. Ягъни, һәр риваять, легенда яки башка жанрларга караган әсәрләр әлеге олуг затның гадәти кеше түгеллеген исбатлауга хезмәт итә. Чыңгыз ханның культын өйрәнүче галимнәр аның гадәти булмаган ихтыяр көчен, талантын, популярлыгын ханның харизмасы белән бәйләп аңлаталар. Бу очракта шәхеснең хакимияткә килүе претендентның харизмасы белән аңлатыла. Харизма туганда ук Алла тарафыннан бирелә. Бер кеше дә үз тырышлыгы белән аңа ирешә алмый. Харизматик авторитет та халыкның хакимлеккә килүченең гадәти булмавына, Алла тарафыннан сайланган булуына инануыннан формалаша.

Тимучинның нәсел-шәҗәрәсе, тууы турындагы легенда-риваятьләрдә аның илаһи нәсел җебе тотемга барып тоташу, Алла тарафыннан сайланган шәхес булуы бәян ителә. Чыңгыз ханның 23 буыннан торган шәҗәрәсе Буртэ-Чино һәм хатыны Гоа-Марал исемнәре белән башланып китә.

Бортэ-Чино – соры бүре, Гоа Марал нәфис болан дип тәрҗемә ителә. Галимнәр әлеге затларны генеологик мифлардан килгән фольклор персонажлары итеп карыйлар, бу риваять чыңгызилар нәселенең шушы хайваннардан чыгуына ишарә итә. Бортэ Чино белән Гоа Марал зооантроморф табигатьле образлар. Алар риваятьтә кешеләр буларак тасвирлансалар да, исемнәре зооморфологик билгеләрен саклап калган. Төркиләрнең риваять легендаларында тотем бүре образы Илаһи Күк белән тәңгәлләштерелә. Бу Чыңгыз ханның ерак бабасы Бодынчарның тууын тасвирлаган риваятьтә ачык аңлашыла. Алан-Гоа үзенең нурдан авырга калуын сөйли. Төнлә төнлек аша нур булып үтеп кергән илаһи зат таң атканда сары эт кебек тырмашып чыгып китә [Козин, § 21]. Бу риваять «Дәфтәре Чыңгызнамә» дастанында Чыңгыз ханның тууына бәйле рәвештә китерелә. Алангу янына үлгән Дуйым Бәяннең рухы кайта; ул таң алдыннан нур булып төшә һәм елкы яллы күк бүре булып чыгып китә. Киткәндә: «Чыңгыз, Чыңгыз», – дип аваз бирә [Дәфтәре чыңгыз-намә, б. 12]. Варисның хакимияткә хокукы аның илаһи нәсел башы, яки тотем белән кан туганлыгы аша нигезләнә. Илаһи ата кешеләргә нур булып күренә. Харизматик шәхеснең дә башкалардан аерып торган билгесе – йөзе-

нең нурлы булуы. «Юань-чао би-ши»да 9 яшьлек Тимучин «йөзе – таң кебек» дип сурәтләнә. «Дәфтәре Чыңгызнамә»дә дә Чыңгызның йөзе гадәти булмавы аңлашыла. Аның «йөзен күргән кеше артыннан калмас иде», дигән юллар да шуны раслый.

Чыңгыз хан турындагы риваятьләрдә аңа тугач та Тимучин исеме бирелү, соңрак исемгә әверелгән Чыңгыз титулына ия булуы турында да мәгълүмат саклана. Риваятьләр Тимучин исеменең Тимер сүзеннән булуын аңлата. Бер риваятьтә Чыңгыз хан туган вакытта атасы Есугай-батурның Тимучин-Уге исемле татар кешесен әсирлеккә алып кайтуы бәян ителә. Монгол халыклары җиңелгән сугышчының – дошманның яшәү көче, энергиясе исеме белән яңа туган балага күчүенә ышанган. Икенче яктан, балага ул туган вакытта булган вакыйгаларга аваздаш исем сайлау гадәте дә күп кенә халыкларга хас була.

Тимучин исеменең фольклорда сакланган икенче этимологиясе буенча ул тимерче сүзеннән килеп чыккан. Бурят-монгол халыкларында Чыңгыз ханның тимерче булуы турында риваятьләр дә бар. Аларда Чыңгыз ханның алып булуы, аның ике аягы белән елганың ике ярына басып, Дөш тавын сандал итеп, Чика елгасы суында суыта-суыта, тимер сугуын сөйли [Мэн-да Бэй-лу, с. 96].

Фольклор әсәрләре Чыңгыз титулының килеп чыгуын да аңлатырга омтыла. Мәсәлән, Чыңгыз исемен диңгез сүзеннән ясалган һәм «Чыңгызхан»ны «Диңгез хан», «Окай-хан», «Диңгез кебек зур» дигән мәгънәне бирә дигән фикерне очратырга мөмкин. Океан-диңгез төшенчәсе бу очракта космогоник төсмергә ия. Д. Банзаров Чыңгыз титулы сөннәрнең үз ханнарына биргән tchen-yu (чен-ю) Тәңре-кубу ягъни «Күк улы»ннан килеп чыккан дип фаразлый. Сөн телендәге tchen-yu – кытайча Чингис «Күк улы» [Банзаров, с. 176–177].

Риваятьләр буенча, Тимучин дөньяга укмашкан кан учлап туа. Бу мотив геройның киләчәгенә ишарә булып чыга. Киләчәктә хөкемдар, бер яктан, ныклы карашка ия – кырыс булса, икенче яктан, аның шәфкать-миһербан белмәве, кеше гомере белән санлашмавы да риваятьләр тууга җирлек була.

Чыңгыз ханның сугыш тактикасы, басып алынган ил халкына карата шәфкатьсезлеге лә риваять-легендаларга кереп калган. Риваятьләрдә яулап алынган Минья империясенең Вула Хэ шәһәрен алу өчен, кошлар ярдәмендә ут төртү, Харәзм шәһәрен су астында калдырып, ахырда аның урынына арпа чәчү бәян ителә.

Чыңгыз хан турындагы риваять-легендаларда беренче планга чыккан төп кыйммәт – бердәмлек һәм тугрылык.

Бердәмлек мотивы легендар Алан-гоа образы белән бәйле риваятьтән үк башлана һәм Чыңгыз хан турындагы һәр риваять-легендада кызыл җеп булып сузыла. Алан-гоаның улларына, бердәмлеккә чакырып, үгет бирүе тасвирлана. Ул һәрберсенә берәр чыбык биреп, аны сындырырга куша. Аннары аларга, яңадан сындырыр өчен, бергә бәйләнгән 5 чыбык бирә... Плутарх бу сюжетны б. э. к. II–I гасырларда Кара диңгез буенда яшәгән скифларга нисбәт итә. Бердәмлек

идеясен чагылдырган әлеге сюжет татар халкында да борынгыдан ук мәгълүм. Җәләлетдин Ата-Мәлик Җүвәйни аны Чыңгыз ханның үзенә бәйле вакыйга буларак искә ала [Чингисхан, с. 29]. Җүвәйнинең хезмәтендә Чыңгыз хан турында тагын бер риваять урын алган. Анда халыкка бердәмлекне тәэмин итүче юлбашчы кирәклеге әйтелә.

Риваятьләрдә Чыңгыз ханның хатыны Бүртегә, улларына булган мөнәсәбәте дә яктыртыла. Аноним авторның «Шәдҗәрәт әл-әтрәк» («Төркиләрнең шәҗәрәсе») хезмәтендә, Җүчинең үлемен тасвирлаган тезмә һәм чәчмә өлешләр аралашып килә.

Риваять кысасына кергән төрки җырдан халыкның Чыңгыз хан турында яхшы мәгълүматлы булуы аңлашыла. Чыңгыз хан улы Җүчине үзенең уң кулы, төп таянычы дип саный.

«Шәдҗәрәт әл-әтрәк»тә Җүчинең үлеме тасвирланган эпизодта Чыңгыз ханның улын никадәр яратуы, хөрмәт итүе, аңа ышануы ачык күренә. Җүчинең үлем хәбәре килеп җиткәч, бу турыда беркем дә Чыңгыз ханга җиткерергә кыймый. Бу авыр эшне хезмәткә Олуг-Җырчы исеме белән кереп калган чичәнгә тапшыралар. Чыңгыз хан җырларга кушкач, Олуг-Җырчы түбәндәге җырны башкара:

Тенгиз баштын булганды, ким тондурур, а ханым?
Терек тубтым джыгылды, кем тургузур, а ханым?

Чыңгыз хан да җыр белән җавап бирә:

Тенгиз баштын булганса, тондурур олум Джучи дур,
Терек тубтым джыгылса, тургузур Олум Джучи дур.

Олуг Җырчы үзенең җырын кабатлый, бу вакытта аның күзләреннән яшь ага башлый. Һәм шул вакытта Чыңгыз хан бөтенесен аңлый:

Көзөң йәшен чөкүртүр көңлүң толды болгаймы?
Җырың күңел өкүртүр Джучи үлде булгаймы?

Олуг Җырчы янә җыр белән җавап кайтара:

Сөйлемәккә иркем юк, син сөйләдең, а ханым!
Үз ярлыгың үзгә җаб айу өйледен, а ханым!

Чыңгыз хан беркем дә әйтергә кыймаган хәбәрне үз авызы белән әйтә. Үз соравына үзе җавап бирә. Соңгы сүзләреннән Чыңгыз ханның югалтуны бик авыр кичерүе, улы белән соңгы вакытта аралары бозылуга бик нык үкенүе сизелә:

Кулун алган куландай кулунумдин айрылдым,
Айрылышкан аңкаудай эр олумдин айрылдым.
[Из родословия тюрков, с. 202].

Чыңгыз хан улы Җүчидән соң алты ай яши. Аның үлемен риваять-легендалар романтикага төреп сурәтли. Чыңгыз хан берничә тапкыр яуга чыгып та, ахырга кадәр буйсындыра алмаган Си-Ся, ягъни Тангут җирләренә якын гына урында вафат була. Риваятьләр Чыңгыз ханның Си-Ся ханлыгына кат-кат һөҗүм итүен түбәндәгечә аңлата:

Чыңгыз хан Шидургу-хаганның хатыны Гүрбелҗин-гоаның матурлыгы турында ишетеп, аны үзенә алырга тели. Хәйлә белән Шидургу-хаганны үтергәннән соң, Гүрбелҗин-гоа янына кияү булып кергәч, хатын үзенең тырнагы астыннан кайчысын алып, Чыңгыз ханның җенес әгъзасын кисеп ала. Хан кан югалтудан үлә. Икенче версиядә Чыңгыз хан бу ярадан исән кала. Әмма ул өенә кире кайта алмый, юлында үтеп чыкмаслык киртәләр хасил була. Ул, яңадан-яңа җирләр яулый-яулый өеннән ераклаша гына бара.

Фольклорда Чыңгыз хан – Күкләр улы, үлемсез зат. Шуңа күрә дә аның үлемен халык кабул итә алмый. Һәм Чыңгыз ханның юклыгын хәбәр итү, башка дөньяга караган (Улан-хатун шулма, ягъни явыз рух, пәри) хатын булмаса, хан мәңге яшәр иде дигән идеяне үткәрү максатыннан шундый әсәрләр иҗат ителә.. Чыңгыз хан үләр алдыннан үзенең берничә йөз яки мең елдан кабат кайтачагын әйтә.

Төркиләрнең «Дәфтәре Чыңгызнамә»сендә Чыңгыз хан халык мәнфәгатьләрен кайгыртучы гадел хөкемдар буларак тасвирлана.

### Әдәбият

*Козин С.А.* Сокровенное сказание. Монгольская хроника 1240 г. / С.А.Козин / Институт Востоковедения АН СССР. М.; Л.: Изд-во АН СССР, 1941. Т. I.

Дәфтәре Чыңгыз-намә / китапны басмага хәзерләүче сүзлек һәм аңлатмаларның авторы Сәлим Гыйлаҗетдинов. Казан: Иман, 2000.

Мэн-да Бэй-лу («Полное описание монголо-татар»). Факсимиле ксилографа / перевод с китайского, введение, комментарий и приложение Н.Ц. Мункуева. М.: Наука. Гл. ред. восточной литературы, 1975.

*Банзаров Доржи.* Собрание сочинений / Доржи Банзаров. – М.: Изд-во Академии наук СССР, 1955.

Чингисхан. История завоевателя мира записанная Ала-ад-Дином Ата-Мелик Джувейни. – М.: Магистр-Пресс, 2004.

Из родословия тюрков: Сборник материалов относящихся к истории Золотой Орды. Извлечения из персидских сочинений собранные В.Г. Тизенгаузеном. Т. II. М; Л.: Изд-во АН СССР, 1941.

***Закирова Илсөяр Гамил кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 398.8

*А.Х. Садекова*

# М.С. МӘҺДИЕВНЕҢ «БЕЗ – КЫРЫК БЕРЕНЧЕ ЕЛ БАЛАЛАРЫ» ПОВЕСТЕНДА ФОЛЬКЛОРИЗМНАР

Статья посвящена исследованию взаимосвязи фольклора и литературы в произведении татарского писателя М. Магдиева «Мы – дети сорок первого года».

**Ключевые слова:** фольклорный текст, песня-дудак, баиты, народный юмор, народные сказы.

The article explores the relationship between folklore and literature in the Tatar writer M. Magdiev’s novel «We are children of the forty-first year».

**Keywords:** Folklore text, song-dudak, bayet, folk humor, folk tales.

Мөхәммәт Мәһдиевнең (1930–1995) 1968 елда татар әдәбиятына килүе зур вакыйга була [Мәһдиев, 1968]. Аның «Без – кырык беренче ел балалары» дигән повесте укучыларны тетрәндерә. Аннан соң да ул күп әсәрләр язды. Әмма монысы мәңгегә әдәбият тарихында калды. Аны тәрҗемәчеләр 1974 елда ук рус телендә яңгыраттылар. Э. Салихова тәрҗемәсеннән соң Р. Ахуновныкы басылды. Әмма кайбер әсәрләр ана телендә мәңгеләшә. Мәһдиевнең теле шул хәтле уникаль, милли, хәтта тәрҗемәдә тел матурлыгы югала сыман.

Бу турыда татар энциклопедиясендә дә язылган: «М.С. Мәһдиев “Без – кырык беренче ел балалары” исемле беренче повесте белән үк үзен үзенчәлекле иҗат стиле булган язучы итеп танытты. Аңа лиризм, нечкә юмор, үзенчәлекле тел-бизәкләү чаралары хас» [Татар энциклопедиясе, т. 4, б. 111].

Мәһдиев әсәрләренең теле – Казан артындагы саф татар теле. Ул хәтта локатив сыйфатка ия дияргә мөмкин. Һәм аны махсус семинарларда өйрәнергә була. Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның әсәрләре дә нәкъ шушы телдә язылган.

М. Мәһдиев повестеның теле үзенчәлекле, фольклоризмларга гаҗәеп бай, аны хәтта фольклор текстына якын дип тә әйтергә мөмкин. Ул мәкальләрне, җырларны, авыл риваять-сөйләкләрен, бәетне, мәзәкне әсәр тукымасына сеңдерә. Фольклорчы буларак, экспедицияләрдә йөреп, халык иҗаты әсәрләрен язып ала. 1964 елда Новосибирскида, 1965 елда Курган өлкәснең Сафакүл районында була. Бик күп яңа материал таба. Әсәрдәге фольклоризмнарның күбесе Арча ягы халык иҗатыннан. М. Мәһдиев халык иҗатын ишетеп кенә түгел, теоретик яктан да бик яхшы белгән мөгаллим, галим. Ул татар фольклорын, XIX–XX гасыр татар әдәбиятын Казан дәүләт университетында күп еллар укыта [Мөхәммәт Мәһдиев, 2004, б. 43, 51–52].

«Без – кырык беренче ел балалары» повестеның эчтәлеге бик гади кебек: сугыш еллары, ач, ялангач авыллар, әтиләр сугышта булу сәбәпле үсмерләр колхоз басуларында авыр хезмәттә. Педагогика училищесы студентлары турында шактый күңелсез хикәя. Студентларның хыялы бер генә – ашау, аларның авызга нәрсәдер кабасы, йотасы килә. Әмма шушы фонда, иң авыр хәлләрдә дә автор юморга урын таба ки, әсәр йотлыгып укыла. Бу – күз яшьләре аша көлү булып яңгырый.

Хикәяләү бер студент исеменнән алып барыла.

Укытучыларны да әллә ни теләп каршыламыйлар. Ләкин барысын да түгел: менә ул керә, завуч, рус теле укытучысы, Мәскәү татары диләр. Таләпчән, төз гәүдәле. Малайлар бит хатын-кызлар укыткан мәктәпләрдән җыелганнар, нык таләпкә өйрәнмәгәннәр. Әмма рус теле укытучысы аларны, язудагы хаталарын мыскыл итеп, кулга ала. Малайлар тәнәфестә батыраялар, аның күзлек пыяласын рогаткадан атып ватарга хыялланалар. Әмма бу хыялның буш икәнен автор мәкаль аша «белдерә» («Бүрәнә аша бүре куу»). «Мәкальләр, образлы буларак, тормыш тәҗрибәсен гомумиләштереп билгеле бер нәтиҗә, хөкем, гыйбрәт, нәсыйхәт өчен мораль нәтиҗә чыгаралар. Мәкаль гомер-гомергә халыкның аерылгысыз юлдашы, киңәшчесе, акылы, үгет-нәсыйхәтчесе булып килгән» [ТХИ. Мәкальләр, 1978, б. 7, 95].

Әсәрнең төп персонажлары яшүсмерләр – Әркәшә, Әлтафи, Зарифуллин. Әркәшә Пермяков – ветеринар улы, ул рус егете, ләкин татар авылында аның туган теле – татар теле, аларның гаиләсендә дә татарча сөйләшәләр. Әркәшә рус телендә атларның төсен (масть) әйтеп бирә. Укытучы аны мактый: «Май чүлмәге тышыннан беленә», – ди. Әркәшә өчен күңелсезлекләр дә килеп чыга. Ирексездән «Бәхетсезгә – вакытсыз», «Бәхетең бер йомарланмасын» мәкальләре искә төшә. Әсәрдә түбәндәге юллар бар: зоология дәресендә Әркәшә кара тараканның кан йөреше системасын аңлатырга тиеш була. Әркәшә өнсез кала һәм нәрсәдер искә төшерергә тырыша:

«– Ата кара тараканның кан әйләнеше... Кан әйләнеше... гаять... гаять...

– Йә, йә, ди укытучы, сәгатен озак итеп куенына сала-сала, – йә, шуннан...

Әркәшәнең каушаудан борыны тыгылды.

– Ата кара таракаттык... Кара ата таракаттык... гаять... гаять...

“Гаять” Әркәшә өчен капкын булып чыкты».

Бу юлларны укыганда көлми калу мөмкин түгел.

Әмма Әркәшәгә мәзәк түгел. Укытучы аны эшлексез, зыян китерүче дип атый. Көненә 500 грамм ипи бирелә торган карточканы туктатам дип куркыта. Тараканның кан әйләнеше системасын белмәгәч, Әркәшәдән бернинди файда юк. Бик көлкеле хәл, әмма бу бит сугыш чоры. Ипи карточкаң булмаса, эш харап. Аларның гаиләсендә 8 кеше бит. Классташлары аны коткару эшенә керешәләр. Әлтафи һәм

студентлар укытучыга (ул завхоз да) үтмәсләнгән көрәкләрне кайрарга тәкъдим итәләр, һәм бәрәңгене казып алырга булышалар. Таракан онытыла. Текстта исә мондый ярдәм мәкаль белән аңлатыла: «йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын».

Зарифуллинның тәнәфестән соң класска керүен автор болай сурәтли: «Тәртә арасына җигелергә кергән үгез кебек авыр керде». Әмма шул вакыт класска аларның яраткан рус теле укытучысы килеп керә. Һәм класс гадәттәгечә тына, «Слово о полку Игореве»не тыңлыйлар. Зарифуллин борынгы шигърият моңына чума, алар текстны хор белән кабатлыйлар. Зарифуллин сокланып, качмаска, калырга була.

Педучилищега кайткач, укытучының Пушкинның «Евгений Онегин»ын хикәяләве тәэсирендә, студент төшендә Евгений Онегинны күрә – ул ялт иткән цилиндрда, ак перчаткалардан, лорнеттан. Алар Онегин, белән котелок тотып, кайнар суга чират торалар, Онегин исә чабатадан. Мәзәк, әмма көләсе килми.

М. Мәһдиев – кеше җанының зур белгече. Аның тылдагы яшүсмерләр тормышы турындагы әсәрендә көлү күз яше белән өретелгән.

Укытучылар да – сугыш корбаннары. Алар үзләре дә ач, әмма шундый ук ач бала училищедан кача. Сәбәбе – Әлтафи белән сугышу. Әмма ул көчлерәк була. Гыйззәтуллин аны Мөрәле авылыннан булуда гаепли, алар белән бәйләнсәң – судларга бирәләр (авылларның холыклары турында галим Нәкый Исәнбәттә әйтемнәр бик күп). Алар «Балалар фольклоры» томына да кергән. Андый шаян характеристикалы авыллар Татарстанның төрле районнарында бар. Мәсәлән, Казан ягы авыллары турында:

Барган идем Көеккә,  
Утыртыллар биеккә.  
Барган идем Күәмгә,  
Утыртыллар түбәнгә.  
Барган идем Сәрдәгә,  
Утыртыллар Әрҗәгә.  
Утырам да утырам.  
Беркемдә юк җәлләргә  
[Балалар фольклоры…, 1984, б. 78].

Димәк, язучы авыллар турында гыйбарәләрне ишетеп белеп кулланган.

Гыйззәтуллин рус теле дәресендә дә бәлале була: «задание на дом»ны – «назания на дом», «назано за дом» – дип бутала. Һәм качып китә.

Җәйге каникулларга студентлар да авылларга тарала. Язучы табигать күренешләре һәм кеше күңеле арасында тәңгәллекләр үткәрә. Гыйззәтуллин исеменнән сулыкларның, күлләр, елгаларның үзенчәлекләрен аңлата. Кечкенә күлле, инешле җирдә яшәгән кешеләр борчулы, көнче, дип уйлый Гыйззәтуллин. Аның авылында

чишмәләр бар, һәм аның чылтыравын ишетеп үскән балаларда музыкага мәхәббәт уяна, урманның янәшәдә булуы да ярдәм итә.

Дөрес, Гыйззәтуллинның әнисе урманда кара еланнарның да булуын әйтә. Халык сөйләвенчә, бер кыз адашкан һәм урманда кунган, ә икенче көнне аны үле килеш тапканнар. Бурсык канын эчкән имеш. Бер кыз урманда йоклаган һәм төш күргән: су эчә дә, су эчә икән. Ә өендә елан йотканы билгеле булган. Багучы аңа тоз ашаткан, су бирмәгән. Кызны эссе мунчага илткән, янәшәсенә сөтле савыт куйган. Елан эссегә түзмичә, кызның авызыннан чыгып, сөтле савытка төшкән. Бүреләр турында да уйдырмалар күп. Бер малай бүре өненә кергәч, ана бүре кайткан да, арты белән керә икән. Койрыгы белән малайга кагылгач, ул, энесе дип, кычкырып җибәргән. Бүре, куркып, чыгып качкан, ә малай өндә калган. Бу жанр – сөйләк дип атала. Русча – быличка. Ул татар фольклорында аз тикшерелгән.

Мондый куркыныч хикәяләр балалар бүрәнә өстенә җыелгач сөйләнә иде, ди язучы. Сугыш башлангач, бар да бетә. Урманнан утын ташу газапка әйләнә, чөнки кул арбаларын тарту бик авыр була. Сугыш урманның әкиятен, матурлыгын, романтикасын бетерә. Урман җылытучы һәм ашатучыга әйләнә.

М. Мәһдиевнең бу әсәрендә дә, башка әсәрләрендә дә табигать күренешләре (мәсәлән, «Бәхилләшү» повестендә) мул тасвирлана. Әсәрләрнең тукымасына җай гына кереп урнашып, аларны матурлый, легенда, хикәя – сөйләкләр белән баета.

Әсәрдә шаярулар күп, яшьлекнең сугыш чорында да шатлыклары бар. Колхозда эшләгәндә, туңып беткән, черегән бәрәңгедән коймак пешереп ашаган студентлар шаяртырга җай табалар. Әлтафи ак ипи бал белән бик тәмле дип хыялланып утыра:

«– Яңа бал беләнме? – диләр.

– Әйе, әйе.

– Кайчан ашадың? Кем сыйлады.

– Әй, Ташлытау базарында берәү ашаганны күрдем».

Мәзәкләрнең көтелмәгән чишелеш белән тәмамлануы – зарури шарт. Димәк, алар жанр поэтикасын тәэмин итә торган чара һәм алымнарга керә. Шундыйларның берсе – алогизм. Кайвакыт алогизм сәбәп һәм нәтиҗә бәйләнешен кыскарту аркылы барлыкка китерелә [ТХИ. Мәзәкләр, 1960, б. 17]. Әлеге мәзәктә дә алогизм бар. Чөнки чит кеше ашаган ипи турында «бик тәмле» дип сөйли Әлтафи. Егет, географтан рөхсәт сорап, азрак акча эшләмәкче була. Мич чыгара, башка эшләрдә катнаша. Туйганчы кыстыбый ашап кайта, бераз акчалы да була. Ул атлас немец карталары сатып ала. Бу уңайдан автор төрле татар өлкәләрендә фольклорчылар язып алган «Зөлхәбирә» бәетен искә ала. Ул бәеттә гүзәл кыз Зөлхәбирәне этисе Мостафа мулла, карта уйнап, бер очракта попка оттыра, икенче очракта – исправникка, дип сөйлиләр информантлар. Әмма горур кыз мондый явызлыкка риза булмый. Үзен-үзе һәлак итә.

Бәетләр – татар халкының менталитетын, хыял, ниятләрен чагылдырган, бик борынгыдан халык хәтерендә сакланган сөйләп һәм көйләп язма һәм телдән иҗат юлы белән бәян ителгән әсәрләр [ТХИ. Бәетләр, 1960, б. 17, 65]. М. Мәһдиев повестенда кыска гына искә алынган «Зөлхәбирә» бәете бик популяр булган. Ул «Татар халык иҗаты»ның бәетләр томында да урын алган. «Арча суларының буйларында былбыл кошлар оча һавада. Зөлхәбирә кызны сорасагыз – үтеп китте фани дөньядан [ТХИ. Бәетләр, 1960, б. 17, 214–216]. Арча сулары искә алына. Бәлки бәеттә бу якларда кайчандыр булган вакыйга бәян ителгәндер. Чөнки мондый әсәрләр булган фаҗига эзеннән языла.

Шушы бәет персонажлары карта уйнаучы дүрт студентка дәрт бирә. Бер картаны – поп, берсен – Зөлхәбирә, тагын берсен – мулла Мостафа дип атап, карта сугалар. Шулай итеп, бәет мәзәккә әйләнә. Яшьлек шуклыгы дияргә генә кала. Аларның карта уйнаганын тарих укытучысы күрә, әмма бу турыда директорга җиткерми.

Малайларның шуклыклары җәзасыз кала.

Студентлар практика узгач, колхозга эшкә китәләр. Эш авыр, әмма 400 г ипи бирелә. Һәрберсенә – яртышар литр сөт. Хуҗалар исә сөттә изгән, мичтә кызарткан изгән бәрәңге белән сыйлыйлар, ач балаларның хыялы тормышка аша. Эштән соң алар колхозчыларның ялын оештырырга, рухларын күтәрергә тиеш булалар.

Концертта фронт җырларын яңгыраталар. Студентка Нина рус халык җырын матур итеп башкара. Студентлар тирә-юнь авылларда концертлар куеп дан казаналар. Спектакльләр, инсценировкалар, җырлар булсын – халык күтәреп ала. Мәсәлән, Мәтәскәдә Әлтафи җитәкчелегендә борынгы татар җыры «Әй дүдәк»не башкаралар. Повестьта бу бик матур итеп тасвирлана. Кушымталарда үрдәкләр һәм казлар кычкырырга тиеш. Халыкка бу бик ошый. Бөтен зал, я үрдәк, я каз булып кычкырып, егылып көлә. Студентларның концертлар белән ешрак килүен сорыйлар.

М. Мәһдиевнең «Әй дүдәк» дигән җыры фольклор томнарына кермәгән, чөнки ул жыр Г. Тукайның җырлар томында гына сакланган. Бу дәфтәр институт архивында саклана. Текстны китерәбез:

Йөгерә үрдәк, йөгерә каз
Боты озынга күрә.
Әй, дүдәк, дүдәк, дүдәк,
Басма өстендә каз, үрдәк,
Кыйгак-кыйгак,
Бак, бак, бак, бак,
Басма өстендә каз, үрдәк.

Без кызларны яратабыз
Бите кызылга күрә.
Әй, дүдәк, дүдәк, дүдәк,
Басма өстендә каз, үрдәк,

Кыйгак-кыйгак,
Бак, бак, бак, бак,
Басма өстендә каз, үрдәк.

Йөгерә үрдәк, йөгерә каз,
Кала эзеннән тамга.
Әй, дүдәк, дүдәк, дүдәк,
Басма өстендә каз, үрдәк,
Кыйгак-кыйгак,
Бак, бак, бак, бак,
Басма өстендә каз, үрдәк.

Үтә матурларны сайлап,
Урта матурдан калма.
Әй, дүдәк, дүдәк, дүдәк,
Басма өстендә каз, үрдәк,
Кыйгак-кыйгак,
Бак, бак, бак, бак,
Басма өстендә каз, үрдәк [ТӘһСИ. Кулъязма…].

Тукай заманында ук халык җырлаган бу җырны М. Мәһдиев яңадан халыкка кайтарды.

Шагыйрь Ренат Харис болай яза: Ул (Мәһдиев) җырчы иде. Ул җырларның нечкә күңел белән генә тоеп була торган эчкәреге серләрен белә иде һәм шул серләрдән үзенең роман, повестьларын язганда да бик оста файдалана иде [Мөхәммәт Мәһдиев, 2004, б. 29–30]. Бу без анализлаган әсәрдә дә күренә.

Башка авылларда программа яңартыла. Зарифуллин ялгыз җырларга батырчылык итә һәм уңышка ирешә. Аңа хәзер «Ике дөнья бер – уртасы камыр».

Популяр җырлар арасында яшелчәчелек, яшелчә үстерү турындагы такмаклар бар. Студентлар яшелчәләр булып киенәләр: Нина – борыч, Баязитова – суган, Гыйззәтуллин – торма, Әлтафи – кишер, Зарифуллин – кыяр. Җырлар да шундыйрак эчтәлекле:

Ашны тәмләндерим дисәң,
Күберәк утырт кишер,
Кишер утырткан кешеләр
Зур уңышка ирешер. һ. б.

Яшелчәләр турындагы җырлар тирә-юнь авылларга да таралган. 1984 елгы экспедиция вакытында мондый җырлар Зур Кукмара авылында язып алынды. Алар халык репертуарында сакланган.

Повестьта халыкның сугыш елларында тормыш авырлыкларына түзеп, җырлар, әйтемнәр, мәкальләр, мәзәкләр белән хисләнеп яшәве сурәтләнә: 1945 ел җитә, солдатлар кайта башлый. Зарифуллинның да абыйсы кайта. Киләчәккә, яңа, яхшы тормышка өметләр арта. Әсәрдә халык тормышының панорамасы бирелә.

Этнографик күренешләр, фольклор үрнәкләре, табигать матурлыгын тасвирлау әсәргә оптимистик рух өсти.

**Әдәбият**

Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен / төз. Н. Исәнбәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.

ТӘһСИ, Кульъязма һәм музыкаль мирас үзәге. Фонд 1, тасвирлама 21 (Габдулла Тукайның җырлар дәфтәре).

*Мәһдиев М.* Без – кырык беренче ел балалары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1968.

Мөхәммәт Мәһдиев. Язучы турында замандашлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.

Татар энциклопедиясе. Т. 4. Казан, 2014. Б. 111 (Д.Ф. Заһидуллина, Р.Ә. Мостафин).

Татар халык иҗаты. Бәетләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1960.

Татар халык иҗаты. Мәзәкләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1960.

Татар халык иҗаты. Мәкальләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978.

***Садекова Айсылу Хөсәен кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 373.4 + 811.512.145

*М.М. Шәкүрова,*
*Л.М. Гиниятуллина*

# МӘКТӘП ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕНЕҢ ЗАМАНЧА КОНЦЕПЦИЯЛӘРЕ

Государственная политика в области образования на современном этапе направлена на модернизацию школьного учебного процесса. Одним из ее направлений является обновление учебного содержания в логике компетентностного подхода, что требует создания новых школьных учебников. Данная статья посвящена изучению и анализу существующих на практике концепций школьного учебника. Цель статьи – сделав определенные выводы, выдвинуть собственные предположения о новом формате учебника по родному (татарскому) языку.

**Ключевые слова:** концепция, учебник, родной язык, татарский язык, образовательный процесс.

State policy in the field of education at the present stage is aimed at modernizing the school educational process. One of its directions is updating the curriculum in the logic of the competency-based approach, which requires the creation of new school textbooks. This article is devoted to the study and analysis of existing in practice concepts of a school textbook. The purpose of the article is to draw certain conclusions and put forward our own assumptions about the new format of the textbook on the native (Tatar) language.

**Keywords:** concept, textbook, native language, Tatar language, educational process.

Татар телен туган тел буларак укыту өчен гамәлдәге программаларны, дәреслек һәм методик кулланмаларны заман таләпләренә туры китереп эшләү һәм аларның нәтиҗәлелеген объектив бәяләү иң актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора. 2017 елдан башлап яңа үрнәк программалар төзү, стандартлар эшләү, дәреслекләр язу, аларны куллануга кертү һәм башка мәсьәләләр үзәктә тора. Соңгы елларда безне борчыган проблемалар (татар телен туган тел буларак өйрәнүгә гомуми белем бирү оешмаларында һәм тулаем алганда җәмгыятьтә ихтыяҗның түбән, уку материалының катлаулы һәм күләмле булуы, укучыларның яшь үзенчәлекләренә җавап бирә торган аңлаешлы, кызыклы, коммуникатив компетенциягә нигезләнгән дәреслекләрнең азлыгы) яңа дәреслекләр эшләүгә этәрә [Шәкүрова, Гыйниятуллина, 2018, б. 10]. Татар баласын туган телендә иркен аралашырга, логик эзлеклелектә уйларга, сөйләшергә өйрәтүнең яңа юлларын эзләү чорында яшибез. Әлеге мәсьәләләрн хәл иткәндә, укучының иптәшләренә, гаиләсенә, әйләнә-тирәгә, Туган иленә, татар дөньясына үз мөнәсәбәтен белдерә алуы, шулар ярдәмендә сөйләмен үстерүе, тел байлыгын арттыруы, туган телне өйрәнүе күз уңында тотыла. Бу мәсьәләләр туган (татар)

телне укытуның яңа юнәлешләрен кичекмәстән барлауны һәм гамәлгә кертүне таләп итә. Соңгы елларда телне укытуда лингвистик компетенциянең өстенлек итүе, бай лексик мирасның җитәрлек бирелмәве, дәреслектәге күп кенә грамматик формаларны үзләштерүнең аерым җөмләләргә бәйләп алып барылуы, текст белән эшләү механизмын белмәү һәм башкаларны ассызыклау зарур.

Бүгенге көндә дәүләтнең белем бирү өлкәсендәге сәясәте мәктәп укыту системасын яңартуга юнәлтелә. Җәмгыятьтә мәктәптә алган белемнәрен гамәлдә файдалана алырдай кешеләргә ихтыяҗ зур. Мәктәп этабында белем бирү системасын яңартуның бер юнәлеше – аның эчтәлеген үзгәртү. Шуңа бәйле рәвештә гамәли юнәлешле мәктәп дәреслекләре эшләү беренче планга чыга. Әлеге дәреслекләрдә түбәндәгеләрне исәпкә алу зарур:

– укучыларның яшь үзенчәлеге;

– укучыларда төп компетенцияләрне формалаштыру;

– ачык белем бирү мохитен дөрес файдалану;

– балаларда мөстәкыйльлек тәрбияләү;

– укучыларны аралашырга өйрәтү;

– укучыга йөкләнгән эш күләменең санитар нормаларга туры килүе.

Әлеге таләпләрдән чыгып, шуны әйтергә була: дәреслектә бирелгән гамәли материалдан укучы тормышта файдалана алырга тиеш.

Бүгенге көндә белем бирүнең төп максаты – белемнәрне формалаштыру түгел, ә мәгълүмати җәмгыятьтә балага үз урынын табарга булышу.

Элек дәреслек белем бирү чыганагы булса, заманча дәреслекләрдә мәгълүматны табарга өйрәтү алгы планга чыга. Тиз үзгәрүчән һәм мәгълүматка бай дөньяда укучының мөстәкыйль эш итәргә өйрәнүе кирәк. Шуннан чыгып дәреслекләрнең форматы, уку текстлары һәм эш төрләре игътибар үзәгенә куела.

Традицион дәреслекләрдә өч компонент урын ала: теоретик материалны үз эченә алган параграфлар, белем, күнекмәләрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр җыелмасы. Дәреслекләр күпме генә үзгәреш кичерсә дә, XX гасырның икенче яртысыннан әлеге өч компонент саклана килде [Гыйниятуллина, Шәкүрова, 2018, б. 56]. Әлеге төзелеш төрле авторларның күпчелек дәреслекләренә хас. Шушы күзәтүләр нәтиҗәсендә «Ни өчен, дәреслекләрнең эчтәлеге тамырдан үзгәрүгә карамастан, аларның форматы шул килеш кала соң?» дигән сорау туа. Ни сәбәпле дәреслекләрнең эчтәлеге үзгәрү аларның структурасын үзгәртү белән бергә алып барылмый?

Заманча дәреслекләр эшләү мәктәп дәреслекләренең яңа теоретик концепциясен булдыру белән бәйле. Гамәлдә булган дәреслек концепцияләренең кайберләрен карап китик һәм аларга хас төп үзенчәлекләрне билгелик.

**Теркәлгән форматтагы дәреслек концепциясе.** Әлеге концепция А.И. Герцен исемендәге Россия дәүләт педагогика университеты

галимнәре (А.П. Тряпицына, Н.Ф. Радионова, С.А. Писарева, О.В. Акулова, Е.В. Пискунова, Т.В. Менг, Р.У Богданова, О.Н. Крылова һ. б.) тарафыннан тәкъдим ителә. Авторлар бу форматны заманча дәреслекнең иң камил моделе дип атыйлар. Әлеге модельнең методологик нигезен компетентлы якын килү технологиясе тәшкил итә [Шакурова, Юсупова, 2017, с. 124].

Теркәлгән формат нигезендәге дәреслекләрдә һәм дәреслек линияләрендә һәр бүлек билгеле бер структурага ия була. Параграф, бүлек, дәреслек, линия, предметның эчтәлеген ачу белән беррәттән, укучыларда төрле компетенцияләр дә формалаштыра. Дәреслекнең һәр компоненты (текст, биремнәр, иллюстрацияләр һ. б.) дәреслеккә билгеле бер тәртиптә кертелә.

В.П. Дронова җитәкчелегендә эшләгән галимнәр төркеме билгеләнгән форматтагы дәреслек концепциясенә охшаш модель тәкъдим итә. Алар мәгълүматны махсус эшләнгән форматта ике биткә урнаштырып бирүне тәкъдим итә. Һәр параграф билгеле бер алгоритм, схема буенча урнаштырыла.

Теркәлгән формат нигезендә эшләнгән дәреслекнең иске форматтагы дәреслекләрдән аермасы аның дәреслек навигатор вазифасын да башкаруында. Анда биремнәр формасында башка уку-укыту ярдәмлекләренә (электрон кушымталар, энциклопедияләр, сүзлекләр һ. б.) сылтамалар күрсәтелә. Авторлар беренче чиратта төп ике бурычны истә тотып эш итә:

1) белем бирүдә эшчәнлекле якын килүне тормышка ашыру;

2) мәктәптә белем бирү баскычлары арасында элемтә булдыру.

Татар телен туган тел буларак укыту өчен булган гамәлдәге башлангыч сыйныф дәреслекләре дә билгеләнгән форматка нигезләнә. Алар укучыларны белем бирү мәгълүмати мохитенә катнаштыру, аларда төрле бурычлар чишүдә шәхси тәҗрибә булдыру бурычын чишүне алга чыгара.

Тагын бер дәреслек форматы – **технологик дәреслек**. Кубань дәүләт университеты галимнәре (А.И. Архипова, И.Д. Брегеда, Е.Н. Жужа) фикеренчә, яңа буын мәктәп дәреслекләре өч юнәлешне берләштерү юлы белән барырга тиеш: уку-укыту мәгълүматы, дидактик инновация, информацион технологияләр. Әлеге өч юнәлеш берләшү нәтиҗәсендә «мәгълүмат + дидактика + компьютер» формуласын тормышка ашыра торган яңа уку-укыту продукциясе туарга тиеш. Традицион дәреслекләрдә бер генә компонент – мәгълүмат, электрон дәреслекләрдә ике компонент – мәгълүмат + компьютер компонентлары гына бар. Яңа тип дәреслекнең моделен компьютер программалары кушымтасы булган технологик дәреслек тәшкил итәргә тиеш. Биредә белем бирү материалының төп күләме традицион булмаган ысуллар һәм алымнар ярдәмендә үзләштерелү күздә тотыла.

Технологик дәреслек ике: гамәли һәм методик өлешләрдән тора. Гамәли өлеш төп нигез булып тора. Дидактик блок аңа нигезләнеп

корыла һәм укучыларның программа материалын мөстәкыйль тәшкил итә һәм анда предметны өйрәнү методикасы тәкъдим ителә.

Әлеге концепциянең төп кагыйдәләре түбәндәгеләр:

1) дәреслек көчле укучыларга гына йөз тотарга тиеш түгел, ягъни күп дәрәҗәле дәреслек булырга тиеш. Дәреслектәге материал һәр белем дәрәҗәсен канәгатьләндерергә тиеш;

2) предметка кагылышлы фәнни яңалык, ачышлар укучыга аңлаешлы телдә язылып, дәреслеккә кертелергә тиеш;

3) дәреслек төрле программалар нигезендә укуны да тәэмин итәрлек булырга тиеш.

Яңа дәреслек концепцияләрен өйрәнгәннән соң, түбәндәге нәтиҗәләр ясалды:

– башлангыч сыйныфлар өчен туган (татар) тел дәреслегенең яңа форматта булуы таләп ителә;

– бүгенге көндә теркәлгән форматтагы технологик дәреслек сорала;

– дәреслек ике дәрәҗә (база һәм тирәнтен өйрәнү өлешләрен) өчен булган материалны берләштерергә тиеш.

Бу фикерләрне дәлилләп, түбәндәгеләрне әйтә алабыз:

– дәреслектәге материалның билгеле бер форматка салынуы укучы, укытучы, әти-әниләр өчен уңайлы;

– 1–4 сыйныфларда укучы өйрәнергә тиешле материалның блоклап бирелүе, аның елдан-елга кабатланып торуы, эзлеклелек һәм дәвамчанлык балага материалны яхшы үзләштерә алу мөмкинлеге тудыра;

– дәреслектә башка уку-укыту әсбаплары белән элемтә саклану, укучыны мөстәкыйль эшләргә, бүгенге көндәге бай мәгълүмат мохитендә югалып калмаска өйрәтә;

– ике дәрәҗәле дәреслек –укытучыга төрле белем дәрәҗәсенә ия булган укучылар белән эшләгәндә уңайлы формат;

– ике дәрәҗәле дәреслек финанс ягыннан да отышлы. Һәр ике дәрәҗә өчен аерым дәреслек эшләгән очракта, бастырып чыгарган дәреслекләрнең саны күпкә артыр иде;

– дәреслектән тыш уку-укыту комплектын эш дәфтәре, электрон дәреслек, төрле форматтагы электрон кушымталар тулыландырырга тиеш.

Димәк, яңа стандарт программаларга нигезләп эшләнгән дәреслекләрнең эчтәлеге, төзелеше, коммуникатив, этномәдәни һәм лингвистик компетенцияләргә нигезләнгән булуы шарт. Яңа дәреслекләрдә лексик темалар һәм алар белән бәйле әдәби текстлар һәм халык авыз иҗаты үрнәкләре, кара-каршы сөйләшү, төрле ситуацияләр һәм алардан чыгу юллары, мөстәкыйль фикерли, уйлый белүгә корылган күнегүләр, лингвистик биремнәр, рәсемнәр, логик уеннар һ. б. үзәккә алына. Иң мөһиме – баланың татар телендә үзенең фикерләрен төгәл оештырып, әңгәмәдә катнашуы, үз фикерен иркен һәм дәлилләп бирә алуы шарт. Укучыны туган теле, мәдәнияте, тарихы

белән кызыксындыра белүнең, аны татар телендә иркен аралашырга, логик эзлекле итеп уйларга, сөйләшергә өйрәтүнең яңа юллары кирәклеге ачыкланды. Шунлыктан урта (тулы) гомуми белем бирү оешмаларының гомуми башлангыч белем бирү этабында «Туган тел (татар теле)» дәреслекләре Федераль дәүләт белем бирү стандартларына нигезләнеп, ике дәрәҗәне берләштереп эшләнелә («база өлешен өйрәтү» (рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы татар төркемнәре өчен), «тирәнтен өйрәтү» (татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен).

Заман бездән баланың татар телендә үзенең сөйләмен төгәл оештырып, үз фикерен иркен һәм дәлилләп бирә белүен, туган телне укытуның максат-бурычларын һәм көтелгән нәтиҗәләрне тулы һәм ачык күзаллауны таләп итә. Татар телен предмет буларак кына укыту түгел, ә бәлки аның милли мәдәниятнең асылы, татар милләтен саклауда төп таяныч булуын алга куеп эш итү дә сорала. Яңа дәреслекләр милли менталитет, фәлсәфә, үзаң, әхлак кануннары белән таныштыруны үз эченә ала. Шуңа бәйле рәвештә һәр сыйныфта тематик материал үзара бәйләнгән дүрт зур лексик темага берләштереп бирелә: 1) «Мин», 2) «Тирә-як, көнкүреш», 3) «Туган ил», 4) «Татар дөньясы». Дәреслекләрдә лексик темалар алгы планга чыгарыла.

Беренче тема – «Мин». Укучының үз мөнәсәбәтен белдерүгә караган лексик берәмлекләр белән эш итүне күздә тота: гаилә, мәктәп, дуслар, сыйныфташлар, укытучылар, балалар өчен язылган әсәрләрнең геройлары һ. б.

Икенче тема – «Тирә-як, көнкүреш». Укучыларны кешелекле, иҗади, актив, мөстәкыйль, әйләнә-тирәне күзәтә, табигатьне саклый белә торган итеп тәрбияләүгә юнәлтелә. Яраткан уеннар, уенчыклар, халык әкиятләре, хайваннар, үсемлекләр дөньясы кебек темалар тәкъдим ителә. Алар сөйләмне үстерү, тел байлыгын арттыру максатыннан бирелә.

Өченче тема – «Туган ил»не яратырга, аның белән горурлана белергә өйрәтә: татар халкы һәм Россия Федерациясе субъектлары халыкларының гореф-гадәтләре, традицияләре аша укучыларда гражданлык, патриотик хисләр, туган илгә карата хөрмәт уяту, Россия һәм Татарстанның дәүләт символлары (гимн, флаг, герб), шәһәрләре, авыл тормышы һ. б. турында мәгълүмат бирүне максат итә.

Дүртенче тема – «Татар дөньясы». Бу темага милли менталитет, фәлсәфә, үзаң, әхлак кануннары белән таныштыру керә. Укучыны татар халкының рухи тормышы, мәдәнияте: гореф-гадәтләре, милли бәйрәмнәре (Сабантуй, Нәүрүз), уеннары («Башмакчы», «Ак калач», «Без, без, без идек», «Йөзек салыш»), милли өс киемнәре һ. б. га багышланган текстлар белән эшләргә өйрәтү күздә тотыла.

Бүгенге көндә безнең төп бурычыбыз – телебезнең бай мирасын саклау, туган телендә иркен аралаша торган шәхесләр тәрбияләү, буыннан-буынга телебезне тулы бер система буларак тапшыру, икенче тел буларак татар телен өйрәнүчеләрнең аралашуын булдыру.

**Әдәбият**

Башлангыч сыйныфларда «Туган тел» предметын укыту: яңартылган эчтәлек һәм перспективалар. Методик ярдәмлек / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина. Казан, 2018. 40 бит.

*Гиниятуллина Л.М, Шәкурова М.М.* Туган телне укыту методикасының бүгенге көн проблемалары. Монография. Казан: Вестфалика, 2018. 110 с.

*Шакурова М.М., Юсупова З.Ф.* Татарско-русское двуязычие и его использование в обучении татарскому языку // Вестник Челябинского гос. пед. ун-та„ 2017. № 7. С. 122–126.

*Публикация статьи осуществлено в рамках мероприятия 4.1.3 Государственной программы «Сохранение, изучение и развитие государственных языков Республики Татарстан и других языков в Республике Татарстан на 2014–2021 годы».*

*Мәкалә «2014–2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 4.1.3. номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Шәкүрова Мөслимә Мәгъсүм кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Гиниятуллина Лилия Миңнулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 745

*Л.М. Шкляева*

# XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ГАСЫРНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЯРТЫСЫНДА АВЫЛДА ЯШӘҮЧЕ ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ КОСТЮМЫ ЭЛЕМЕНТЫ БУЛАРАК АЛЪЯПКЫЧ БИЗӘГЕНЕҢ СТИЛЬ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**(ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИнең 2014–2018 елларда оештырылган экспедиция материаллары буенча)**

В статье описываются локальные стилевые особенности традиционных фартуков, являющихся устойчивым элементом костюмного комплекса сельских татарок-представительниц различных этнографических групп. Прослеживаются общенациональные мотивы орнаментального декора передников, а также рассматриваются проблемы сохранения самобытных эстетических принципов оформления данных изделий на современном этапе.

**Ключевые слова:** фартук, национальный костюм, традиция, локальные особенности, декоративное творчество.

The article describes the local style features of traditional aprons, which are a stable element of the costume complex of rural Tatar women representing various ethnographic groups. The national motifs of the ornamental decoration of the aprons are traced, and the problems of preserving the distinctive aesthetic principles of the design of these products at the present stage are considered.

**Keywords:** apron, national costume, tradition, local features, decorative art.

XIX гасырда Идел буенда яшәүче төрле халыкларның традицион хатын-кыз костюмында алъяпкычны көндәлек, бәйрәм һәм дини кием комплексларында очратырга мөмкин. Ул күлмәкне пычранудан саклаган, моннан тыш, алъяпкычның бизәлеш үзенчәлекләренә карап, хатын-кызның социаль дәрәҗәсен билгеләгәннәр, бизәкләр саклагыч-бөти вазифасын да үтәгән.

Барлык этнографик төркемнәрдә дә алъяпкыч авылда яшәүче татар хатын-кызлары киеменең мәҗбүри компоненты булган. Татар телендә алъяпкычның утыздан артык исеме бар. Бу аның форма һәм бизәлеш ягыннан бик төрле булуын күрсәтә [Донина, Рамазанова, с. 13]. Крестьян гаиләләрендә өйдә тукылган, кулдан чигелгән алъяпкычларны бик кадерләп тотканнар һәм буыннан буынга тапшырганнар. Бүгенге көндә дә алар күп гаиләләрдә бакыйлыкка күчкән әби-апаларның истәлеге булып саклана. Алъяпкычларның күбесе авылда яшәүче татарлар арасында костюм сәнгате чәчәк аткан XIX гасыр ахырыннан башлап XX гасыр урталарына кадәрге чорга (Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышы еллары моңа керми) карый. Хәзерге вакытта да кайбер локаль төркемнәрдә алъяпмалар тегү һәм чигеп бизәк төшерү белән шөгыльләнәләр.

Татар халкы киемендә алъяпкычларның кайчан барлыкка килүе әле дә ачыкланып бетмәгән. Тикшеренүчеләр аның тышкы характеристикаларына, тукымасына, киелү рәвешенә һәм этнографик үзенчәлекләренә күбрәк игътибар бирделәр. Татар костюмы күп кенә сәнгать белгечләренең (П.М. Дульский (1925), Ф.Х. Вәлиев (1984), Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова (1990), Л.Н. Донина (2007)) һәм этнографларның (Н.И. Воробьев (1927), М.Г. Завьялова (1997), Ю.Г. Мөхәммәтшин (1997), Р.Г. Мөхәммәтова (1997), С.В. Суслова (2000) һ. б.) һәрвакыт игътибарын җәлеп итеп килде. Әлеге теманы бигрәк тә С.В. Суслова һәм Р.Г. Мөхәммәтова тирәнтен өйрәнделәр. Аларның күпьеллык тикшеренүләргә нигезләнгән уртак хезмәтендә XIX гасыр уртасыннан алъяпкычларның татарларның барлык локаль төркемнәрендә аерым сәнгати нәфислеккә ирешүе ассызыклана [Суслова, Мухамедова, с. 109]. Галимнәр бизәкләп эшләнгән алъяпмаларның Кама алдында, Төньяк Урал буенда һәм Идел алдында киң таралуын билгелиләр. Китап авторлары алъяпкычларны, өлгесенә карап, ике төргә бүлеп карыйлар: «бил турысында (күкрәкчәле һәм күкрәкчәсез) һәм җилкәдә беркетелә торганнарга» [Суслова, Мухамедова, с. 110]. Алар күкрәкчәле алъяпкычларны иң борынгы үрнәкләр дип саныйлар. Алъяпкычларның икенче төрен белгечләр тагын өч төркемгә бүләләр. Беренче төркемгә – туры (тоташ өлге буенча тегелгән), икенчесенә – кысалы (итәге билдән киселгән), өченчесенә – кокеткалы алъяпкычлар кертелә. Кокеткага «алны һәм ян якларны каплап торган киң итәк» тегеп куела [Суслова, Мухамедова, с. 114]. Әлеге китапта бәян ителгән һәм анализланган материалның нигезендә XX йөз уртасында башланып, гасыр азагына кадәр дәвам иткән күзәтүләр ята.

Авылда яшәүче татарларның алъяпкычларына хас локаль стиль үзенчәлекләре турында фәнни әйләнештәге мәгълүматларны 2014–2018 елларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылган экспедицияләрдә тупланган материаллар тагын да тулыландырды. Аларның нәтиҗәләренә караганда, алъяпкычларның С.В. Суслова һәм Р.Г. Мөхәммәтова тарафыннан теркәлгән үзенчәлекләре буыннан буынга тапшырылып сакланган һәм XXI гасыр башы тегүче-осталарның эшләнмәләрендә дә очрый. Татарлар тупланып яшәгән урыннарда җирле авыл мәктәпләре һәм китапханә музейлары экспедиция материаллары җыйганда әһәмиятле база вазифасын үтәде. Аларның экспозицияләрендә аутентик хатын-кыз алъяпкычлары еш урын ала. Мондый эшләнмәләр кайбер гаиләләрдә дә саклана. Болары – нәселдән килгән чигүчеләр өчен үрнәк хезмәтен үти. Аларның алъяпкыч тегү һәм аңа чигеп бизәк төшерү турындагы бәяннары – әһәмиятле информация чыганагы.

Авылда яшәүче татарларның этнографик төркемнәрендә (казан татарлары, керәшеннәр һәм мишәрләр), кайда яшәүләренә карамастан, өйдә тукылган җитен һәм киндер тукыма кисәгеннән, шулай ук бер генә төстәге ситсы һәм сатиннан тегелгән алъяпкычлар

табылды. Шунысын әйтергә кирәк, гадәт буенча аларга үсемлек-чәчәк орнаментлары чигелгән. Әмма кайбер локаль төркемнәрдә алъяпкычлар чигеп бизәлмәгән. Әйтик, Самара өлкәсе Keләүле районы Назаровка авылы керәшен хатыннарының алъяпкычлары кызыл, яшел яисә зәңгәр төстә булып, чит-читләре ачыграк төстәге тасма һәм төрле төстәге билбаулар белән каймаланган. Җете куе төстәге тукыма фонында алар бик нык аерылып торганнар [Шкляева, 2015, с. 240].

Печән чапканда кия торган бала итәкле ак алъяпкычларга орнамент төшерелмәгән. Алъяпкычның җилкәләре канатлап тегелгән, бил турысын арттан төймәләнә торган киң каеш кысып торган, аның астындагы итәк вак атлатып бөрмәләп җыелган. Мондый үрнәкләр Татарстанның Мамадыш районы Югары Кыерлы (Верхний Берсут) һәм Югары Сөн авыллары музейларында саклана.

Актаныш районы татар хатын-кызларының ак һәм кара җирлекле сатин алъяпкычлары чиратлашып килгән үрмә чәчәк-яфрак мотивыннан гыйбарәт бордюр тасма белән бизәлгән. Аларның традицион өлгесе каешка тегеп куелган күкрәкчәдән һәм итәктән тора [Султанова, с. 240].

Әлеге экспедицияләрдә катнашучыларга казан татарлары яшәгән территорияләрдә җитен яки киндердән бизәкләп тукылган алъяпкычлар очратырга туры килмәде. Хәзерге вакытта мондый үрнәкләр керәшен татарларында шактый киң таралган [Шкляева, 2013]. Борын-борыннан әлеге элемент кызларның да, хатыннарның да көндәлек һәм бәйрәм киемнәрендә мәҗбүри саналган. Шакмаклап яки буй-буй бизәкләр төшереп тукылган киндер алачаларга шактый зур урын бирелгән. Элек җепне табигый буяулар белән буяганнар, шуңа алар ныклырак булганнар. Алъяпкыч тегү өчен эре шакмаклы алача алынган. Еш кына зур шакмак эченә кечкенәрәге тукылып, ритм һәм төс ягыннан контраст вариацияләр (кызыл, зәңгәр (яшел), ак һәм сары) барлыкка килгән. Җепне ачык төсләргә буяганда, анилинлы буяулар кулланганнар. Төрле төстәге геометрик орнамент чүпләм ысулы белән төшерелеп, еш кына алъяпкычның итәген бизәгән. Аляпкычның озын бауларын билгә урап, алдан бәйләп куйганнар. Олырак яшьтәге хатыннарның алъяпкычы тубык сөягенә җиткән озын күлмәкләреннән 7–10 см га кыскарак булган. Яшьләргә тезләрне каплар-капламас озынлык та рөхсәт ителгән. Дүртпочмаклы күкрәкчәнең өске читенә тар гына тукыма буйлары тегелгән, аларны муен артына бәйләп куйганнар. Бу стиль бүген дә саклана. XXI гасыр башында да керәшен хатын-кызлары, бәйрәмнәргә һәм туйларга барганда, элеккечә барысы да әбиләренең үзенчәлекле аутентик милли киемнәрен, я традицион стильдә тегелгән заманча костюмнар кияләр.

Нагайбәкләрнең матди мәдәнияте керәшеннәрнекенә бик тә ошаган. Әмма соңгыларыннан аермалы буларак, узган гасыр азагына кадәр алар өйдә тукылган алъяпкычлар гына кигәннәр. Хәзерге вакыт-

та алар костюмнарны (шул исәптән алъяпкычларны да) фабрикада җитештерелгән шакмаклы штапельдән тегәләр. Тукыманың рәсеме XIX гасыр ахыры – XX гасыр башындагы үзенчәлекле үрнәкләрне хәтерләтә. Бу чорда керәшеннәрнең һәм нагайбәкләрнең алъяпкычлары бизәкләргә аеруча бай булган. Нагайбәк хатыннары төрле төстәге йон җепләр белән уникаль ысул (бизәүдә бүгенге көнгәчә сакланмаган локаль стиль үзенчәлеге) кулланып бизәк төшергәннәр.

Оренбург өлкәсенең татар авылларындагы кәләшләр алъяпкычны йон җепләр белән «түшәп» чиккәннәр. Шундый эшләнмә үрнәген без Шарлык районының мишәрләр яшәгән Сарманай авылы музеенда очраттык [Ялчин, 2014]. XX гасырның икенче яртысыннан Оренбург өлкәсенең татар авылларында бирнә әзерләү традициясе кабат яңара [Шкляева, 2015, с. 274]. Анда бүген дә туйның икенче көнендә яшь килен үз куллары белән чигеп эшләнгән үзенчәлекле кием (шул исәптән матур чәчәк бәйләмнәре чигелгән алъяпкыч) кия. Ул, көянтә-чиләкләрен асып, чишмәгә суга бара. Барлык кунаклар да аңа иярә. Яшь килен шундагы бөтен кешене чишмә суы белән сыйлый, ә тегеләре чиләккә акча ыргыта [Шкляева, 2015, с. 275].

Башкортстанның Эстәрлебаш районы Хәлекәй авылында да шуңа охшаш йола саклана икән. Бу турыда безгә авыл җирлеге башлыгы Ф.А. Бaһaветдинов сөйләде. Аерма бары шунда: күршеләр чишмә суын кәләшнең әнисенә үз куллары белән чиккән берәр әйбер бәрабәренә «сатып алалар». Шуннан соң каенатасы яшь килененә махсус әзерләнгән, чигеп чәчәкле бизәкләр төшерелгән бәйрәм алъяпкычы бүләк итә. Килен, шуны киеп, җыелган халык алдында бии.

1950 еллар азагыннан бүгенге көнгә кадәр Оренбург чигүчеләре тоташ һәм тапкырлап чигү техникаларын өстен күрәләр. Үсемлекчәчәк мотивлары – элеккечә иң күп очрый торган сюжетларның берсе. Арада роза чәчәге аеруча популяр. Шушы үзенчәлекне Самара татарларында да очратабыз. Мәсәлән, нәселдән килгән чигүче Ф.Ф. Гайфуллинаның (Иске Ярмәк авылы) алъяпкычларына да шундый ук бизәкләр төшерелгән. Чигүче-оста нәфис тондагы синтетик тукымаларны нигез итеп алып, аларны Урта Иделдә үсә торган кыр һәм бакча гөлләре образларын үзенә җыйган чәчәк бәйләмнәре белән бизи. Ф.Ф. Гайфуллинаның сүзләренә караганда, Иске Ярмәк авылында сугыштан соң ак төстәге бәйрәм алъяпкычларының аскы өлешен генә (кечкенә алъяпкыч) кия башлаганнар. Зур мәҗлесләр вакытында хуҗабикәләр хәзер дә, кунаклар танысын өчен, шулай киенәләр. А.К. Асылгәрәева, С.А. Морзаханова кебек нәселдән килгән чигүчеләр бу традициянең Гали авылында да саклануын әйттеләр. Шунысы кызыклы, хәзерге заман чигүчеләреннән аермалы буларак, XX гасыр уртасына кадәр Самара өлкәсенең оста чигүчеләре ак, сары яисә кара төстәге нигезгә чиккәндә, чынбарлыктагы прообразлар белән охшашлыктан качарга тырышканнар. Аларның чигешләре төрле ысулларны кулланып башкарылган. Әмма,

кагыйдә буларак, һәр форманың контуры нигез тукыма төсенә контраст тамбурлы чигү белән башкарылган. Яңа Мансур авылыннан А.С. Субеева фикеренчә, инә белән түгел, ә кечкенә ыргак белән чиккәннәр. Шундый алъяпкыч Иске Ярмәк авылында саклана. Аны Ф.Ф. Гайфуллинаның әнисе Миңнеҗиһан Фартдинова чиккән. Әлеге борынгы традицион чигү үрнәгендә кара төстәге тукымада бизәкләрнең контуры тамбурлы «күпертеп чигү» ысулында башкарылган. Төп нигезнең үзәктәге раппортлары (бизәкнең кабатланып килүче өлешләре) ак, яшел, ал һәм күк төсләрдәге йон җепләр белән келәм ысулында чигелгән.

Чиләбе өлкәсенең Нязепетровск районы Арыслан һәм Әптерәк авылларында татар хатын-кызларының алъяпкычларына хәзер дә борынгы тамбурлы чигү ысулын кулланып бизәк төшерелә. Чигүле альяпмаларның итәкләре, җилкә каешлары һәм канатлары төрле төстәге матур чәчәкләр белән тулган. Бу – милли бәйрәм костюмының мәҗбүри элементы.

Шулай итеп, XX гасыр уртасына кадәр алъяпкычлар авыл җирендә яшәгән татар хатын-кызлары костюмының бер өлешен тәшкил иткән. Безнең көннәрдә бу традиция инде югалып бара. Чигелгән үсемлек-чәчәк бизәге саклагыч-бөти вазифасын үтәми, әмма милли бердәйлек билгесе итеп карала. Алъяпкычларга бизәк төшерүдә бик күп көч куюны таләп итә торган келәм техникасы һәм нәфис тамбурлы чигү сирәк кулланыла. Нигездә тапкырлап һәм шома чигүләр киң таралган. Республикада һәм аннан читтә татарлар күпләп яшәгән территорияләрдә хатын-кызларның милли бәйрәм костюмнарында алъяпкычларны Самара өлкәсе татарларында, Оренбург мишәрләрендә, Чиләбе өлкәсендә яшәүче Урал буе татарларында һәм нагайбәкләрдә, шулай ук Татарстан керәшеннәрендә очратырга мөмкин. Һәр төркемдә алъяпкычларның декоратив эшләнеше локаль стиль үзенчәлекләре белән аерылып тора.

Хәзерге вакытта алъяпкычларның сәхнә вариантлары (үзешчән һәм профессиональ) барлыкка килде. Алар үтә гади, локаль билгеләргә ия түгел һәм авыл татар хатын-кызларының үзенчәлекле тышкы кыяфәтен боза гына.

**Әдәбият**

*Донина Л.Н., Рамазанова Д.Б.* Словник названий элементов татарского костюма: учебное пособие. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 2007. 119 с.

*Султанова Р.Р.* Осталар ягы // Милли-мәдәни мирасыбыз: Актаныш. Казань, 2010. 415 б.

*Суслова С.В., Мухамедова Р.Г.* Народный костюм татар Поволжья и Урала (середина XIX – начала XX века). Историко-этнографический атлас татарского народа. Казань: Фэн, 2000. 312 с.

*Шкляева Л.М.* Искусство кряшен. Каталог выставки «Искусство кряшен» в рамках проекта «Искусство народов Татарстана», июль-август 2013. Казань: Заман, 2013. 80 с.: ил.

*Шкляева Л.М.* Особенности народного декоративно-прикладного искусства татар Самарской области // Из сокровищницы научных экспедиций.

Национально-культурное наследие. Татары Самарской области. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 2015. С. 178–204.

*Шкляева Л.М.* Декоративно-прикладное искусство, промыслы и ремесла татар Оренбургской области // Из сокровищницы научных экспедиций. Национально-культурное наследие. Татары Оренбургской области. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 2015. С. 263–284.

*Ялчин Р.Ф.* Сарманай – 270 лет. Шарлык: Димург, 2014. 140 с.

***Шкляева Людмила Михайловна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145

*О.Р. Хисамов*

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНЕҢ Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫНДА ТЕЛ БЕЛЕМЕ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ТИКШЕРЕНҮЛӘР ТУРЫНДА

Статья посвящается многолетней деятельности Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан в области татарского языкознания. Особое внимание уделяется освещению истории наиболее крупных научных исследований и проектов. Раскрывается огромный вклад ученых-языковедов, определяющих лицо института.

**Ключевые слова:** языкознание, диалектология, лексикология, лингвистика, лексикография, фундаментальный научный труд.

The article is devoted to the long-term activity of the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan in the field of Tatar linguistics. Particular attention is paid to covering the history of the largest research projects. The huge contribution of linguistic scholars who determine the face of the institute is revealed.

**Keywords:** linguistics, dialectology, lexicology, linguistics, lexicography, fundamental scientific work.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты ачылган көннәреннән башлап (1939) лингвистика өлкәсендә фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләр алып бара.

Тел белеме бүлеге институт эшли башлауга ук барлыкка килә. Яңа оешкан бүлеккә мөдир итеп Л. Җәләй билгеләнә. Галим диалектологик экспедицияләр оештыра, җыелган материалны эшкәртүгә һәм җыентыклар, сүзлекләр бастырып чыгаруга күп көч куя. Узган гасырның 50 нче елларыннан татар сөйләшләрен һәм аларга хас төп үзенчәлекләрне ачыклау җәһәтеннән зур эш башкарылуга бәйле рәвештә, татар диалектологлары, төрки халыклар арасында беренчеләрдән булып, «Татар теленең диалектологик атласы» өчен материал туплау эшенә тотыналар.

1950–1960 еллар – татар диалектологиясе фәне үсешендә аеруча нәтиҗәле чор: материал җыю өчен программа төзелә, аспирантура тәмамлап яки үз хезмәтләрен бәяләүгә биреп, яшь галимнәр (Л.Ш. Арсланов, Д.Б. Рамазанова, Ф.Й. Йосыпов, Ф.С. Баязитова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова) эшкә килә, йөзләгән экспедицияләр оештырыла, гаять зур фактик материал җыела, монографияләр, фәнни җыентыклар, шул исәптән «Татар диалектологиясе буенча материаллар», «Татар теленең тарихи диалектологиясе буенча тикшере-

нүләр» серияләре дөнья күрә, зур диалектологик сүзлекнең ике китабы нәшер ителә. 2009 елда алар «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»нә әверелә.

1989 елда «Урта Идел һәм Урал буе татар халык сөйләшләре атласы» һәм «Атласка комментарийлар» басылып чыга. 2008 елда Себер һәм Әстерхан өлкәләре территорияләре буенча да эш төгәлләнә. 2015 елда Атласның яңартылган, тулыландырылган басмасы дөнья күрде, шулай ук аның электрон версиясе дә эшләнде.

Стилистик һәм текстологик аспектларда тел тарихы белән И. Абдуллин, Г. Әмиров, Х. Курбатов, И. Бәширова, М. Мөхәммәдиев, Я. Әхмәтгалиева, Ф. Фәсиев уңышлы шөгыльләнә. Ф. Фәсиевнең текстологик редакциясендә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» китабы нәшер ителә. 1992–2002 елларда Х. Курбатов җитәкчелегендәге авторлар төркеме тарафыннан «Татар әдәби теле тарихы (XIII–XX йөзләр)» дигән китап әзерләнә һәм дөнья күрә.

1980 елларда М.З. Зәкиев җитәкчелегендә башлангыч алган татар теленең академик грамматикасын төзү һәм бастыру эше дә зур казанышлардан санала. Авторлар тарафыннан татар грамматикасының барлык бүлекләрен тикшерү, булган әдәбиятны анализлау буенча зур эш башкарыла. Иң мөһиме: гомумиләштерү һәм нәтиҗәләр чыгару белән генә чикләнеп калмыйча, татар грамматикасы һәм фонетикасының күп кенә төп мәсьәләләре буенча зур тикшеренү эше гамәлгә ашырыла. Фәнни хезмәттә татар әдәби теленең хәзерге торышы өчен кайсы авазларның нинди позицияләрдә, кайсы күрсәткечләрнең һәм синтаксик конструкцияләрнең – норматив, ә ниндиләренең – вариатив (ягъни телнең төрле стильләрендә кулланылган вариантлар) булуы турында мәгълүматлар урын ала. Грамматика авторлары – М. Зәкиев, Д. Тумашева, Ф. Ганиев, К. Зиннәтуллина – 1994 елда Татарстанның фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясенә лаек дип табыла. 2015–2017 елларда әлеге фәнни хезмәтнең тулыландырылган, яңартылган версиясе эшләнеп, киң җәмәгатьчелеккә җиткерелде.

Институтның тел бүлеге, беренче көннәреннән үк, лексикографлар төркемен дә үз эченә ала. Сүзлекләр төзү эше танылган тел белгече Риза Газизов җитәкчелегендә тормышка ашырыла башлый. Татарча-русча һәм терминологик сүзлекләр эшләүдә катнашу өчен, штаттан тыш хезмәткәрләр сыйфатында, Нәкый Исәнбәт, Гаяз Ишмөхәммәтов, Касыйм Хәмзин, Хәмит Мөштәри, Габбас Сәйфуллин һ. б. кебек күренекле галимнәр һәм белгечләр чакырыла. Алар – 1940 еллар ахыры – 1950 еллар башында чыккан сүзлекләрнең төп авторлары. Күмәк тырышлыкның нәтиҗәсе буларак, «Татарча-русча сүзлек» (1950) һәм 4 томнан торган һәм 20 меңгә якын сүзне үз эченә алган «Русча-татарча сүзлек» (1955–1959) басылып чыга. 1958 елда төркем лексикография секторы дип үзгәртелә. «Зур татарча-русча сүзлек» һәм 3 томлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н төзү буенча зур эш башкарыла. «Татарча-русча сүзлек» 1966 елда Мәскәүдә нәшер ителә. Әлеге сүзлек 38000 сүз һәм гыйбарәне үз эченә ала.

Ул бүген дә, нигез белешмәлек буларак, киң катлау файдаланучылар арасында актив кулланылышта.

1977–1981 елларда «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» өчтомлыгы басылып чыкты. Татар лексикографиясендә генә түгел, ә бөтен тюркологиядә төрки телләрдәге аңлатма сүзлекләр арасында әлеге басма – иң уңышлыларыннан берсе.

Әлеге фәнни хезмәтләрдә тыш, татар тел белеменең бүгенге тикшеренүләре һәм уңышларының нигезен тәшкил иткән йөзләгән мәкаләләрне һәм дистәләгән монографияләрне атарга мөмкин.

Бүгенге көндә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында тел белеме өлкәсендә өч бүлек эшли: лексикология һәм диалектология, гомуми лингвистика һәм лексикография бүлекләре. Әлеге бүлекләрнең эшчәнлеге татар әдәби теленең, татар сөйләшләре һәм диалектларының теориясен һәм тарихын, структурасын һәм яшәү закончалыкларын, хәзерге торышын өйрәнүгә, шулай ук төрле гамәли проектларны тормышка ашыруга юнәлтелгән.

Фундаменталь тикшеренүләрнең нәтиҗәләре академик хезмәтләр булып формалаша һәм татар теленең тарихы, хәзерге торышы, үсеш перспективалары турында фәнни фикер булдыра, мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен дәреслекләр язуга объектив база булып хезмәт итә.

Бүгенге көндә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында тел белеме юнәлешендә гамәлгә ашырыла торган юнәлешләрнең берсе – «Хәзерге татар теле: функциональ һәм структур стратификация мәсьәләләре», ул татар лингвистикасы үсеше проблемаларын системалы һәм комплекслы өйрәнүне күздә тота. Әлеге юнәлештәге фәнни эшчәнлек нәтиҗәләре 2015–2017 елларда, фәннең бу өлкәдәге соңгы казанышларын исәпкә алып, яңадан нәшер ителгән «Татар грамматикасы» (татар телендә) дип аталган фундаменталь хезмәттә һәм аерым монографияләрдә урын алды.

«Татар теленең лексикасы һәм фразеологиясе: хәзерге заман лингвистика парадигмаларында лексикографик аңлатма бирү» юнәлеше кысаларында берничә фәнни тема буенча эш бара. Татар телендә «Татар лексикологиясе» дигән өч томлык фундаменталь хезмәтнең дөнья күрүе – бу өлкәдәге тикшеренүләрнең иң әһәмиятлесе. Әлеге проектның төп бурычы – татар теленең лексикасын тарихи үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып өйрәнү, бердәм, бербөтен система буларак күз алдына китерү. Әлеге фәнни хезмәтне басмага әзерләү барышында мәсьәләгә комплекслы якын килү сүзлек составының семантик һәм функциональ потенциалын диахрон-синхроник планда ачарга һәм күзалларга, тулаем лексик системаның үзгәрүенә йогынты ясаган лингвистик һәм экстралингвистик факторларны ачыкларга ярдәм итте. Сүз һәм гыйбарәләрнең генезисын һәм үсеш юлларын билгеләү, милли мәдәният контекстында аларга лексикографик тасвирлама бирү дә әһәмиятле бурычларның берсе булды.

«Татар лексикологиясе» – татар тел гыйлеменең әлеге өлкәсендәге беренче фундаменталь хезмәт. Ул төрле фәнни мәктәп

вәкилләренең фәнни эзләнү нәтиҗәләрен үз эченә алды, һәм татар лексикологиясенең күп кенә аспектлары беренче мәртәбә фәнни яктан тикшерелде. Ул – тюркологиядә әлеге ракурста эшләнгән тәүге хезмәт.

Шушы ук юнәлеш кысаларында татар антропонимнарын өйрәнү һәм Татарстан Республикасы топонимнарын электрон картага төшерү буенча да эш алып барыла. Татарстан Республикасы топонимнарының электрон каталогы (http://toponym.antat.ru/ru) топонимиканың барлык аспектларын һәм юнәлешләрен чагылдырган комплекслы сүзлек рәвешендә эшләнә. Ул аңлатмалы-энциклопедик, тарихи-этимологик һәм норматив-белешмәлек сүзлекләр принципларын үзендә туплаган. Каталогка Татарстан Республикасындагы барлык географик объектларның да атамалары – ойконимнар, гидронимнар, оронимнар һ. б. теркәлә. Анда атамаларның яңалары да, искеләре дә, шулай ук әлеге объект атамасының барлык, шул исәптән халык телендәге вариантлары да урын ала. Каталогка 7000 нән артык топонимны теркәү күздә тотыла. Бүгенге көндә 6000 нән артык топоним картотекага урнаштырылган.

«Татар телен һәм аның диалектларын чагыштырма-тарихи планда өйрәнү» юнәлеше кысаларында татар диалектлары һәм татар диалектлары теле тикшерелә. Соңгы елларда Институтта диалектология өлкәсендә филология фәннәре докторы, профессор Д.Б. Рамазанова, филология фәннәре докторы Ф.С. Баязитова кебек галимнәр әлеге юнәлештә зур эш башкардылар. Алар тарафыннан татар диалектологиясенең төрле аспектларына багышланган дистәләгән монографияләр нәшер ителде, йөздән артык мәкалә дөнья күрде.

Бүгенге көндә бүлекнең яшь диалектологлары татар теле диалектларын өйрәнү юнәлешендә ареаль тикшеренүләр алып баралар. Татар диалектларында исем сүз төркемнәре һәм урта диалектның фонетик үзенчәлекләре нәкъ менә ареаль аспектта өйрәнелә. Тикшерү өчен материал, нигездә, институт тарафыннан оештырылган комплекслы экспедицияләр барышында туплана. Тел галимнәре дә аларда турыдан-туры катнаша.

«Татар әдәби теле тарихы» проекты – әлеге юнәлештәге фундаменталь хезмәтләрнең берсе. Әлеге проект иске татар телен XIII – XX гасыр башына караган язма истәлекләр нигезендә комплекслы һәм системалы тикшерүне күздә тота. Төп максат – иске татар язма әдәби теленең формалашу һәм үсү закончалыкларын, традицияләрен, нормаларын билгеләү һәм тасвирлау. Тикшеренүләрнең нәтиҗәләре «Татар әдәби теле тарихы» дип аталган өч томлык коллектив монографиядә чагылыш табачак. Хезмәтнең беренче ике томы 2017–2018 елларда дөнья күрде. Беренче томда иске татар язма текстларының график, орфографик үзенчәлекләре тикшерелә. Икенче томда иске татар язма текстларының морфологик үзенчәлекләре өйрәнелә. Өченче томда әдәби телнең лексикасы һәм лексик-семантик категорияләре анализланачак.

Бүгенге көндә Институтта алты томлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н (күләме 450–500 а. т., чама белән 100 мең берәмлек сүз) төзү буенча эш бара. Бу фундаменталь хезмәт башка белешмәлекләрдән күләме, сүзләр саны, бай эчтәлеге, сүзлек материалының структур оештырылышы белән дә аерылып тора. Сүзлекнең уникальлеге аның, моңа кадәр эшләнгән сүзлекләр белән чагыштырганда, күбрәк сүз берәмлеген үз эченә алуыннан бигрәк, элек басылган аңлатмалы сүзлекләрдән концептуаль аермасында. Сүзлектә төрки телләр өчен характерлы һәм сүз ясалышы дәрәҗәсендә ачык күренгән аналитизм күренеше максималь рәвештә тулы һәм системалы чагылыш тапты. Татар телендә тезмә фигыльләрнең саны берничә йөз меңнәр белән исәпләнергә мөмкин. Шуның белән бергә телдә тезмә исемнәр, формаль-семантик күрсәткечләре белән мөстәкыйль лексик берәмлекләр статусына дәгъва иткән, һәм, билгеле, вокабула сыйфатында лексикографик яктан беркетелергә тиешле исем конструкцияләре дә кулланыла. Соңгы еллардагы әлеге һәм башка тирәнтен фәнни тикшеренүләрне татар теленең аңлатмалы сүзлегендә фәнни беркетү һәм дөрес итеп чагылдыру – фундаменталь лексикографик хезмәтне төзүчеләр алдында торган иң әһәмиятле фәнни-гамәли бурычларның берсе. 2015–2018 елларда сүзлекнең беренче дүрт томы дөнья күрде. 2020 елга барлык алты томны да нәшер итү күздә тотыла.

2014 елдан башлап «2014–2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында татар теленең яңа сүзлекләрен әзерләү һәм бастырып чыгару буенча зур һәм максатчан эш башланды. Әлеге программа буенча Институт хезмәткәрләре тарафыннан төрле типтагы сүзлекләр эшләнде. Бүгенге көндә татар телендә дөрес язу һәм дөрес әйтелеш кагыйдәләрен беркетергә тиешле орфографик һәм орфоэпик сүзлекләр эшләүгә дә аерым игътибар бирелә. «Татар теленең орфоэпик сүзлеге»н, «Татар теленең орфографик сүзлеге»н төзү буенча эш бара.

Профессор Р.Г. Әхмәтьяновның фундаменталь характердагы ике томлык «Татар теленең этимологик сүзлеге» эшләнеп нәшер ителү – фән өлкәсендә һәм республиканың иҗтимагый тормышында, тулаем төрки-татар дөньясында күптән көтеп алынган игътибарга лаек зур вакыйга. Анда татар телендәге 10300 гә якын сүз теркәлеп, аларга аңлатмалар бирелгән, 200 дән артык тел һәм диалект материаллары чагылыш тапкан.

Бүгенге көндәге фән-техника казанышлары тел галимнәре алдына да аерым бурычлар куя. Лингвистикада да яңа технологияләрне куллануга, цифрлаштыруга ихтыяҗ зур. Шуңа бәйле рәвештә Институт галимнәре тарафыннан Сүзлекләрнең электрон фонды (http://suzlek.antat.ru/indexR.php) булдырылды. Эшнең максаты – татар теле сүзлекләренең күп функцияле электрон җыентыгын булдыру. Фондта төрле типтагы сүзлекләр урнаштырыла: аңлатмалы, ике-, күптелле,

гомуми һәм аерым, аспектлы һ. б. Фонд чыганаклары сүз турында төрле мәгълүматлар алырга мөмкинлек бирә: дөрес язылышы, басымы, грамматик үзенчәлекләре, мәгънәсе, синонимнары, килеп чыгышы, фразеологизмнар һәм әлеге сүз кергән состав берәмлекләр һ. б. Бүгенге көндә фонд интернет челтәрендә урнаштырылган һәм 25 сүзлекне үз эченә ала.

2016 елда ТӘһСИдә Милли мәгариф бүлеге оештырылды. Анда туган тел һәм әдәбият укыту проблемалары системалы һәм комплекслы төстә өйрәнелә. Бүгенге көндә бүлек хезмәткәрләре яңа буын туган (татар) теле дәреслекләре булдыру өстендә эшлиләр.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән (№ 676, 10.08.2012) Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты «Халык контроле» мәгълүмат системасында «Атамалардагы һәм язмалардагы хаталар» категориясендә модератор итеп билгеләнде. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 30 сентябрендә чыккан № 743 карары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, алар карамагындагы учреждениеләр, Татарстан Республикасындагы дәүләт унитар предприятиеләре, җирле үзидарә органнары, муниципаль берәмлек һәм оешмалар исемнәре язылган элмә такта текстларының орфография һәм пунктуация кагыйдәләренә туры килүен, рус һәм татар телләрендәге элмә такта текстларының тәңгәллеген тикшерү Институт тарафыннан гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы Мәдәнияты министрлыгы каршындагы мемориаль такталар буенча комиссия тарафыннан әзерләнгән текстлар да Институтта мәҗбүри экспертиза үтә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: хәзерге вакытта 80 еллык бай тарихы булган Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан тел гыйлеме өлкәсендәге тикшеренүләр традицияләргә таянган хәлдә, заман таләпләренә йөз тотып, эзлекле, системалы рәвештә алып барыла.

***Хисамов Олег Ришат улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фән эшләре буенча*
*директор урынбасары*

УДК 821.512.145

*З.З. Рәмиев*

# ИНСТИТУТ ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

В статье в историческом аспекте кратко анализируются литературоведческие исследования, проведенные сотрудниками ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова со дня его основания по сегодняшний день, в особенности, серьезные труды по истории и теории татарской литературы, имеющей многовековой путь развития, а также текстологические работы по творчеству татарских писателей-классиков.

**Ключевые слова:** история татарской литературы, текстология, монография, том, Габдулла Тукай, Галимджан Ибрагимов.

The article briefly analyzes in historical aspect literary studies conducted by employees of the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov from its founding to the present day, in particular, serious work on the history and theory of Tatar literature, which has a centuries-old development path, as well as textual works on the work of Tatar classic writers.

**Keywords:** history of Tatar literature, textology, monograph, volume, Gabdulla Tukai, Galimjan Ibragimov.

Татар әдәбиятының Кол Галиләрдән башланган озын тарихын һәм совет чорындагы үсеш-үзгәреше мәсьәләләрен төрле яклап өйрәнү бурычы йөкләнгән әдәбият секторы[1] Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советының 1939 ел 7 октябрь карары нигезендә Мәгариф халык комиссариаты оештырган Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институты (1941 – 1996 елларда Тел, әдәбият һәм тарих институты; 1967 елдан Г. Ибраһимов исемендәге) составында беренче көненнән үк, әмма авыр шартларда эшли башлый. 1920–1930 еллар – бу юнәлештә дә шактый хезмәт күрсәткән Галимҗан Ибраһимов, Галимҗан Нигъмәти, Гомәр Гали, Җамал Вәлиди, Газиз Гобәйдуллин (Г. Газиз), Гали Рәхимнәр репрессия корбаннары булган дәвер. Академик фән мәйданында тикшеренүләр алып барырдай хезмәткәрләр табу мөмкин дә түгел шикелле, әмма эшне дәвам итәргә кирәк. Секторны җитәкләүгә Казан педагогия институтын һәм анда ук аспирантура тәмамлаган, Казан педагогия училищесы директоры урынбасары Якуб Агишев (1899–1972) чакырыла, фәнни эшкә Вәли Хаҗиев, Габдулла Камскийлар тартыла (берсенең дә гыйльми дәрәҗәсе булмый). Бераздан аларга Бәкер Яфаров, Хәсән Хәйри, Гали Халит, Мөхәммәт Гали, Мөхәммәт Гайнуллин килеп кушыла. Мәгълүм ки, ул вакытларда байтак күренекле язучыларыбыз иҗаты катгый тыелу, шулай ук татар язуының ике мәртәбә

[1] Соңрак, төрле елларда « әдәбият лабораториясе», «әдәбият бүлеге» дип исемләнеп йөртелде. 1987 елдан – «әдәбият белеме бүлеге».

мәҗбүри рәвештә үзгәртелүе сәбәпле дә татар әдәбияты тарихында урын алган иҗатчыларның язма мирасын нечкәләп тикшерү шактый дәрәҗәдә чикләнгән була. Шунлыктан әүвәлге хезмәтләрдә төп игътибар Габдулла Тукайга, Мәҗит Гафуриларга гына бирелә. Аларны чын мәгънәсендә халык шагыйрьләре сыйфатында бәяләүгә басым ясала (Г. Халит, Я. Агишев хезмәтләре). 8 нче сыйныф өчен «Әдәбияттан дәреслек-хрестоматия» төзелә. Җөрьәт итеп, гаять мөһим текстологик эшкә – күптән көтелгән Габдулла Тукай әсәрләренең академик басмасын әзерләүгә керешәләр (өч том итеп планлаштырылса да, ике томлы булып басыла; 1930 ел башында мондый омтылыш тулысынча тормышка ашырыла алмаган иде). Озакламый секторда борынгы чор һәм Урта гасырлар, XIX йөз һәм XX гасыр башы татар әдәбияты тарихларын булдыру максатында план-проспект төзелә. Сектор хезмәткәрләре Г. Тукай, К. Насыйри, Г. Камал, М. Укмасый, М. Гафури, С. Рәмиев кебек күренекле иҗатчыларның шәхси архивларына караган материалларны Институтка алу эшенә дә игътибар бирәләр, Вәли Хаҗиев өлгерлеге белән Уфадан Мәҗит Гафуриның шактый бай архивы кайтарыла...

Билгеле ки, Бөек Ватан сугышы елларында әдәбият секторына да гыйльми эшчәнлеген алып бару кыенлаша. Шулай да секторда эшләүне дәвам иттерүчеләр планлаштырылган эшләрне үтәүгә җаваплы караганнар (Г. Камский сугышка алына һәм һәлак була). Мәсәлән, Я. Агишев һәм Х. Хисмәтулин берничә ел дәвамында алып барылган гыйльми эшне – Тукайның академик басмасының 1 нче томын төзүне тәмамлыйлар, һәм ул 1943 елда Татарстан китап нәшриятында нәшер ителә (2 нче томы буенча да эш барган, әмма 1948 елда гына басыла алган).

1946 елда Казанда СССР Фәннәр академиясенең филиалы ачыла, институт аның составында (һәм җитәкчелегендә дә) яши башлый. Сектор эшчәнлеге дә киңәя төшә, гыйльми эзләнүләргә Хәй Хисмәтуллин, Гази Кашшаф, Рөстәм Башкуровлар тартыла, аспирантура ачыла (1946–1958 елларда анда Б. Гыйззәтуллин, Н. Гыйззәтуллин, Р. Башкуров, Ш. Абилов укыган). Ул елларда гыйльми эзләнүләрнең тематикасы байый, татар әдәбияты тарихын язу, урта мәктәпләр, югары уку йортлары өчен дәреслекләр төзү, классиклар мирасын текстология җәһәтеннән өйрәнү кебек мәсьәләләр игътибар үзәгенә куела. 1954 елда ул вакытлар өчен аеруча мөһим хезмәт, сектор әдәбиятчыларының катлаулы чор мирасын анализларга омтылуларын чагылдырган – «XX йөз башы татар әдәбияты» (авторлары – Б. Гыйззәт, Г. Халит, Х. Хисмәтуллин) басыла. Билгеле, ул совет чоры идеологиясе басымы астында, сыйнфый күзлектән үткәреп язылган (бу вакытларда башкача мөмкин дә түгел иде), репрессияләнгән яисә буржуаз дип аталган язучыларның мирасы тикшерүдән читләштерелгән, яисә тискәре бәяләнгән. Мәсәлән, Г. Халит Сәгыйть Рәмиевне, Нәҗип Думавины «вакытлы рәвештә революционлык күрсәтеп тә, тора-бара демократиядән читләшкәннәр» дип бәяли [XX йөз башы..., б. 23]. Төп

тикшерү объектлары – Г. Тукай, Г. Камал, М. Гафури, Г. Коләхмәтов, Ш. Камал иҗатлары.

1946 елның июнендә Институт, Казан университеты һәм педагогия институты белән бергәләп, Тукайның тууына 60 ел тулуга багышланган гыйльми сессия үткәрә. Төп докладчылар – Институт хезмәткәрләре (Г. Халит, М. Гайнуллин, Х. Хисмәтуллин, Б. Яфаров, М. Гали). Сессиянең 1948 елда чыккан «материаллары»нда Тукай иҗатын тагын да тирәнрәк һәм төрле яклап анализларга омтылыш сизелә.

Бу елларда М. Гафуриның 4 томлы «Әсәрләр җыелмасы» төзелә башлый (ләкин 4 томы гына басыла; төзүчесе – Г. Халит), Г. Камалның ике томлы «Әсәрләр»е чыга (төзүчесе – М. Гали). Сектор эшчәнлегендә татар мәгариф системасы өчен аеруча кирәкле дәреслек-кулланмалар төзү эше дә зур урын алып торган: болар – «югары уку йортларының татар теле һәм әдәбияты бүлекләре өчен» М. Гайнуллин һәм Җ. Вәзиева төзегән «Татар әдәбияты; XIX йөз – 1917 елга кадәр» исемле дәреслек-кулланма (1947; 710 битле), Х. Хәйринең 9 нчы, М. Гайнуллин һәм Х. Ярминең 8 нче сыйныфлар өчен «Татар әдәбияты», Л. Җәләйнең 8 нче сыйныф өчен «Әдәбияттан хрестоматия» дәреслекләре. Х. Хәйринең Һади Такташ, М. Гайнуллинның Каюм Насыйри турындагы монографик хезмәтләрендә бу бөек шәхесләрнең тормышы һәм иҗат дөньяларын шактый җентекләп тикшерергә омтылыш ачык күренеп тора.

Мәгълүм ки, Сталин үлеменнән соң уздырылган КПССның XX съезды карарлары белән совет җәмгыятендә демократик үзгәрешләр барлыкка килде, аеруча мөһиме – Сталинның шәхес культы, күп еллар дәвамында алып барылган репрессив сәясәте фаш ителде, 1930–1940 елларда концентрацион лагерьларга озатылган, атылган татар язучы, мәдәният, сәнгать, җәмәгать эшлеклеләренең гаепләре булмавы хөкем органнары тарафыннан расланды. Ниһаять, Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Г. Гали, Г. Нигъмәти, Ф. Сәйфи-Казанлы, С. Сүнчәләй кебек татар иҗатчы шәхесләребезнең язма мирасын бернинди чикләүсез өйрәнү мөмкинлеге туды, беренче чиратта, әсәрләрен сайланмалар рәвешендә генә булса да укучылар кулына тапшыру кирәк иде. Әдәбиятчылар бу мөһим эшкә зур җаваплылык белән тотындылар. Азмы-күпме сакланып калган шәхси архивлар барланды, әдипләребез еш язышкан вакытлы матбугат органнары өйрәнелде (кызганычка каршы, XX гасыр башында чыгып килгән кайбер газеталарның барлык саннары да сакланмаган, мәсәлән, «Борһане тәрәккый»нең). Бу «җепшеклек» (тоталитар хакимият йомшару, сәяси һәм иҗтимагый тормыш беркадәр либеральләшү, сүз иреге бирелү, иҗади эшчәнлекне бик үк кысмау) чорында килеп туган фәнни-иҗади мөмкинлекләрдән файдаланып, М. Гайнуллин, Х. Хәйри, Г. Халит, Х. Хисмәтуллиннар, шулай ук яңарак кына фән дөньясына аяк баскан Н. Гыйззәтулин, Ш. Абилов, Р. Башкуровлар игътибары да әдәбиятыбызның төрле дәверләренә юнәлде. 1963 елда басылган «Борынгы

татар әдәбияты» исемле дәреслек-хрестоматиядә Кол Галидән Утыз Имәнигә кадәрге заманнарга нисбәтле татар әдәби мирасының иң мөһим өлешләре системага салынып, укучыларга тәкъдим ителде. Репрессиягә дучар булып өлгермичә, авырып үлеп киткән, шулай да, һичшиксез, XX гасыр башы татар әдәбияты классигы булып бәяләнергә лаеклы Фатих Әмирханның иҗат мирасы ике томда гына булса да басылып чыкты (кереш сүз авторы, 2 нче томны төзүче – Х. Хисмәтуллин). 1937 елда классиклыгы инкяр ителгән Г. Ибраһимов (төрмәдә үлә) әсәрләренең өчтомлыгына язылган кереш мәкаләсендә Г. Халит атаклы язучы, галим, җәмәгать эшлеклесенең XX гасыр татар әдәбияты тарихында беренче урын биләгәнлеге турында да фикер йөртә, шул ук вакытта Тукайны да «онытмый», ике дистә ел буе барган эзләнү-уйлануларын «Тукай үткән юл» монографиясе аша укучыга җиткерә (1962, 228 б.).

Нинди авыр шартларда да (репрессияләр, идеологик басым, сугышта югалтулар, цензура) татар әдәбиятының яшәүдән туктамавын, совет чорында да талантлы әсәрләр язылуын күрсәтү максатында әдәбиятчы галимнәр коллектив хезмәтләр тудыру фикеренә дә килделәр. Болар – «Татар совет әдәбияты тарихы» (1960, 822 б.) һәм «История татарской советской литературы» (Мәскәү: Наука, 1965, 578 с.); татар һәм рус телләрендә басылды. Бу зур күләмле монографияләрдә әдәби күренешләргә сыйнфый күзлектән карау дәвам итсә дә, авторлар әсәрләрнең сәнгати яңгырашларын, язучы-шагыйрьләрнең иҗатында урын алган индивидуаль хосусиятләрне тикшерергә дә омтылалар, социалистик реализм иҗат методы белән тудырылырга тиешле татар әдәбиятында реализмның, халыкчанлыкның, жанрларның үсештә булуын күрәләр. Р. Башкуровның «Тукай һәм рус әдәбияты» (1958), Х. Мөхәммәтовнең «Татар әдәбиятында мәгърифәтчелек идеяләре» (1951) монографияләрендә исемнәренә үк чыгарылган, моңа кадәр аз тикшерелгән катлаулы мәсьәләләр үзәккә куеп тикшерелә.

1960 еллар ахырында – 1970 еллар башында институтның әдәбиятчылары сафына Ә. Әхмәдуллин, Ф. Мусин, Р. Сверигин, Ф. Ибраһимова, М. Гайнетдинов, Н. Хисамов һ. б. килеп кушылу, М. Гайнуллин (1958 елдан фәннәр докторы), Х. Хәйри, Г. Халит (1968 елдан фәннәр докторы) кебек өлкәнрәкләрнең татар әдәбият белеменең катлаулы проблемаларын хәл итәргә өлгереп җитүләре тикшеренүләрне киңрәк планда алып барырга мөмкинлек бирә. Аеруча М. Гайнуллин нәтиҗәле эшли: 1966 елда «Татарская литература и публицистика начала XX века» (435 б.), 1968 елда «Татар әдәбияты: XIX йөз» (670 б.) исемле бай фактик материалга нигезләнеп язылган күләмле монографияләрен дөньяга чыгара. Аларда хәзерге татар әдәбиятының башлангыч дәверендә иҗат иткән әдипләрнең язма мирасы шактый җентекле интерпретацияләнгән, бүгенге тикшеренүчеләр хәзер дә аларга таянып эш итәләр. Ф. Ибраһимова татар балалар прозасы буенча кандидатлык диссертациясе яклый, китап бастыра, Ф. Мусин исә XX гасыр уртасы татар прозасын заман һәм тарих белән бәйләнештә тикшерә.

Әмма шул ук вакытларда институт галимнәре алдына эре темаларга коллектив хезмәтләр тудыру бурычы да куела. Әдәбиятчылар алдына меңьеллык татар әдәбиятының тарихын күптомлы итеп язу проблемасы килеп баса. Секторны 1966 елдан Хәсән Хәйри җитәкләгән (1973 елдан Нил Юзиев; 1974 елдан – фәннәр докторы) вакытларда ук моңа әзерлек эшләре алып барылуын әйтергә кирәк. Мәсәлән, яшьрәк хезмәткәрләр XX гасыр башы татар вакытлы матбугатын (мөһимрәк газета һәм журналларны) карап чыгып, анда күренгән әдәби текстларга, әдәби-тәнкыйди материалларга аннотацияләр төзи. Бераздан әлеге зур эшнең, тарихның биш томлы (соңрак алты томлы) планпроспектын булдыру кирәк дип табыла. Ул, секторның берничә әдәбиятчысы катнашында төзелеп, кульязма хокукында күбәйтелә һәм гыйльми җәмәгатьчелек хозурына тәкъдим ителә. Басманың баш редакцион коллегиясе (баш редактор Н. Юзиев) генә түгел, һәр томның да редколлегиясе төзелә. Бүлекнең бөтен әдәбиятчыларыннан тыш, тарихның кайбер өлешләрен, бүлекләрен язуга башка сектор (соңрак бүлек), читтәге фәнни учреждениеләр һәм югары уку йортлары галимнәрен дә тарту мәсьәләсе килеп туа (Петербургтан Г. Таһирҗанов, Уфадан Г. Хөсәенов һ. б.). Билгеле ки, бу басма буш урында пәйда булмады, Г. Халит, М. Гайнуллин, Н. Юзиев, Ш. Абилов, Н. Хисамов, М. Гайнетдинов һ. б. лар бай тарихлы әдәбиятыбызның төрле чорларына, жанрларына, күренекле әдипләргә нисбәтле эзләнүләрен бастыралар. Әмма татар әдәбият белеменең үсеш логикасы нәкъ менә күптомлы, концептуаль, фундаменталь хезмәт булдыруны таләп итә. 1 нче томга урнаштырылган «Татар әдәбияты тарихының алтытомлыгы» дип исемләнгән керештә Н. Юзиев шактый бәхәсле, әдәби барышны чорларга бүлеп өйрәнү мәсьәләсенә тукталып, «Татар әдәбиятының үзенчәлеген төгәлрәк, тулырак ачу максатыннан аны тарихи-деологик һәм әдәби-эстетик үзенчәлекләре белән аерылып торган кечерәк дәверләргә, гасырларга, чорларга бүлеп карау отышлы» дип санады. 1 нче том «Урта гасырлар дәвере», 2 нче том «XIX йөз татар әдәбияты», 3 нче том «XX гасыр башы», 4 нче том«Татар совет әдәбияты (1917–1941)», 5 нче том «Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты (1941–1960)» дип исемләнеп, 1984–1989 елларда Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты, рецензияләрдә, презентация вакытларында әдәбиятчыларның зур уңышы итеп бәяләнде. Билгеле ки, аларны әзерләү вакыты СССРның таркалуга бару, социалистик идеологиянең басымы сизелерлек йомшару, абруе кими төшү елларына туры килде, һәм авторлар, томнарның җаваплы, фәнни редакторлары (Ш. Абилов, М. Гайнуллин белән Н. Ханзафаров, Г. Халит, Н. Юзиев, Н. Хисамов, Н. Гыйззәтуллин, Ф. Мусин) электән килгән, инде ныклап урнашкан фикерләргә төзәтмәләр кертергә омтылдылар. Мәсәлән, XX гасырның унынчы еллары поэзиясендә, аеруча яшь каләм әһелләре шигъриятендә, романтизмның «иҗат юнәлешен билгеләгән төп эстетик факторларның берсенә әверелүе»н дәлилләү...

Югарыда институт хезмәткәрләренең татар әдәби мирасын барлау һәм укучыларга кайтару юнәлешендәге эшчәнлеге (институт төзелгәч тә вакыт-вакыт башкарыла киленгән чаралар) турында инде сүз булган иде. 1970 елларга аяк баскач, бу аерата да мөһим эшне – текстологик тикшеренүләрне яңа баскычка күтәрү зарурияте туды. Бигрәк тә әдәбиятыбызның алтын дәвере (XX гасыр башы) классиклары иҗатының тулырак басмаларын төзү һәм юбилейларына өлгертү мәсьәләсе бик тә актуаль төс алды. Институт дирекциясе, бу хәлдән чыгу юлын махсус фәнни төркем төзүдә күреп, 1976 елның маенда аны булдыру турында карар чыгарды. 1977 ел башыннан З. Рәмиев, М. Әхмәтҗанов, Р. Гайнанов, Л. Гайнанова, Н. Садыйкова һәм Ф. Ибраһимова составында эшли башлаган текстология төркеменең фәнни-тикшеренү планнарына 1980 елларда олы юбилейлары да көтелә торган бөек әдипләребез – Г. Тукай, М. Гафури, Һ. Такташ, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Камал, М. Җәлилләрнең күптомлы басмаларын төзү эше кертелде. Гәрчә бу эш совет цензурасы күзәтчелеге астында алып барылса да, текстолог-әдәбиятчылар теге яки бу әдипнең мирасын мөмкин кадәр тулырак чагылдырырга, текстларны авторлары ихтыярына туры китереп, комментарийларны да тулырак бирергә омтылдылар. Шулай да ул чорда әле текстларны бернинди кыскартуларсыз урнаштыру мөмкин булмады, кайберләре нәшрияткa тапшырылгач алып ташланды (мәсәлән, М. Гафуриның 1917 елгы «Татар байрагы» шигыре). Г. Ибраһимов томнарында текстлар 200 ләп урында кыскартылып бирелде.

Институт галимнәре татар әдәбиятының башка чорларында иҗат ителгән әсәрләрне өйрәнүне дә дәвам иттеләр. Ниһаять, 1983 елда Кол Галинең атаклы «Кыйссаи Йосыф» поэмасының күптән көтелгән фәнни (академик дияргә дә ярый) басмасы дөнья күрде. Аның текстын әзерләүче, кереш мәкаләне (40 битле), искәрмә һәм аңлатмаларны, кулъязмаларының тасвирламасын язучы – Фазыл Фәсиев (махсус редакторы – М. Госманов). Әлеге басма чыгу институтта, гуманист шагыйрьнең тууына 750 ел тулу юбилеена багышлап, фәнни-гамәли конференция дә уздыру мөмкинлеген бирде (материаллары басылды: Казан, 1987).

1990 еллар азагында илебез тормышын тамырдан үзгәртеп кору чоры башлану, Татарстан АССРның суверенитеты да игълан ителү гуманитар фәннәр, аерым алганда, әдәбият белеменең яшәешенә яңа сулыш өрде. Бу социалистик догмалардан арына башлау, репрессиягә дучар булганнарның (мәсәлән, солтангалиевчеләрнең) тулысынча аклануы, 1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң мөһаҗирәттә яшәргә мәҗбүр булганнарның (бигрәк тә, Гаяз Исхакыйның) иҗатыннан табу алыну аркасында мөмкин булды. Яңа сәяси-иҗтимагый шартларда институт әдәбиятчылары мөһимлеге күзгә аеруча бәрелеп («кычкырып») торган дүрт темага мөрәҗәгать иттеләр.

Боларның беренчесе – классик язучы, публицист, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе Гаяз Исхакыйны «кайтару». Татар әдәбиятчылары

бу эшкә зур теләк һәм җаваплылык хисе белән алынды. Заманында әдип язышкан газета һәм журналларга юл ачылды (шул исәптән, 1928–1939 елларда чыгарылган «Яңа милли юл» журналына да), көтепханәләрнең ачык киштәләренә китаплары кереп урнашты, Төркиядә сакланып калган шәхси архивы материаллары (башта күчермәләре, соңрак оригиналлары да) институтка кайтарылды (2018 елда Әнкарадагы «Аяз Таһир (Төркестан – Идел-Урал) фонды рәисе Түләй Дуран ханым, шәхсән Казанга үзе килеп, аларны әлеге институтка тапшырды). 1995 елларда әдипнең 15 томлы «Әсәрләр»ен төзүне институтның фәнни-тикшеренү планнарына кертүгә ирешкәч, әдәбиятчы-текстологлар төркеме бөтенесе дә диярлек шул эшкә тартылды. Тормышы һәм иҗатының фәнни библиографиясе булмау Исхакый каләменнән чыккан текстларны табу һәм кулга төшерүне гаять кыенлаштырды, билгеле. Автографларын (кульязмаларын) уку да җиңел түгел иде, текстларда комментарийлар сорап торган урыннар да бихисап. Алай да текстологлар 15 томлыкны 2014 елга төзеп бетерә алдылар. Бу гаять четерекле һәм күләмле эшне Лена Гайнанова (1–5 нче томнар), Зөфәр Мөхәммәтшин (11–13 нче т.), Фатыйма Ибраһимова (8 нче т.), Фәния Фәйзуллина (14 нче т.), Гөлназ Хөснетдинова, Эльмира Галимҗанова, Гөлчирә Ханнанова, Рәшит Кадыйровлар (6, 7, 9, 10, 15 нче т.) составындагы әдәбиятчы-текстологлар төркеме башкарды. Г. Исхакый әсәрләренең 15 томлыгы – Г. Ибраһимов исем. институт эшчәнлеге тарихында, гомумән, татар әдәбияты текстологиясендә әлегә тиңе булмаган басма. Болардан Л. Гайнановага, Ф. Ибраһимовага (вафатыннан соң), З. Мөхәммәтшинга һәм бу юлларның авторы З. Рәмиевкә (ул кайбер томнарны төзешүче, 6–15 нче томнарның фәнни редакторы) 2016 елда Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге казанышлары өчен Дәүләт бүләге тапшырылды.

Икенче тема да әдәбият текстологиясе өлкәсенә карый. Бөек шагыйребез Габдулла Тукай әсәрләре, текстологик эш тә башкарылып, вафатыннан соң 2, 3, 4, 5 томлыклар рәвешендә биш мәртәбә басылган иде. Алар басмадан-басмага камилләшә, тулылана төшеп нәшер ителсәләр дә, «монда бөтен Тукай» исемен күтәрә алмадылар. Вафаты якынайган көннәрдә бөек шагыйрьнең васыяте сыйфатында әйтелгән «Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле» дигән сүзләре һаман да реаль эчтәлек алмый торды. Яңа вазгыятьтә шагыйрьнең барлык билгеле әсәрләре белән халыкның таныша алу мөмкинлеге булмау әдәбиятчыларны борчый иде. Шунлыктан, аз санлы текстология бүлегенең[1] фәнни тикшеренү планына, ниһаять, Тукайның академик типтагы басмасын әзерләүне кертү (Г. Исхакый томнарын төзү белән параллель диярлек) бүлек эшчәнлеген шактый катлауландырды.

[1] 1987 елда текстология бүлегеннән аерылып чыгып, 2007 елга кадәр кульязмалар һәм текстология бүлеге составында эш алып барды.

Әмма инде аны әзерләүне тагын да чигерү мөмкин түгел. Һәм текстологларга 2011 елга шагыйрьнең 125 еллыгына алты томлы итеп фараз ителгән басманың беренче ике томын төзеп бетерү һәм бастырып чыгару бурычы йөкләнде. Башка дүрт томы исә 130 еллыгына өлгертелер дип уйланылган иде. Үтә дә җаваплы эшкә алынган тәҗрибәле әдәбиятчы-текстологлар – Р. Кадыйров, З. Мөхәммәтшин 1 нче томны, З. Шәйхисламов, Г. Хөснетдинова, Э. Галимҗанова һәм З. Рәмиев – 2 нче, З. Шәйхисламов 3, З. Мөхәммәтшин – 4 нче, Г. Хөснетдинова һәм Г. Ханнанова – 5 нче, Э. Галимҗанова һәм Ф. Фәйзуллина – 6 нчы томнарны төзегәндә, Тукайның берничә дистә текстын таптылар, аларны чын мәгънәсендә академик фән таләпләренә туры китереп, тәфсилле шәрехләмәләр яздылар, текстларны элекке басмаларындагы хаталардан арындырдылар. Бу алты томлы академик басма Тукай каләменнән чыккан барлык текстларны да эченә ала дип әйтергә була. Әмма шунысы бар: Тукай язышкан кайбер чыганаклар (газета һәм журналларның аерым саннары), кызганычка каршы, табылмады.

Институтта татар әдәбияты тарихын, нәзари проблемаларын хәзерге заман фәнни методологиясе кулланып тикшерергә омтылган әдәбият белеме бүлеге хезмәткәрләре, яңа гасыр башланып киткәч тә, тагын бер фундаменталь эшне үтәргә керештеләр; ул – сигез томлы «Татар әдәбияты тарихы» (*моннан ары: сигезтомлык*). Бер караганда, алты томлы басманың язылып тәмамлануына нибары ун-унбиш ел гына узган (6 нчы томы, соңарып – 2001 елда гына чыга), шунлыктан әллә ни «искереп» өлгермәскә тиешле иде. Тик бернәрсә бар; ул совет чорында язылды. Авторлары аларда татар халкының гаять үзенчәлекле әдәби иҗатының үзенә генә хас хосусиятләрен чагылдырырга омтылган булсалар да, алтытомлык ул чорның идеологик өйрәтмәләреннән азат түгел иде. Шунысы да искә алынырга тиешле булды: әдәби мирасның моңа кадәр хәтта билгеле булмаган катламнары да өйрәнүне «сорый» иде.

Сигезтомлыкның төзүчесе һәм җаваплы мөхәррире Равил Рахмани 1 нче томга урнаштырган кереш мәкаләсендә («Татар әдәбияты тарихының сигезтомлыгына гомуми күзәтү») бу фундаменталь характердагы хезмәтнең яңартылган методологик прициплар кулланып язылачагына басым ясый. Бүгенге көнгә чыккан алты томында аларның чагылу дәрәҗәсен күзәтүгә керешмәстән, бары тик хезмәтнең гаять бай материалга нигезләнеп язылуын, шаблон фикерләүләрдән качып, күптәннән мәгълүм әдәби әсәрләрнең дә серле якларын ачарга омтылуны, аерым төшенчә-атамаларның төзәтмәләр кертелеп файдаланылуын (мәсәлән, «татар», «әдәбият», «миллилек») әйтергә тиеш табам. Р. Рахмани алтытомлыкның нигезендә яткан, баш редакторы Нил Юзиев тәкъдим иткән периодизациягә дә үзгәреш кертә. Күрәбез: 1 нче томда (фәнни редакторы М. Бакиров) татар әдәбиятының борынгы чордан XV гасырга кадәрге үсеш тарихы анализлана; 2 нче томда – XV–XVIII гасырлар (фәнни редакторы Х. Миңнегулов);

3 нче томда – XIX йөз (фәнни редакторы Ф. Галимуллин); 4 нче томда (фәнни редакторы Р. Ганиева) – XX йөз башы; 5 нче томда (фәнни редакторы Д. Заһидуллина) – 1917–1956 еллар; 6 нчы томда (фәнни редакторлары: Д. Заһидуллина, Ә. Закирҗанов) – 1960–1980 еллар әдәбияты тикшерелә[1]. Билгеле ки, сигезтомлыкның авторлары сыйфатында Ә. Закирҗанов җитәкчелегендәге Әдәбият бүлегенең барлык хезмәткәрләре катнаша. Бу эшкә шулай ук институтның башка бүлекләрендә, Казан федераль университетында эшләүче тәҗрибәле галимнәр дә җәлеп ителә.

Соңгы елларда институт галимнәре татар әдәби мирасын текстология (текстология төркеме 2007 елдан аерым бүлек рәвешендә яши) җәһәтеннән тикшерүгә зур әһәмият бирделәр. Классиклар иҗатына игътибар һич тә кимемәгән хәлдә, борынгырак чорларда иҗат ителгән әсәрләрне дә, аерым әдипләр, зыялы шәхесләр язма мирасын да җентекле өйрәнү, аларның әдәби-сәнгати дәрәҗәсен билгеләү, текстларын бүгенге татар язуында булдыру мәсьәләсе дә актуальлеген югалтмый. Н. Исмәгыйлев Җәмалетдин Бикташиның «Фәзаилеш-шөһүр» исемле әсәрен, Ә. Алиева «Нәсихәтес-салихин», «Мең дә бер кичә»не (2 нче том), М. Әхмәтҗанов «Каһарман катыйль»не, Э. Ханнанова С. Миңлекәй шигырьләрен хәзерге татар язуында әзерләп бастырдылар. М. Әхмәтҗановның татар археографиясенә караган эзләнүләрен эченә алган китаплары әледән-әле басылып тора. Р. Исламов Мәмлүкләр чоры язма мирасын, Шәрифнең «Шаһнамә»сен тикшерде, Н. Хисамов Кол Галинең атаклы «Кыйссаи Йосыф» поэмасын өйрәнүне дәвам иттерде.

Хәзерге вакытта әдәбиятчы-текстологларның төп игътибары Галимҗан Ибраһимов иҗатына юнәлтелгән. 1937 елда авыру хәлендә хаксызга кулга алынып, төрмә шифаханәсендә вафат булган бу татар әдәбияты классигы, 1950 еллар ахырында аклангач та, өч томлы «Сайланма әсәрләре», бераздан сигез томлы «Әсәрләр»е инде басылган иде. Әмма аларда язучы мирасын тулысы белән урнаштыру мөмкин булмады. Исемен дә йөрткән институт тикшеренүләрендә аның турында яңадан-яңа мәгълүматлар табылу, үткәндәге язма байлыкны өйрәнүдә совет чорында яшәп килгән киртәләр алып ташлану Г. Ибраһимовның барлык әсәрләрен халыкка кайтару эшенә тотынуны тизләтте. Һәм яңа басма булдыру мәсьәләсе, аны академик басма рәвешендә төзү зарурияте туды. Әүвәле 15 томлы булачак басманың план-проспекты төзелеп, ул институтның йомгаклау конференциясендә тикшерүгә куелды. Редколлегиясен институт директоры Ким Миңнуллин үзе җитәкләгән унбиштомлыкның биш томы басылып чыкты. Аларда әдипнең роман, повесть һәм хикәяләре китерелгән. Атап әйткәндә: 1 нче томны (1917 елга кадәрге хикәяләре һәм «Казакъ кызы» романы) Г. Зәйниева, 2 нче томны (повестьлар, роман) Ә. Алиева, 3 нче томны (хикәя, повестьлар, роман һәм драма) Г. Зәйниева

[1] 7 нче һәм 8 нче томнарны төзү дә якын елларда тәмамланыр дип көтелә.

һәм Г. Батыршина, 4 нче томны (Безнең көннәр» романы, 1919 елгы вариант) Г. Батыршина һәм 5 нче томны («Безнең көннәр», соңгы – 1934 елгы вариант) Ә. Алиева төзегән, һәр текстка фәнни искәрмә һәм аңлатмалар да бирелгән. Томнарга автор исән чагында гына басылып калган «Адәмнәр» повесте, берничә хикәясенең вариантлары кергән. Искәрмәләрдә әсәрләргә замандашларының мөнәсәбәтен чагылдырган бәяләмәләр дә телгә алына.

Институт әдәбиятчылары классикларыбыз юбилейларына (Тукай, Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан һ. б.), әдәбият белеменең актуаль проблемаларына багышланган фәнни-гамәли конференцияләрдә чыгыш ясадылар, татар мәгариф системасында уздырыла торган чараларга актив катнаштылар, урта мәктәпләр өчен татар әдәбиятыннан дәреслекләр һәм хрестоматияләр төзеделәр. Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә эшләүче әдәбиятчылар 2016 елда, анда саклана торган материалларны өйрәнеп, археография, палеография, кодикология, эпиграфика һәм мәдәни мирасны өйрәнү белән бәйләнеше булган башка юнәлешләрнең актуаль мәсьәләләрен яктырткан, фәнни эзләнү һәм ачышларга корылган «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» исемле яңа серия эшен башлап җибәрде. (редакторы И. Гомәрев). Беренче чыгарылыш, олуг шагыйребезнең тууына 130 ел тулу мөнәсәбәте белән, Габдулла Тукай иҗатына багышланды. Бу елга кадәр аның 6 басмасы дөнья күреп, ул Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, С. Вахиди, Ш. Мәрҗани кебек мәшһүрләребезнең иҗат-хезмәтләрен яктырта.

Институт әдәбиятчылары 2016 елда басылып чыккан Тукай энциклопедиясен (баш редакторы З. Рәмиев) төзүгә дә күп көч куйды. Иң элек анда урнаштырылачак мәкалә һәм белешмәләрнең исемлеген булдырырга кирәк иде. Бу эш Н. Юзиев, З. Рәмиев, М. Әхмәтҗанов, Ф. Яхин, Р. Ганиевалар тарафыннан башкарылды. Иң күп мәкалә язучылар да институт хезмәткәрләре булды (кайберләре инде лаеклы ялда). З. Шәйхисламов 234 , Р. Харрасова 216, З. Мөхәммәтшин 195, З. Рәмиев 121, Ф. Бәширов 133, Н. Хисамов 89, А. Садыйкова 56, Ф. Яхин 52 мәкалә язды. Күбесендә Тукай әсәрләренең язылу һәм басылу тарихы, идея-эстетик үзенчәлекләре, кайбер башка телләргә тәрҗемә итү турында сүз бара. Әдәбиятчыларыбызның тыгыз фикерле, лаконик стильдәге мәкаләләре Татар энциклопедия институты төзегән «Татар энциклопедиясе»ндә дә (татарча һәм русча) урын алды. М. Ибраһимов җитәкчелегендәге тукайчылар шагыйрьнең (өч томлы) тормышы һәм иҗаты хроникасын төзүгә кереште.

Кыска гына күзәтүдә дә институт әдәбиятчыларының 80 ел эчендә башкарган фәнни эшләренең колачы киң, нәтиҗәле булганлыгы, хезмәтләрендә актуаль проблемаларны тикшерергә омтылганнары, әдәби күренешләрне анализлаганда совет чорындагы идеология басымыннан котыла барганнары күренеп тора дип уйлыйм.

**Әдәбият**

XX йөз башы татар әдәбияты. Казан: Таткнигоиздат, 1954.

*Закирзянов А.М.* Основные направления развития современного татарского литературоведения (кон. XX – нач. XXI в.). Казань: «Ихлас», 2011. 320 с.

Институт языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова. Казань, 2010. 232 с.

*Рәмиев З.* Әдәбиятчы-текстолог язмалары. Казан: «Ихлас», 2014. 436 б.

50 лет поисков и открытий. Казань: Татар. кн. изд-во,1989. 240 с.

Татарстан Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әдәбият белеме. Казан: ТӘһСИ, 2015. 96 б.

Труды ученых Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова: 1939–2009. Казань , 2010. 208 с.

Труды ученых Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова: 1939–2019: Библиогр. указ. 2-е изд., перераб. и доп. Казань, 2019. 252 с.

***Рәмиев Зөфәр Зәйни улы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 792+78

***Э.М. Галимова***

# Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫНДА ТЕАТР ҺӘМ МУЗЫКА БЕЛЕМЕ ЮНӘЛЕШЕНДӘГЕ ФӘННИ ЭЗЛӘНҮЛӘР

В данной статье представлены некоторые факты из истории формирования отдела театра и музыки Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ. Также раскрывается многогранная деятельность отдела в области театрального искусства, музыковедения, этномузыкологии, хореографического искусства. Статья раскрывает огромный вклад ученых отдела театра и музыки в развитие национальной культуры и искусства, определяет значимость изданных книг сотрудниками за всю историю существования отдела, обозначает творческую стратегию с целью достижения высоких результатов в работе.

**Ключевые слова:** искусство, музыка, театр, хореография, культура, национальное наследие.

This article presents some facts from the history of the formation of the theater and music department of the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov of Academy of Sciences, Republic of Tatarstan. The multifaceted activities of the department in the field of theater, musicology, ethnomusicology, and choreographic art are also revealed. The article reveals the enormous contribution of the researchers of the theater and music department to the development of national culture and art, determines the significance of published books throughout the history of the department, denotes a creative strategy with the goal of achieving high results in work.

**Keywords:** art, music, theater, choreography, culture, national heritage.

Татар халкының мәдәни мирасы гаҗәеп бай. Без иҗтимагый фикер өлкәсендәге җитди казанышларыбыз, күп жанрлы, формасы һәм тематикасы ягыннан төрле әдәбиятыбыз белән горурлана алабыз. Шуның белән бергә, милли сәнгатьнең үзенчәлекле һәм матур әсәрләрендә гәүдәләнеш тапкан нәфасәти хис чагылышлары гаять зур әһәмияткә ия. Музыка, театр, хореография – милләтнең югары рухи үсеше күрсәткечләре. Һәм, әлбәттә, алар тәфсилле һәм тирәнтен өйрәнүне таләп итә.

1968 елда СССР ФАнең Казан филиалы Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институты базасында сәнгать бүлеге ачылуны милли сәнгать белеме үсеше өлкәсендә беренче этап дип санарга кирәк. Бүлек үзенең эшчәнлеген өч юнәлеш буенча алып бара. Әлбәттә, төп игътибар татар халкының театр, музыка, тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать юнәлешләренә бирелә. Бүлек мөдире итеп филология фәннәре кандидаты Ф.Н. Гыйззәтуллин билгеләнә. Нәтиҗәле эшләү өчен күренекле сәнгать белгечләре (Ф.Х. Вәлиев, М.Н. Нигъмәтҗанов, И.И. Илялова, Х.Г. Гобәйдуллин) һәм яшь галимнәр дә

(Һ.К. Мәхмүтов, Д.А. Гыймранова, З.Н. Сәйдәшева ) җәлеп ителә. Сәнгать бүлеге каршында аспирантура ачылу зур вакыйга була. Ул сәнгать белеме өлкәсендә яшь кадрлар әзерләү максаты белән системалы укытуны җайга сала.

Фәнни тикшеренүләрдә, шулай ук яшь белгечләр тәрбияләүдә милли мәдәният өлкәсендә дан казанган шәхесләр нигез салган традицияләрнең күчемлелеген саклауны бүлек мөдире үзенең төп эш принцибына әйләндерә. Нәкъ менә шуңа күрә дә Ф.Н. Гыйззәтуллин хезмәткәрләрдән элгәреләре булдырган бөтен нәрсәне белүләрен, революциягә кадәрге һәм аннан соңгы чорлар вакытлы матбугаты материалларын, архив һәм музей фондларын өйрәнүләрен, информаторлар – өлкән буын мәдәният эшлеклеләре арасында җыю-туплау эше алып баруларын таләп итә. Шулай ук әлеге чорда системалы, тырыш хезмәт нәтиҗәсендә милли сәнгать тарихына һәм теориясенә багышланган фундаменталь фәнни хезмәтләр языла.

1966 – 1971 елларда Мәскәүдә «Наука» нәшриятында 6 томлык «Совет драма театры тарихы» басылып чыга. Анда Б. Гыйззәтнең татар театры турындагы очерклары урын ала. СССР ФАнең Казан филиалы Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институтының сәнгать секторы хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнгән һәм 1975 елда дөнья күргән «Татар совет театры» китабы татар театры белемендә әһәмиятле этап булып тора. Анда, Г. Камал исем ТДАТ тарихына багышланган өлеш белән беррәттән, беренче мәртәбә Республика күчмә (хәзер К. Тинчурин исем. Татар драма һәм комедия театры), Минзәлә һәм Әлмәт театрлары буенча да бүлекләр кертелә. Китап авторлары – А. Әхмәдуллин, Б. Гыйззәт, Х. Гобәйдуллин, И. Илялова, Х. Кумысников, Һ. Мәхмүтов, Д. Гыймранова әлеге эшне зур җаваплылык белән башкарып чыгалар.

80 нче елларда татар драматургиясе буенча гомумиләштерелгән тикшеренүләр барлыкка килә. А. Әхмәдуллин, «Татарская драматургия», «Горизонты татарской драмы»; М. Гайнуллин, «Татарская литература и публицистика XX века» дип исемләнгән китаплар басыла.

Шул вакытларда татар сәхнәсе корифейлары Г. Кариев, С. Гыйззәтуллина-Волжская, Г. Болгарская, Г. Шамуков, К. Тинчурин, Х. Уразиков һ. б. эшчәнлегенә багышланган монографияләр дә пәйда була. И. Иляликованың «Актерское искусство современного татарского театра», «Межнациональные связи татарского театра», «Камал театры» кебек китаплары серия булып нәшер ителә.

1988 елда Һ. Мәхмүтов, И. Илялова, Б. Гыйззәтнең «Октябрьгә кадәрге татар театры» китабы дөнья күрә. Анда революциягә кадәрге сәхнә сәнгатенең тарихи үткәне тәфсилләп сурәтләнә, оешуының төп этапларына күзәтү ясала, театр тормышындагы иң әһәмиятле вакыйгалар һәм казанышлар бәян ителә. Әлеге хезмәт үзендә бай фактик материал туплавы белән кыйммәтле.

Аерым театрларның тарихына багышланган тикшеренүләрне дә билгеләп үтәргә кирәк. Бу уңайдан Д. Гыймранованың китапларын

атарга мөмкин: «Сабир Өметбаев исем. Минзәлә татар дәүләт драма театры», «Әлмәт татар дәүләт драма театры», «Яр Чаллы татар дәүләт театры».

М.Г. Арслановның 1992, 1996 һәм 2002 елларда өч китаптан торган «Татарское режиссерское искусство» дигән хезмәте дә татар театры тарихы буенча гомумиләштерүче җитди хезмәт булып тора. Анда татар режиссурасының үсеш этаплары күрсәтелә, милли сәхнә осталарының аеруча әһәмиятле постановкалары реконструкцияләнә, татар спектакль кую сәнгатенең характерлы үзенчәлекләре һәм әйдәп баручы тенденцияләре ачыклана.

Гомумән алганда, сәнгать бүлеге яшәгән дәвердә театр белеме белгечлеге буенча ике кандидатлык диссертациясе (М.Г. Арсланов, «Творчество Хусаина Уразикова и татарское сценическое искусство 1930 – 1940 годов»; Ф.С. Кадыйрова, «Современный татарский театр (проблемы романтизма)»; «СССР халыклары әдәбияты (Татар әдәбияты)» белгечлеге буенча – бер (А.Р. Салихова, «Литературно-критическое наследие Габдрахмана Карама») һәм бер докторлык диссертациясе (М.Г. Арсланов, «Эволюция режиссуры татарского театра 1906–1941 годах») якланды.

Әлеге теманың төрле аспектлары М. Г. Арслановның «Хөсәен Уразиков» (1986), «Режиссер Ширъяздан Сарымсаков» (2004), «Актер. Режиссер. Драматург.Педагог» (2006), «Тылсым. Татар театры: режиссерлар һәм драматурглар» (2008) дип исемләнгән монографияләрендә ачыла. Әйтергә кирәк, А.Р. Салихованың 2003 елда басылып чыккан «Татарский театр в литературно-критическом наследии Габдрахмана Карама» монографиясе дә татар театр тәнкыйте мәсьәләләренә багышланган.

Бүлектә татар халык һәм профессиональ музыкасын өйрәнү белән М.Н. Нигъмәтҗанов, З.Н. Сәйдәшева, А.А. Алмазова, Н.Ю. Әлмиева, Г.Б. Гобәйдуллина, Г.Р. Сәйфуллина, Г.М. Макаров, Э.Р. Каюмова, Г.Р. Туймова шөгыльләнә. Күп елларга сузылган экспедицион һәм фәнни-тикшеренү эшнең нәтиҗәләре булып М. Нигмәтҗановның «Татарские народные песни» (М.,1970; Казань, 1984); З. Сәйдәшева һәм Х. Ярминең «Татарско-мишарские песни» (М., 1979); А. Алмазованың «Фарид Яруллин и татарский балет» (Казань, 1987); Ф. Салитованың «Музыкальные драмы Салиха Сайдашева» (Казань, 1988); Э. Каюмованың «Милли көйләр. Татар-төрки моңнары» (Солтан Габәши материаллары буенча) (Казан: Мәгариф, 2002), «Татарская народно-песенная культура Нового времени: Проблемы традиционного мышления и жанровой атрибуции» (Казань, 2005); Г. Макаровның «Традиционные духовые музыкальные инструменты Волго-Камья» (Казань, 2006) китаплары нәшер ителә. Аларда татар музыка фольклорының күп кенә җыр һәм инструменталь культура үрнәкләре урын ала, бу әсәрләрне халыкчан башкару манерасы теркәлә. Профессиональ музыка мәсьәләләренә багышланган хезмәтләрдә татар музыка мәдәниятенең күренекле эшлеклеләре тормышы һәм иҗаты турында

кыйммәтле материаллар фәнни әйләнешкә кертелә, аларның әсәрләре нинди жанрга карауларыннан һәм стилистик бердәмлек билгеләреннән чыгып анализлана, татар музыкасын дөнья музыка сәнгатенең тәэсирле чаралары белән баету процессы өйрәнелә.

Гомумән алганда, 17.00.02. «Музыка белеме» белгечлеге буенча бүлектә 13 кандидатлык диссертациясе языла: З.Н. Сәйдәшева «Татар композиторларының җыр иҗатында фольклор традицияләре»; А.А. Алмазова «Ф. Яруллинның “Шүрәле” балеты һәм күпмилләтле совет сәнгате тарихында аның урыны»; М.П. Фәйзуллаева «Татар операларында халык җыры нигезе»; Ф.Я. Шәмсетдинова «Татар симфоник музыкасы үсешенең төп этаплары»; Р.Ф. Халитов «Татар халык музыка уен кораллары һәм татар инструменталь музыкасы»; Ф.Ш. Салитова «Татар профессиональ музыкасы барлыкка килүдә С. Сәйдәшев музыкаль драмаларының роле»; Н.Ю. Әлмиева «Керәшен татарларының җыр культурасы: жанр системасы һәм күптавышлылык»; Г.Б. Гобәйдуллина «ХХ гасыр башы татар шигърияте һәм музыкасының үзара йогынты ясашуы»; Г.Р. Сәйфуллина «Традицион татар-мөселман мәдәниятендә Коръән уку»; Э.Р. Каюмова «Яңа заманның татар халык җыры мәдәнияте:традицион фикерләү һәм жанр атрибуциясе мәсьәләләре»; Г.М. Макаров «Идел-Кама буе татарлары аэрофоннары: генезис һәм тарихи реконструкция мәсьәләләре»; Г.Р. Туймова «Кырым татарларының традицион музыкасында дини музыкаль-поэтик жанрлар: мәүлид һәм илаһлар»; Э.М. Галимова «Пермь татарларының традицион музыка мәдәнияте».

2007 елны үзгәреш чоры дип әйтергә була, ни өчен дигәндә, әлеге елның 1 гыйнварында сәнгать бүлеге базасында яңа тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге оештырыла, ә төп бүлекнең исеме театр һәм музыка бүлеге дип үзгәртелә.

2009 елда «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт театры. Йөз ел. Ике томда» альбомы басылып чыгу зур вакыйгага әверелә. Аны әзерләүдә һәм язуда ТӘһСИнең театр һәм музыка бүлеге хезмәткәрләре М.Г. Арсланов, Д.А. Гыймранова, А.Р. Салихова турыдан-туры катнаша.

М. Г. Арслановның 2014 елда дөнья күргән «Татарский театр: энциклопедический словарь-справочник» дип аталган китабын чагыштырмача күптән түгел чыккан басма дияргә мөмкин. Китапта бай фактик һәм теоретик материал тупланган. Персоналияләр, сәхнә әсәрләре, театр коллективлары белән бергә анда махсус һөнәри терминнар да кертелгән. Шулай ук 2014 елда Д.Р. Фәрдиеваның «Национальная проза на сцене Татарского государственного академического театра имени Г. Камала» китабы басыла.

2016 елда театр һәм музыка бүлеге мөдире итеп композитор, сәнгать фәннәре кандидаты, РФ һәм ТР Композиторлар берлеге әгъзасы, М. Җәлил исем. Республика премиясе лауреаты Эльмира Галимова билгеләнә.

Хәзерге вакытта театр һәм музыка бүлеге «Сәнгати мәдәниятнең күчемлелеге һәм үсеше мәсьәләләре» дигән гомуми тема өстендә

эшли. Бүлек эшчәнлегендә түбәндәге төп өч юнәлешне аерып күрсәтү зарур: «Татар театры тарихы», «Идел-Урал төбәге татарларының рухи мәдәнияте системасында музыка сәнгате» һәм «Идел буе татарларының рухи мәдәнияте системасында халык биюенең үзенчәлеге».

«Татар театры тарихы» фәнни юнәлеше буенча үткәрелгән тикшеренүләрнең актуальлеге әлеге эшнең беренче мәртәбә оештырылуында. Тикшеренү предметына яңача, җәмгыять тормышындагы социаль үзгәрешләр белән бәйләнештә һәм идеологик катламнардан арынып якын килү, шулай ук эшкә фәнни гамәлияттә моңарчы файдаланылмаган материалны җәлеп итү аның кыйммәтен арттыра һәм кызыксынуны көчәйтә. Хәзерге вакытта татар театр сәнгатен өйрәнү аеруча актуаль. Бу иҗат процессының активлыгы белән дә, жанр составының яңарып торуы белән дә, сәхнә әсәре тудыру процессына карата калыплашкан карашларны яңадан карау белән дә бәйләнгән. Әлбәттә, бу этапта татар театр сәнгатен аның бөтен тарихи үсеше процессында өзлексез иҗади процесс итеп карарга кирәк. Бу өлкәдә фәнни тикшеренү эше белән филология фәннәре кандидатлары А.Р. Салихова һәм Д.Р. Фәрдиева шөгыльләнә.

«Идел-Урал төбәге татарларының рухи мәдәнияте системасында музыка сәнгате» юнәлеше буенча фәнни тикшеренүләр этник музыкаль мирасны өйрәнүгә һәм саклауга, тарихи күчемлелек проблемаларын хәл итүгә, традицион кыйммәтләрне кабат торгызуга юнәлтелгән. Әлеге юнәлештәге тикшеренүләрнең актуальлеге нәкъ менә шул факт белән билгеләнә дә. Монографиянең беренче мәртәбә фәнни әйләнешкә кертелгән практик һәм теоретик материалларын Россиянең төрле регионнарында яшәгән татарларның музыкаль фольклорын өйрәнүгә кагылышлы, музыка белеме һәм этномузыкология өлкәсендә фәнни хезмәтләр язганда, методик әсбаплар төзегәндә файдаланырга мөмкин.

Бу юнәлеш кысаларында сәнгать фәннәре кандидаты Э.М. Галимова, Г.Ф. Юнысова, педагогика фәннәре кандидаты Н.Х. Нургаянова актуаль фәнни тикшеренүләр алып бара.

2017 елдан башлап театр һәм музыка бүлегендә милли хореография мәсьәләләре дә өйрәнелә башлады. Халык хореографиясенең тарихи аспектлары төрле халыкларның формалашкан этник традицион мәдәниятен тирәнтен танып белүгә гаять нык тәэсир итә. Хәзерге заман мәгарифе һәм мәдәнияте контекстында нәкъ менә халык биюе профессиональ хореография сәнгате үсешенең нигезе һәм чыганагы булып тора. Шуңа күрә, бүгенге көндә, «Этнос һәм Идел буе халыкларының бию культурасы: тарихтан хәзерге заманга» дигән теманы этаплап өйрәнү һәм әлеге темага фәнни басма әзерләү максаты куелды.

Соңгы ун ел бүлек өчен фәнни яктан аеруча продуктив булды: заманча фәнни тикшеренүләр алып барылды, масштаблы проектлар оештырылды. Гомумән алганда, төбәк, бөтенроссия, халыкара статуслы фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашу алга таба да максатчан эшчәнлек алып барырга зур этәргеч бирә, дип әйтергә кирәк.

Бүлек тарафыннан уздырылган фәнни чараларның берсе – Татар театрының 110 еллыгына багышланган «XX гасыр театры һәм яңа заман чакырулары» Халыкара фәнни-гамәли конференциясе (Казан, 2016 ел, 22 декабрь) зур иҗтимагый резонанс тудырды. Конференция программасы дөнья театрларына, мәдәниятләрнең үзара тәэсир итешүенә кагылышлы актуаль мәсьәләләрне, театр тарихы һәм теориясе, педагогика, музыка һәм сәхнә бизәлеше аспектларында драматургиянең, театраль процесс гамәлиятенең роле кебек сорауларны да читләтеп үтмәде. Конференция эшендә Россиянең (А.А. Степанова, К. Матвиенко, А. Сәгыйтова), чит илләрнең (Катажина Осиньская, Польша; С.К. Кабдиева, Казакъстан) әйдәп баручы театр белгечләре, КФУ, Казан дәүләт мәдәният институты, Н.Г. Җиһанов исем. Казан дәүләт консерваториясе галимнәре, театр һәм башка мәгариф учреждениеләре укытучылары, татар драма театрлары, Милли музей, ТР Язучылар берлеге вәкилләре катнашты.

2017 елның сентябрендә ТР Фәннәр академиясендә, Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ булышлыгы белән, театр һәм музыка бүлеге тарафыннан күренекле драматург, актер һәм режиссер Кәрим Тинчуринның тууына 130 ел тулу уңаеннан «Кәрим Тинчурин һәм татар театры» Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе уздырылды. Анда татар театры һәм милли мәдәниятнең үзара тәэсир итешүе һ. б. мәсьәләләр К. Тинчуринның бай иҗаты аша ачыктыртылды.

2017 елның декабренда узган «Халык биюе һәм хореография сәнгате: традицияләр һәм хәзерге заман» Халыкара фәнни-гамәли конференциясе җәмәгатьчелек тарафыннан әһәмиятле фәнни һәм мәдәни вакыйга буларак кабул ителде. Г. Таһировның тууына 110 ел тулуга багышланган конференцияне ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге оештырды. Ул ТР ның Дәүләт җыр һәм бию ансамбле һәм Казан дәүләт мәдәният институтының хореография сәнгате факультеты халык биюе кафедрасы ярдәме белән узды. Нәкъ менә Гай Хаҗи улы Таһиров – татар халкының профессиональ бию культурасы барлыкка килүдә һәм үсеп китүдә аерым роль уйнаган шәхес. Шуңа күрә аны хаклы рәвештә татар халкының сәхнә биюен булдыручы, әлеге юнәлештә эшне башлап җибәрүче дип атыйлар.

Конференциянең тематик программасы түбәндәге юнәлешләрне үз эченә алды: хореография фольклорының актуаль мәсьәләләре һәм аны сәхнә сәнгатендә гамәлгә ашыру; халык хореографиясенең этник үзенчәлеге; хәзерге заман мәгарифе һәм мәдәнияте контекстында профессиональ хореография; фольклор биюен өйрәнүнең теоретик аспектлары һәм тормышка ашыруның гамәли формалары; Г.Х. Таһиров мирасы һәм аның балет куелышларында, халык биюләрендә гәүдәләнеше; хәзерге заман хореографиясендә традицион фольклор жанрларын саклау һәм үстерү. Конференциянең халыкара статусын раслап, Казанга танылган хореографлар, балетмейстерлар, Россия хореографиясе өлкәсендә тикшеренүчеләр килде: Л.А. Касиманова

(Санкт-Петербург), Е.А. Кузнецов (Мәскәү), М.А. Кәримов (Уфа), Арман Нурмахаматулы (Әнкара, Төркия), Тарана Мурадова Гусейн (Баку, Азәрбайҗан), Г.Ю. Сәетова (Астана, Казакъстан).

2017 елның октябрендә театр тәнкыйтьчесе Дания Гыймранованың тууына 80 ел тулу уңаеннан «Татарстан Республикасында театр тәнкыйте һәм театр белеменең актуаль мәсьәләләре» дигән темага уздырылган түгәрәк өстәлне дә Институт тарафыннан оештырылган әһәмиятле чара дип әйтеп була.

«Филология һәм сәнгать фәннәре» халыкара яшьләр мәктәбе кысаларында ел саен уздырыла торган проектта бүлекнең театр белеме һәм этномузыкология өлкәсендә эшләүче галимнәре үз белемнәре белән анда катнашучылар, аспирантлар һәм студентлар белән уртаклашалар.

Бүлекнең өлкән фәнни хезмәткәре Д.Р. Фәрдиеваның «Нәүрүз» Халыкара саммиты (Анталья, Төркия) кысаларында Халыкара татар мәдәнияте симпозиумын оештыруга һәм фәнни мәкаләләр җыентыгын әзерләүгә керткән өлеше игътибарга лаек. Әлеге җыентыкта шулай ук Э.М. Галимова, А. Р. Салихова, Н.Х. Нургаянова мәкаләләре дә урын алган.

Әйтергә кирәк, театр һәм музыка бүлеге хезмәткәрләре жюри әгъзалары сыйфатында төрле конкурс һәм фестивальләрдә катнашып, гомумән, Татарстанның милли-мәдәни тормышында да бик актив катнашалар.

Бүлек мөдире, сәнгать фәннәре кандидаты Э.М. Галимова Идел һәм Урал буе композиторларының «Идел-Урал» Бөтенроссия музыка фестивалендә, «Европа-Азия» Халыкара яңа музыка, РФ Композиторлар берлеге оештырган Бөтенроссия Россиянең яшь композиторлары, Н. Г. Җиһанов исем. «Мирас» Татар музыкасы фестивальләрендә даими катнашып килә. Композитор буларак ул – «Россиянең яшь композиторлары» дигән бөтенроссия һәм халыкара фестивальләрендә дә даими катнашучы. Ел саен ТР Мәдәният министрлыгының берничә эксперт советында жюри әгъзасы сыйфатында эшли.

Фәнни эш белән шөгыльләнүдән тыш, композитор Эльмира Галимованың иҗат эшчәнлеген дә аерым билгеләп үтәргә кирәк. Ул – 200 дән артык җыр һәм романслар, төрле жанрларга караган 100 гә якын музыкаль әсәр авторы. Алар арасында: «Сөембикә канаты» арт-операсы, симфоник картиналар («Четыре стихии», «Небеса-зеркала», «Симфоническая аллегория», «Жизнь по знакам Маугли»), 3 бүлектән торган фортепиано өчен концерт, камера-инструменталь жанрлар, музыкаль драмалар («Зәйтүнәкәй», «Каракүз», «Афәрин, артист»), балалар өчен «Әйт әле, күбәләк» музыкаль мистериясе (Г. Тукай әкиятләре буенча), тарихи эпосларга («Айрыз-батыр», «Баһадур»), драма спектакльләренә көй язу һ. б.

Театр һәм музыка бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре А.Р. Салихова республиканың театр тормышында актив катнаша: театр корылтайлары, форумнар һәм фестивальләр эшендә,

спектакльләрне тикшерүдә, «Яңа татар пьесасы», «Тантана» кебек конкурс һәм региональ театр чараларында жюри әгъзасы буларак.

Театр һәм музыка бүлеге галимнәренең хезмәтләре дә бик актив басыла. 2016 елда татар театрының 110 еллыгына А.Р. Салихованың «Особенности формирования и развития татарского сценического искусства» дигән гомумиләштерү характерындагы хезмәте дөнья күрде. Э.М. Галимова 2017 елда «Традиционная музыкальная культура пермских татар» монографиясен чыгарды. Фәнни басмада төрле жанрларга караган 115 нота үрнәге һәм пермь татарларының сирәк очрый торган 55 җыры һәм инструменталь көйләре язылган аудио-диск урын алган. 2018 елда Д. Р. Фәрдиеваның «Роберт Миңнуллин шигърияте (тел үзенчәлекләре һәм төп мотивлар)» дип аталган монографиясе дөнья күрде. Шул ук елны Г.Ф. Юнысова Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәге фондлары буенча «Саратов өлкәсе татарлары» юлкүрсәткечен бастырды. Россиядә фольклор фондлары буенча күрсәткечләр төзү эше әле башланып кына килә. Һәм ул беренчеләрдән булып Татарстанда гамәлгә ашырылды.

Бүлек тарафыннан түбәндәге фәнни җыентыклар әзерләнде: «Театр XXI века и вызовы нового времени: материалы Международной научно-практической конференции, посвященной 110-летию татарского театра» (2016); «Народный танец и хореографическое искусство: традиции и современность: материалы Международной научно-практической конференции, посвященной 110-летию Гая Тагирова» (2017); театр сәнгатенең күренекле әһелләре – Габдулла Кариевка, Солтан Габәшигә, Мирхәйдәр Фәйзигә багышланган «Коль хочешь ты народу душу тронуть – Уятмакчы булсаң халык күңелләрен» буклеты.

Ел саен Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Татарстан Республикасы районнарына һәм аннан читтә татарлар тупланып яшәгән урыннарга комплекслы махсус экспедицияләр оештыра. Бу өлкәдә этномузыкологлар Э.М. Галимова һәм Н.Х. Нургаянова аеруча актив эшли. Аларның Пермь (Барда), Оренбург, Новосибирск өлкәсе, Башкортстанның Стәрлебаш районы татарларының традицион музыка мәдәниятенә багышланган мәкаләләре «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендәге коллектив монографияләрдә басылып чыкты.

Күргәнебезчә, татар сәнгать белеме корифейлары тарафыннан булдырылган традицияләр күчемлелеге хәзерге фәнни тикшеренүләрдә дә саклана. Димәк, яңа буын тикшеренүчеләрнең хезмәтләрендә дә фәнни нәтиҗәләр үзләренең актуальлеген югалтмаячак.

***Галимова Эльмира Мөнир кызы,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге мөдире*

УДК 74/76

***Р.Р. Солтанова***

# ТАСВИРЫЙ ҺӘМ ДЕКОРАТИВ-ГАМӘЛИ СӘНГАТЬ БҮЛЕГЕ: ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН КОНТЕКСТЫНДА МИЛЛИ-ТӨБӘК СӘНГАТЕ ФЕНОМЕНЫ

В статье рассматривается формирование в отделе изобразительного и декоративно-прикладного искусства ИЯЛИ им. Г Ибрагимова новой научной концепции, базирующейся на методе комплексного историко-искусствоведческого исследования, в рамках общей темы «Формы национально-художественного мышления татар в историко-культурных контекстах». Дается систематизация и краткая характеристика основных исследований.

**Ключевые слова:** искусствоведение, изобразительное и декоративно-прикладное искусств, методология, системно-комплексное исследование.

The article discusses the formation of a new scientific concept based on the method of complex historical and art historical research, within the framework of the general theme «Forms of the Tatars' national and artistic thinking in historical and cultural contexts» in the department of fine and decorative arts Of the Institute of language, literature, and art named after G. Ibragimov. A systematization and brief description of the main studies is given.

**Keywords:** art history, visual and decorative and applied arts, methodology, system-integrated research.

Мөстәкыйль тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге 2007 елда оештырыла (сәнгать белеме бүлеге составында әлеге юнәлеш 1968 елдан ук алып барыла, беренче җитәкчесе – Ф.Х. Вәлиев) һәм үзенең эшчәнлеген «Тарихи-мәдәни контекстта татарларның милли-сәнгати фикерләү формалары» дигән гомуми тема кысаларында комплекслы тарихи һәм сәнгать фәннәре тикшеренүе методына нигезләнгән яңа фәнни концепция буенча төзи. Бүлек үсешенең концептуаль планы тасвирый материалны фәлсәфи, нәфасәти, контекстуаль-культурологик анализ идеяләре белән ныгытуны күз алдында тота. Төп өйрәнү предметы милли-сәнгати фикерләү үзенчәлеген төрле-төрле контекстларда ачыклаудан гыйбарәт: тарихи (Идел Болгары, Алтын Урда, Казан ханлыгы, Казан губернасы, совет һәм постсовет чорлары), мәдәни (мөселман сәнгате, төрки дөнья, хәзерге дөнья сәнгатендәге, Россия киңлекләрендәге, Идел һәм Урал буенда этник-милли чолганыштагы тенденцияләр h. б.).

Мондый төрлелекнең максаты – гаять киң сәнгати иҗат материалында (күптөрле жанр һәм төрләрне үз эченә алган тасвирый сәнгать, декоратив-гамәли сәнгать, сәхнә бизәлеше, архитектура) татар сәнгати-пластик фикер йөртү үзенчәлеген башка мәдәниятләр белән бәйләнештә өйрәнү. Әлеге юнәлештә дизайн анализы аеруча

перспективалы, чөнки ул тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгатьнең барлык форма һәм төрләрен үз эченә ала.

Бу фундаменталь программаны гамәлгә ашыру өчен, бүлектә фәннең арадаш өлкәләре (тарих, фәлсәфә, культурология, социология) буенча әйдәп баручы белгечләрдән торган консультатив совет төзелде, ул төрле этапларда сәнгати мәдәният үсеше мәсьәләләренең куелышына һәм чишелешенә булышлык итәргә тиеш.

Бүлек хезмәткәрләре тарафыннан уздырылган Халыкара фәнни-гамәли конференцияләр: мәгърифәтче-педагог һәм рәссам Шакирҗан Таһировның тууына 150 ел тулуга багышланган «Төрки халыклар сәнгати мәдәниятенең башлангычы һәм эволюциясе» (2008); «Бакый Урманче иҗаты һәм милли сәнгатьнең актуаль мәсьәләләре» (2012); П. Дульскийның тууына 135 ел тулуга багышланган «Россиядә һәм БДБ илләрендә сәнгать белемен үстерүнең актуаль мәсьәләләре» (2014); П. Корниловның тууына 120 ел тулуга багышланган «Россиядә, БДБ илләрендә һәм төрки дөньяда сәнгать белемен үстерүнең актуаль мәсьәләләре» (2017)); симпозиумнар (Төрки дөньяда киез сәнгате: тарих, хәзерге заман» (2009); «Төрки дөньяда агачка кисеп бизәк ясау сәнгате: тарих, хәзерге заман» (2017) Идел-Урал буенда гына түгел, ә бөтен төрки дөньяда тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать өлкәсендәге тикшеренүче галимнәрнең тырышлыкларын берләштерүдә зур адым булды. Әлеге форумнарның нәтиҗәсе буларак, фәнни җыентыклар нәшер ителде, бөтен төрки дөнья сәнгать фәннәре галимнәренең координацион советы төзелде.

Бүлекнең үсеш концепциясеннән чыгып һәм яңа күрсәтмәләрне исәпкә алып, хезмәткәрләр берничә юнәлештә тикшеренүләр алып баралар. Борынгы сәнгать, шулай ук тасвирый сәнгатьнең хәзерге замандагы торышы сәнгать фәннәре кандидаты Д.К. Вәлиеваның фәнни кызыксыну-өйрәнү өлкәсе булды. Ул үзенең «Искусство Волжской Булгарии периода Золотой Орды» (Казань, 2003) китабында Әстерханнан алып Казанга кадәр җәелдерелгән археологик казу эшләре материалларын, табылган яңа язма чыганакларны, музей коллекцияләрен файдаланып, Идел Болгары сәнгатен Алтын Урда сәнгате контекстына кертеп карый. Коллектив монографиядә («Город Булгар», Москва: Наука, 2008) урын алган «Искусство города Болгар» очеркында ул беренче мәртәбә монголларга кадәрге һәм Алтын Урда чорлары Болгар шәһәре сәнгатенең үсеш картинасын бербөтен итеп бирә.

Р.Р. Солтанованың «Искусство новых городов Республики Татарстан» (Казань, 2001) дигән китабы – республиканың яңа сәнәгый шәһәрләре (Әлмәт, Бөгелмә, яшел Үзән, Лениногорск, Яр Чаллы, Түбән Кама, Алабуга) тасвирый сәнгате буенча үзендә, сәнгать фәннәре күзлегеннән, культурологик һәм социологик мөнәсәбәтләрне берләштергән беренче тикшеренү. Анда тасвирый сәнгатьнең барлык төр һәм жанрларының оешу һәм үсеш этаплары билгеләнә, һәр этаптагы төп тенденцияләр ачыклана, милли үзенчәлек төрле стиль тенденцияләрендә күрсәтелә.

Р.Р. Солтанованың 2018 елда якланган докторлык диссертациясе «Сценография татарского театра: основные этапы и закономерности развития (XX – нач. XXI века )» гомумроссия мәдәни театр мирасының мөһим өлешен тәшкил иткән татар театрының сәхнә бизәлешен өйрәнүгә багышланган (17.00.04 – «Тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать һәм архитектура» белгечлеге буенча). Бу фундаменталь һәм комплекслы тикшеренүнең теоретик һәм гамәли әһәмияте шактый зур.

Моннан тыш Р.Р. Солтанова хәзерге Татарстанның сәнгатькяросталары иҗатына багышланган берничә китап бастырып чыгарды. «Празат Исанбет. Грани призвания» альбомы (2005) укучыны тәүге мәртәбә режиссер-рәссамның киңкырлы иҗаты белән таныштыра. «Рифкат Вахитов. Мелодия курая» альбом-монографиясе (2007) милли сәнгать үсешенә үзеннән зур өлеш керткән республикабыз тасвирый сәнгате вәкилләренең берсе булган рәссамның картиналарын һәм монументаль-декоратив әсәрләрен анализлауга багышланган. Бу хезмәте өчен Р.Р. Солтанова Б. Урманче исем. Республика премиясенә лаек булды (2012). «Зуфар Гимаев» дип исемләнгән китапта (Казань, 2018) ул рәссамның иҗат эволюциясен совет һәм постсовет чорларында Татарстан тасвирый сәнгате үсешенең төп тенденцияләре яктылыгында күрсәтә. «Тан Еникеев. Эскизы/ в соавторстве» (Казань, 2018) китабында хәзерге заманның танылган остасы, татар театрларында (Г. Камал исем. ТДАТ, Әлмәт драма театры, Г. Кариев исем. Татар яшь тамашачылар театры) татар классикасы, рус һәм чит илләр драматургиясе буенча куелган спектакльләрнең сәхнә бизәлешен эшләгән Т. Еникиевның иҗатына беренче тапкыр анализ ясала.

Сәнгать фәннәре кандидаты Р.И. Шәмсутов тарихи вакыт агышында һәм үсештә татар шәмаилләре һәм каллиграфия сәнгатен өйрәнде. Аның «Искусство татарского шамаиля сер. XIX–XX века» (Казань, 2001) монографиясендә татарларда гарәп каллиграфиясе сәнгатенең үсеш үзенчәлекләре ачыла. Ул шәмаилнең билгеләр системасын беренче тапкыр Галәм киңлеге моделе итеп карый, суфилар һәм шигыйлар символикасының чагылышына игътибар итә, шәмаил текстларындагы «мөселман татарларда халык исламы»н өйрәнү өчен материал булып торган кече әдәби жанрларның үрнәкләрен китерә. «Слово и образ в татарском шамаиле: от прошлого до настоящего» дип аталган тагын бер китабы (Казань, 2003) татар шәмаиле сәнгатенең гасырдан артык үсеш чорын колачлый. Шәмаилләрдәге тасвирый мотив һәм текстлар нисбәтенә зур игътибар бирелә. Бу шәмаилләр типологиясе мәсьәләсен ачыклауга юл ача. Урта Идел һәм Урал буе татарлары халык исламының характерын ачучы уникаль шәрехләмә текстлары үрнәкләре дә беренче тапкыр басыла.

Р.И. Шәмсутовның «Декор культовых сооружений татар-мусульман Среднего Поволжья и Приуралья» дигән яңа тикшеренүенең максаты – архитектура корылмаларының гомуми тышкы күренешендә, дини корылмалар интерьерында декоратив элементларның

функциональ ролен ачыклау, төрле сәнгать төрләре (витраж, мозаика, уеп бизәк төшерү) синтезы проблемасын чишү.

2009 елда Дәүләт Шәрык халыклары сәнгате музеенда (Мәскәү) Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ юбилее уңаеннан оештырылган гарәп графикалы әсәрләр күргәзмәсенә Р.И. Шәмсутов тарафыннан төзелгән каталог революциягә кадәрге басмаларны да, хәзерге заман авторларының әсәрләрен дә берләштергән татар шәмаиле сәнгатен өйрәнүдә чираттагы яңа баскыч булып тора.

Бүлек эшчәнлегендә иң әһәмиятле юнәлешләрнең берсе – иң борынгы чорлардан алып XXI гасыр башына кадәр Татарстан графика сәнгатенең бөтен төрләрен тикшерү: каллиграфия, китап сәнгате, татар графикасының иң борынгы формалары (ярлыклар, шәҗәрә һ. б.), шулай ук Татарстанда XIX гасырдан үсеш алган Европа графикасы төрләре.

О.Л. Улемнованың «Искусство графики Татарстана 1920–30-х годов» дигән темага язылган диссертациясе (Мәскәү, 2005) Татарстан графикасының бербөтен тарихи үсеше картинасын булдыруга зур өлеш кертте. Анда Татарстанның милли тасвирый сәнгате барлыкка килүне билгеләгән иң әһәмиятле чорларның берсе өйрәнелгән һәм станок графикасы (рәсем, гравюра), производство графикасы, плакат, китап һәм журнал графикалары анализланган.

Соңгы елларда төрле этапларда (1910–1920 еллар, XX гасырның икенче яртысы, хәзерге заман) Татарстанның авангард сәнгатен өйрәнүгә аерым игътибар бирелә. О.Л. Улемнованың шушы юнәлештәге күпьеллык тикшеренүләре сәнгать күргәзмәләре һәм аларга атап чыгарылган басмалар рәвешен алды (Татарстан Республикасы сынлы сәнгать музее белән берлектә): «Казанский авангард 1910–1930-х» (2013–2014); «Графический коллектив «Всадник» (2013–2014); «К. Чеботарев. А. Платунова. Жизнь в искусстве» (2017). Биш күргәзмәдән торган «Московские казанцы» (2017–2018) сериясе Татарстанда беренче мәртәбә Казанда укыган һәм һөнәри эшчәнлеген башлаган, соңыннан рәссам-графиклар булып танылган осталарның (В.Э. Вильковиская, Д.Н. Красильников, Д.П. Мощевитин), скульпторларның (Д.С. Җилов, В.В. Кудряшев) иҗатын төрле яклап яктырта.

Күргәзмә нәтиҗәләре буенча О.Л. Улемнова «Сметая веками насевшую пыль...» Графический коллектив «Всадник». 1920–1924» (Казань, 2014) альбом-каталогын төзеде. Анда күргәзмәгә куелган экспонатлар гына түгел, башкала музейларында һәм шәхси коллекцияләрдә сакланган әсәрләр дә кертелгән. Хезмәттә 1920 еллар Казан авангардының иң ачык күренешләренең берсе булган» «Җайдак» («Всадник») феномены бөтен яклап тикшерелә. Каталог-альбом Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б. Урманче исемендәге бүләгенә лаек булды (2015).

О.Л. Улемнова тарафыннан Н.М. Вәлиев катнашында һәм «ТАИФ» компанияләр төркеме булышлыгы белән төзелгән «Константин Чеботарев. Александра Платунова. Живопись. Графика.

Из музейных и частных собраний» (Казань, 2018) каталог-альбомы 1920 еллар Казан авангардының күренекле осталары тудырган сәнгать әсәрләренең барысын да диярлек колачлаган (Россиянең 11 музееннан һәм 7 шәхси тупланмадан – 700 гә якын саклау берәмлеге).

Хәзерге заманда Татарстан, Россия, чит илләр графика сәнгатендә барган процессларны да О.Л. Улемнова читләтеп үтми. Ул – 2011 елдан бирле уздырылып килә торган халыкара «Җайдак» басма графика күргәзмәсененең (биеннале) даими кураторы. Анда дөньяның төрле почмакларыннан рәссам-графиклар җыела. Һәр биеннале уңаеннан чыгарылган каталогларның да төзүче-авторы – О.Л. Улемнова.

Ф.Г. Вәһапованың «Художественное оформление татарской книги в дореволюционный период» дигән хезмәтендә стиль эволюциясе өйрәнелә, Россиянең һәм чит илләрнең (Урта Азия, Төркия, Иран) гарәп графикалы китаплары системасында татар китабының урыны билгеләнә. Бу тикшеренүнең төп бурычларының берсе – татар бизәүче рәссамнарының һәм күчереп язучы каллиграфларның исемнәрен ачыклаудан гыйбарәт.

О.Л. Улемнова һәм Ф.Г. Вәһапованың тикшеренүләре нәтиҗәсе булып ике томлы «Искусство книги Татарстана» хезмәте торырга тиеш. 1 нче томда – XX гасыр башына кадәр татар китабы сәнгати бизәлешенең башлангыч алуы һәм үсеше яктыртылачак, 2 нче томда – 1917 елдан алып XXI гасыр башына кадәрге вакыт аралыгы чагылыш табачак. Китап рәссамнары сүзлеге, күпсанлы иллюстратив материал да урын алачак. Милли традицияләре бик тирәнгә киткән татар китабын бизәү сәнгатенә багышланган хезмәтләрнең актуальлеге (кызганычка каршы, аларны моңарчы беркем дә махсус өйрәнмәде) XXI гасыр башында Татарстанда полиграфиянең интенсив үсүе белән бәйле. Әмма ул төрле стильдә, эклектик характерда булу белән характерлана.

Өлкән фәнни хезмәткәр Л.Н. Донинаның «Интерпретация татарского национального костюма в татарском театре» дип исемләнгән тикшеренүендә төрле фәннәр кисешә: сәнгать белеме, театр белеме, нәфасәт, семиотика, этнография, филология. Бу – шулай ук бүлек эшендә яңа юнәлеш. Моңарчы милли костюм бары тик тарихи-этнографик аспектта гына өйрәнелде. Теманың актуальлеге шуның белән аңлатыла да. Л.Н. Донина үзенең хезмәтендә традицион киемне театр мәйданында гадәти күзаллау кысаларына гына сыешмаган контекстуаль мәгънәгә ия билге итеп карау мәсьәләсен куя. Л.Н. Донинаның «П.Т. Сперанский. Л.Л. Сперанская-Штейн. От эскиза к спектаклю» альбом-каталогы – (2010) күпсанлы архив, музей материалларына, язма һәм визуаль чыганакларга нигезләнеп, еллар дәвамында алып барылган тикшеренүләр нәтиҗәсе. Бүгенге көндә Л.Н. Донина «Татарстан рәссамнары» биобиблиографик күрсәткеченә кертү өчен нәкыш, декоратив-гамәли сәнгать осталарының иҗатын өйрәнә.

Тасвирый сәнгатьнең бер төре буларак скульптура тарихи вакыт агышында (барлыкка килүеннән алып бүгенге көнгә кадәр) аспирант

Т.Н. Кривошеева, фәнни хезмәткәр Д.Д. Хисамова тарафыннан тикшерелде.

Т.Н. Кривошееваның кандидатлык диссертациясенә таянып язылган «Особенности развития скульптуры Татарстана (истоки, становление, продолжение традиций)» монографиясендә беренче мәртәбә татар скульптурасының башлангычы һәм формалашу үзенчәлекләре проблемасы куела. Бу – тарихи-мәдәни колачы белән масштаблы мәсьәлә. Авторның казанышы шунда, ул С. Дадашевның «Төрки миниатюраның формаль тасвирый теле теориясе»н монументаль скульптура әсәрләренә карата да иҗади куллана. Д.Д. Хисамованың «Художественные процессы в монументальной скульптуре Татарстана второй половины XX – начала XXI века» дип аталган хезмәтендә (2012) беренче тапкыр Татарстан монументаль скульптурасы үсешенең тулаем картинасы торгызылган. Теманың актуальлеге нәкъ менә шушы чорда республика скульптурасына үз иҗатларында Казан сәнгать мәктәбенең рус скульптурасы традицияләрен дәвам иткән профессиональ осталар килү белән аңлатыла.

Бүлектә фәнни тикшеренүләрнең тагын бер яңа юнәлеше – архитектура һәм шәһәр төзелеше сәнгать фәннәре кандидаты Г.Г. Ногманованың «Архитектура и градостроительство Казанской губернии в период Российской империи (XVIII – нач. XX в.)» хезмәтендә чагылыш тапты. Ул теоретик характерда булуы белән генә түгел, ә хәзерге заман архитектурасы, шәһәр төзелеше, реставрация эшләре өчен дә гамәли әһәмияткә ия.

Хезмәттә Россия империясе шартларында Идел-Кама төбәгенең архитектура-шәһәр төзелеше үзенчәлекләре ачыклана. Хронологик рамкалар төбәкнең архитектура һәм шәһәр төзелеше үсеше тарихын яңадан торгызырга, республиканың тарихи-мәдәни мирасына реконструкция һәм реставрация ясаганда кабул ителгән проектларны нигезләргә мөмкинлек бирүче архив документларының бик күп булуы белән аңлатыла.

Өлкән фәнни хезмәткәр Л.М. Шкляеваның «Народное искусство домовой резьбы у татар Среднего Поволжья середины XX – начала XXI века: семантика и стилевые особенности» (2017) монографиясе дә кандидатлык диссертациясе нигезендә нәшер ителде. Тикшеренүдә казан татарларында, керәшеннәрдә һәм Урта Идел буенда яшәүче мишәрләрдә хәзерге заман йортны кисеп-уеп бизәү сәнгатенең милли үзенчәлекләре, шулай ук корылмаларның сырлы фасад декоры орнаментында стиль тудыручы элементлар һәм образлы-сәнгати чишелеш һәм семантика факторлары ачыклана.

Китап шәхсән автор һәм башка хезмәткәрләр тарафыннан күпсанлы экспедицияләр дәвамында җыелган кыр материалларына таянып язылган. Мондый тикшеренүләр бигрәк тә актуаль, чөнки хәзерге заманда татар халкы мәдәниятенең төрле формалары акрынлап юкка чыга бара, дөньяның традицион картинасы үзгәрә. Л.М. Шкляева – «Искусство народов Поволжья» һәм «Золотая птица» сериясендә

чыккан каталоглар, Урта Идел буе татарлары һәм анда яшәүче башка җирле халыклар сәнгате буенча Россиядә, Германиядә, Казакъстанда, Азәрбайҗанда, Төркиядә басылган очерклар авторы да.

Татарстан музейларында сәнгать коллекцияләре барлыкка килүне өйрәнү – бүлекнең фәнни-тикшеренү эшчәнлегендә шулай ук яңа юнәлеш. Бу эш белән фәнни хезмәткәр Н.В. Герасимова шөгыльләнә. Шәхси һәм дәүләт музейлары күп ачылу, шулай ук хәзерге музейларның үз коллекцияләрен өйрәнү, аларның каталогын төзү, Россия Федерациясе музей фондының дәүләт каталогын булдыру кысаларында экспонатларның чыганакларын ачыклау буенча актив фәнни эшчәнлек җәелдерүләре белән бәйле рәвештә, музей эшенең тарихи үткәнен өйрәнү безнең көннәрдә аеруча актуальләшә. Тикшеренүләрнең нәтиҗәләре Россиянең фәнни журналларында яктыртылды.

Хәзерге вакытта «Татарстан рәссамнары. XX–XXI гасырлар (Татарстанның сәнгать энциклопедиясе)» биобиблиографик күрсәткечен төзү эше тәмамланып килә. Мондый басма әзерләү зарурлыгы инде күптән өлгергән иде, чөнки республикабыз рәссамнары турындагы соңгы мәртәбә 1980 елларда чыгарылган тулы белешмәлекләр шактый искерде. Әлеге энциклопедик характердагы биобиблиографик басма төрле тарихи чорларда Татарстанның һәм татар диаспорасының сәнгать дөньясын бөтен яклап чагылдырырга, киң җәмәгатьчелеккә аз билгеле яки онытылган исемнәрне торгызырга, республикабыз сәнгате тормышының тулы картинасын тудырырга тиеш.

Бүлек хезмәткәрләре Татарстан рәссамнары (нәкышчеләр, графиклар, скульпторлар, монументалистлар, проектчылар, фотографлар) буенча биобиблиографик материалны системага салалар, яңа исемнәрне һәм биографик мәгълүматларны ачыклыйлар, әсәрләрне фоторәсемгә төшерәләр, шәхси һәм дәүләт архивларында, төрле фондларда, Татарстанның гына түгел, төбәк китапханәләрендә дә материаллар эзләү белән шөгыльләнәләр.

«Татар энциклопедиясе» кебек фундаменталь хезмәт гыйльми әйләнешкә кертелгәннән соң, күп кенә сәнгать тарихчылары һәм сәнгать белгечләренең тикшеренүчеләр игътибарыннан читтә калуы аеруча ачык күренә. Реставраторлар эшчәнлеге анда бөтенләй диярлек яктыртылмаган. Бүлектә бу юнәлешне сәнгать фәннәре кандидаты-И.Ф. Лобашева алып бара.

Бүгенге көндә материал шулкадәр күп җыелды, аны тулысынча энциклопедиягә кертү мөмкин түгел. Шуңа күрә сәнгать жанрлары һәм төрләре (персоналияләр) буенча серияләр чыгарырга булдык. Аерым алганда, И.Ф. Лобашева «Искусствоведы Татарстана» дигән сериянең беренче китабын әзерләде. Ул XX гасырда Россия һәм Татарстанның күренекле сәнгать белгече, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеен төзү инициаторы һәм аның беренче директоры Г.А. Могильниковага (1928–2001) багышланган (тууына 90 ел тулу уңаеннан).

Бу юнәлештә О.А. Гыйльметдинова Татарстанның фәнни һәм Н.И. Фешин исем. Казан сәнгать училищесы архивларында

«Художники-педагоги КХШ/КХУ им. Н.И. Фешина» дип аталган бүлек өчен рәссам-педагоглар турындагы яңа материалларны ачыклау буенча зур эш башкарды.

Бүлектә яңа фәнни серияләр чыгару өстендә дә эшли башладык. Аңа Татарстандагы, Россия, якын һәм ерак чит илләрдәге фәнни-тикшеренү учреждениеләре галимнәре дә җәлеп ителә. «Искусство тюркского мира» сериясендә «Истоки и эволюция художественной культуры тюркских народов» (Казань, 2008) һәм «Искусство войлока в тюркском мире: история и современность» (2009) томнары басылып чыкты инде. Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты һәм Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты белән берлектә эшләнгән «История татарского искусства» сериясендә нәшер ителәчәк «Художественная культура и искусство ранних булгар и Волжской Булгарии VIII–XIII веков» дип исемләнгән 1 том басмага әзер. Сәнгать белгечләре ассоциациясе һәм ТР Мәдәният министрлыгы ярдәме белән бүлек чыгарган «Искусствоведение Татарстана» альманахы (2017) Татарстандагы хәзерге сәнгать тормышының иң мөһим аспектларын чагылдыра, сәнгать фәннәренең офыкларын киңәйтә – төрле методологик якын килүләрне, фәнара тикшеренүләрнең перспективалы булуын күрсәтә, танылган һәм яшь талантлы сәнгать белгечләренең яңа хезмәтләре белән таныштыра.

Бүлек эшчәнлегенең мөһим бер өлеше – күргәзмәләр оештыру. Бу эшчәнлек республика тасвирый сәнгатендә барган процессларны өйрәнергә һәм үз вакытында тәнкыйди бәяләргә булыша. Бүлек алдындагы төп бурычларның берсе – милли үзгәлекне, төбәк үзенчәлекләрен чагылдырган приоритетлы юнәлешләрне билгеләү, Татарстан сынлы сәнгате казанышларын республиканың үзендә дә, аннан читтә дә күрсәтү – берничә сәнгати проектта уңышлы гамәлгә ашырылды: ТР Милли музеенда «Татарстанның китап сәнгате» I республика күргәзмәсе (кураторлары Р.Р. Солтанова, О.Л. Улемнова); «Хәзинә» Милли галереясында «Хәзерге заман киез сәнгате» халыкара күргәзмәсе (2009). 2009 елның апрель – июнь айларында Көнчыгыш халыклары сәнгате дәүләт музеенда (Мәскәү) «Шәмаил сәнгате: сүз һәм образ» күргәзмәсендә беренче тапкыр гарәп графикалы сәнгатьнең татарлар өчен традицион төре үзенең тарихи үсешендә күрсәтелде. Ул ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ нең 70 еллык юбилее уңаеннан оештырылган иде. Л.М. Шкляева «Туган авыл. Родная деревня» дип аталган республика балалар рәсеме күргәзмәсе (2016), «Алтын кош. Золотая птица» Республика декоратив-гамәли сәнгать әсәрләре күргәзмәсе (2017) һ. б. инициаторларының һәм кураторларының берсе булды.

Бүлек мөдире Р.Р. Солтанова тарафыннан А.А. Бахрушин исем. Дәүләт үзәк театр сәнгате музеенда (Мәскәү) Татарстанның театр сәнгате казанышларын пропагандалау буенча зур сәнгать проектлары оештырылды һәм уңышлы гамәлгә ашырылды. «Татар театры тарихы плакат сәнгатендә» масштаблы күргәзмәсе (2016) татар театрының 110 еллыгына багышланды. Аның нәтиҗәсе буларак, шул исемдәге

китап рус, татар һәм инглиз телләрендә дөнья күрде. «Режиссер Марсель Сәлимҗанов театры» күргәзмәсе останың тууына 85 ел тулуга багышланып, Театр елында (2019) зур вакыйгага әверелде. Р.Р. Солтанова «Казан кремле» музей-тыюлыгында узган «Мелодия камня» («Таш моңы») дигән скульптура буенча халыкара симпозиумның да кураторы булды. Әлеге чараның рус, татар, инглиз телләрендә каталогын чыгарды.

Бүлектә аспирантура эшли. Соңгы елларда Р.Р. Солтанова җитәкчелегендә сәнгать фәннәре кандидаты гыйльми дәрәҗәсен алу өчен диссертацияләр якланды: Улемнова О.Л. («1920–30 елларда Татарстанның графика сәнгате» (2005, Мәскәү); Кривошееева Т.Н. («Татарстанда скульптура: башлангычы, үсүе, традицияләре» (Мәскәү, 2010); Донина Л.Н. («Театрда татар костюмы: интерпретация һәм реконструкция мәсьәләләре» (Мәскәү, 2010); Хисамова Д.Д. («XX гасыр – XXI гасыр башы Татарстан монументаль скульптурасындагы сәнгати процесслар» (Мәскәү, 2012); Ваһапова Ф.Г. («XVII гасыр – XX гасыр башы татар кулъязма һәм басма китабы сәнгате үсеше: стилистика һәм символика» (Саранск, 2015); Шкляева Л.М. («XX гасыр уртасы – XXI гасырда Урта Идел буе татарларында агачка кисеп бизәк ясау сәнгате: семантикасы һәм стиль үзенчәлекләре» (Саранск, 2017).

Бүлек Россия сәнгать академиясенең Тасвирый сәнгатьләр теориясе һәм тарихы фәнни-тикшеренү институты (Мәскәү), С.Г. Строганов исем. Мәскәү дәүләт сәнгать-сәнәгать академиясе, Дәүләт сәнгать белеме институты (Мәскәү), РФА нең Н.Н. Миклухо-Маклай исем. этнология һәм антропология институты, төрки дөнья (Азәрбайҗан, Үзбәкстан, Казакъстан, Башкортстан, Алтай Республикасы, Төркия) белән тыгыз бәйләнеш тота.

«Татар халкының милли бердәйлеген саклау» Дәүләт программасы кысаларында хезмәткәрләрнең илебезнең төрле төбәкләренә экспедицияләргә чыгуы татар осталары иҗатының төрле төрләрен (чигү, туку, агачка кисеп бизәк ясау, зәркәнчелек), хәзерге этапта татар халкының матди культурасын өйрәнү мөмкинлекләрен арттырды. Экспедиция нәтиҗәләре буенча «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» фәнни-популяр сериясендә чыккан китапларның аерым бүлекләре сәнгать белгечләре тарафыннан язылды.

Бүлек хезмәткәрләре сынлы сәнгать казанышларын Татарстанда гына түгел, Россиянең башка төбәкләрендә һәм чит илләрдә дә (Мари Эл, Ингушетия, Испания, Польша, Азәрбайҗан, Үзбәкстан, Казакъстан, Грузия) актив пропагандалыйлар, төрле дәрәҗәдәге конференция һәм семинарларда чыгышлар ясыйлар.

Бүлек хезмәткәрләре зур иҗтимагый эш алып баралар һәм экспертлар буларак чыгыш ясыйлар («Хәзерге заман мәдәни киңлегендә театр музее» V Бөтенроссия семинары, проектның кураторы Р.Р. Солтанова, май, 2018; «Казан штрих-коды» халыкара иҗат остаханәсе, проектның сокураторы О.Л. Улемнова, август, 2018).

Р.Р. Солтанова – «Тантана» республика конкурсының жюри әгъзасы, ТР Мәдәният министрлыгы грантларын тапшыру буенча тәнкыйтьчеләр коллегиясе һәм экспертлар советы әгъзасы; Р.Р. Солтанова һәм О.Л. Улемнова – ТР Мәдәният министрлыгы каршындагы Сәнгать-экспертлар советы әгъзалары һ. б.

Бүлек хезмәткәрләре һәм аспирантлар Республиканың югары уку йортларында һәм кадрларның квалификациясе күтәрү учреждениеләрендә педагогик эшчәнлек тә алып баралар.

Бүлек Сәнгать белгечләре ассоциациясе (АИС) белән уртак проектларны да гамәлгә ашыра. Бүлекнең сәнгать белгечләренә кагылышлы фәнни, иҗади һәм социаль мәсьәләләр АИС ның Татарстан бүлеге булышлыгында хәл ителә.

Тулаем алганда, бүлек хезмәткәрләренең эшчәнлеге милли-төбәк сәнгате феноменын өйрәнүгә багышлана. Соңгы елларда тикшеренүләрдә яңа аспектлар да эшкә җигелде. Бу – XX гасыр ахырында мәдәният тибы, сәнгати фикерләү тибы кебек категорияләрдән башка мөмкин булмаган киң масштаблы гомумиләштерүләр дәрәҗәсенә килгән сәнгать белеменең яңа бурычлары һәм ихтыяҗлары белән аңлатыла. Шулай ук үзаң, үзтәңгәллек мәсьәләләре көннән-көн әһәмиятлерәк була барган хәзерге заманның (шул исәптән күпмилләтле Татарстанның) гаять катлаулы рухи үсеш процесслары да исәпкә алына.

***Солтанова Рауза Рифкать кызы,***
*сәнгать фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге мөдире*

УДК 001.32

*Р.В. Шәйдуллин*

# ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ ҺӘМ ТӨБӘКНЕ ӨЙРӘНҮ ИНСТИТУТЫ ТАРИХЫ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Статья посвящается Институту татарской энциклопедии и регионоведения Академии наук Республики Татарстан, в которой рассматриваются основные законодательные акты Татарстана, сыгравшие важную роль в становлении и развитии Института. Особое внимание уделяется начальному этапу развития татарской энциклопедистики, многогранной деятельности первого директора Института М.Х. Хасанова, а также рассмотрению многолетней научно-издательской работы институтского коллектива и его научной продукции. Кроме того, вкратце анализируется процесс совершенствования и обогащения словников многотомной Татарской энциклопедии на татарском и русском языках.

**Ключевые слова:** Республика Татарстан, республиканские законодательные акты, отдел Татарской Советской Энциклопедии при Институте языка, литературы и истории, Институт Татарской энциклопедии и регионоведения Академии наук Республики Татарстан, словники, многотомная Татарская энциклопедия, энциклопедические и научно-справочные издания, М.Х. Хасанов – первый директор Института.

The article is devoted to the Institute of the Tatar Encyclopedia and Regional Studies of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, which examines the main legislative acts of Tatarstan, which played an important role in the establishment and development of the Institute. Particular attention is paid to the initial stage of the development of Tatar encyclopedics, the multifaceted activities of the first director of the Institute M.Kh. Khasanov, as well as consideration of the many years of scientific publishing activities of the institute team and its research products. In addition, the process of improving and enriching the vocabularies of the multi-volume Tatar encyclopedia in the Tatar and Russian languages is briefly analyzed.

**Key words:** Republic of Tatarstan, republican legislative acts, department of the Tatar Soviet Encyclopedia at the Institute of Language, Literature and History, Institute of the Tatar Encyclopedia and Regional Studies of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, dictionaries, multivolume Tatar Encyclopedia, encyclopedic and reference books, M.Kh. Khasanov is the first director of the Institute.

Быел 2019 елның 3 маенда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты оешуга 25 ел тулды. Бүгенге көндә әлеге институт Бәйсез Дәүләтләр Берлегендә бердәнбер дип икърар итә алабыз. Хәер, 2004 елдан Украина Милли фәннәр академиясе карамагында булдырылган Энциклопедик тикшеренүләр институты да эшли. 2019 елның мартына илебезнең 80 республикасында һәм өлкәсендә 818 басма һәм электрон төбәк энциклопедияләре, энциклопедистик белешмәлекләр дөнья күрде, шуларның 321 берәмлеге (ягъни 39,2 проценты) Россия Федерциясе субъектларына багышланган. Әлеге исәпкә Татар энциклопедиясе

һәм төбәкне өйрәнү институты коллективы тарафыннан әзерләнгән өч дистә чамасы энциклопедик һәм фәнни-белешмәлек басмалар да керә. Хәзерге вакытта институт – Татарстанда һәм Россиядә төрле типтагы энциклопедияләрнең фәнни һәм методик нигезләре эшләнгән әйдәп баручы фәнни-тикшеренү учреждениесе, анда энциклопедияләргә профессиональ экспертиза уздырыла, шулай ук илебездәге энциклопедия эшенең үсеше мәсьәләләре өйрәнелә. Институтның фәнни хезмәткәрләре төрле энциклопедистик басмалар өчен фәнни концепцияләр эшлиләр, материалны бәян итү принципларын, аны сайлап алу критерийларын, энциклопедия мәкаләсен әзерләүнең һәм аны мәгълүматлар белән баетуның, иллюстратив һәм библиографик яктан тәэмин итүнең методик нигезләрен билгелиләр.

Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты Татарстан АССР Министрлар Советының 1989 елның 6 сентябрендә чыгарылган «Татар Совет Энциклопедиясен әзерләү һәм нәшер итү турында» карары (№ 339) нигезендә 1990 ел башында СССР ФА Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты каршында оештырылган Татар Совет Энциклопедиясе бүлегеннән башлангыч ала. Документ ТАССР Министрлар Советы рәисе, Татарстан Республикасының булачак Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев тарафыннан имзалана. Карарның преамбуласы түбәндәгеләрдән гыйбарәт: «Киң җәмәгатьчелек теләкләрен исәпкә алып, КПСС өлкә комитеты бюросының 1989 елның 14 марты карары белән расланган республика максатчыл комплекслы «Мирас» программасын башкару һәм хезмәт ияләрен интернациональ һәм патриотик рухта тәрбияләү максатында Татарстан АССР Министрлар Советы карар бирә: СССР ФАнең Казан филиалы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының, В.И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының, ТАССРның Нәшриятлар эшләре, полиграфиия һәм китап сәүдәсе буенча дәүләт комитетының 1989–2000 елларда күп томлы Татар Совет Энциклопедиясен (татар һәм рус телләрендә) әзерләү һәм бастыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә». Хөкүмәт документында «Татар Совет Энциклопедиясен әзерләү буенча барлык гамәли эшне СССР ФАнең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында тупларга һәм энциклопедияне төзү буенча фәнни-оештыру эшләрен башкару өчен институт җитәкчелегенә (ип. Зәкиев М.З.) 1989 елның декабренә кадәр Фәнни үзәк булдыруны йөкләргә, Фәнни үзәк составын, раслау өчен, Татар Совет Энциклопедиясенең фәнни-оештыру советына чыгарырга» тәкъдим ителә. Карарның әлеге нигезләмәсе белән структура бүлеге Тел, әдәбият һәм тарих институты составында мөстәкыйль Фәнни үзәк рәвешендә раслана. Бер үк вакытта СССР Социаль-торак банкының Татарстан республика идарәсе рәисе Л.И. Китайцевага «СССР ФАнең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы Татар Совет Энциклопедиясе фәнни үзәгенә ТАССРның объектлары, эшчеләре, җитештерелүче продукцияләре һәм товарлары

турындагы мәгълүматларның энциклопедиягә кертелүенә кызыксынулы предприятиеләреннән, оешмаларыннан һәм учреждениеләреннән, министрлыкларыннан һәм ведомстволарыннан, шулай ук аерым совет һәм чит ил гражданнарыннан акча күчерү өчен Фәнни үзәкнең махсус хисабын ачарга» йөкләмә бирелә.

Шулай итеп, Тел, әдәбият һәм тарих институты составында хуҗалык исәбендәге Татар Совет Энциклопедиясе фәнни үзәген оештырырга тәкъдим ителә, аның шәхси хисабына 3,18 миллион сум спонсорлар акчасын күчерү планлаштырыла. Бүлек хисабына күпме акча керүе билгеле түгел. Әмма ул чорда СССР Премьер-министры булган В.С. Павловның 50 һәм 100 сумлык кәгазь акчаларны җыеп алуы белән бәйле рәвештә, 1991 елның 2 апреленнән төп куллану товарларына һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләрнең 2–3 тапкыр күтәрелүен гамәлгә керткән реформалар коллектив хезмәткәрләренең финанс хәлен гаять катлауландыра. Карарда спонсорлар буларак күрсәтелгән кайбер предприятиеләр авыр хәлгә калалар. Карар кабул ителгәннән соң ук, әлеге документның кайбер нигезләмәләре шик уята. Нәтиҗәдә Татар Совет Энциклопедиясенең фәнни үзәген төзү тоткарлана, чөнки күп кенә предприятие һәм оешмаларның җитәкчеләре үзләре өчен аңлаешлы булмаган ниндидер фәнни-тикшеренү учреждениесенең эшчәнлеген финансларга атлыгып тормыйлар. Күпләргә энциклопедия бурычларын Татарстан галимнәре яңа институттан гайре дә башкарып чыгарлар кебек тоела. Спонсорлар да әлеге күркәм эшкә акча күчерергәме-юкмы дип озак уйланалар. Моннан тыш, илдә һәм республикада социаль-икътисади вазгыять торган саен катлаулана, инфляция һәм кыйммәтчелек предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең акча тупламаларын йота бара. Җитәкчеләр-спонсорлар белән кабат-кабат сөйләшүләрдән соң, Үзәк хисабында беркадәр акча җыела.

Әлбәттә, болар барысы да тулы куәтле Татар Совет Энциклопедиясе фәнни үзәген булдыру юлында комачаулыклар тудыра, аның урынына спонсорлар, өлешчә институт исәбенә финансланучы кечерәк кенә Татар Совет Энциклопедиясе бүлеге төзелә. Үзәкне оештыруда туган кыенлыкларның тагын берсе ике телдә иркен сөйләшкән кадрларны туплаудан гыйбарәт була. Үзәкнең хуҗалык исәбендә эшләве дә күпләрне сагайта, чөнки 1980–1990 еллар чигендә хөкем сөргән катлаулы социаль-икътисади шартларда әллә ни мул булмаган спонсор акчалар килү дә тукталырга мөмкин иде. Зур авырлык белән Татар Совет Энциклопедиясе бүлеге өчен кирәкле күләмдә хезмәткәрләр җыела, аларның күпчелеген фәнни-тикшеренү тәҗрибәсе булмаган яшь белгечләр тәшкил итә. 1992 елның мартында бүлек составында 14 штат берәмлеге исәпләнә. Аның мөдире итеп Ф.С. Хәкимҗанов билгеләнә. Коллективның тәүге составында 4 кеше генә гыйльми дәрәҗәләргә ия була: филология фәннәре кандидаты Ф.С. Хәкимҗанов, өлкән фәнни хезмәткәр, тарих фәннәре кандидаты Г.К. Вайда, өлкән фәнни хезмәткәр, философия фәннәре кандидаты Р.М. Мөхәммәтшин, фәнни хезмәткәр, тарих фәннәре кандидаты

Р.В. Шәйдуллин. Әлеге составтан бүгенге көндә институтта өч кенә кеше эшли: тарих фәннәре докторы, профессор, энциклопедистика үзәге мөдире Р.В. Шәйдуллин, фәнни хезмәткәрләр Г.М. Габделхакова һәм Л.М. Сәхавова.

Татар Совет Энциклопедиясе бүлеге хезмәткәрләре өчен Тел, әдәбият һәм тарих институты җитәкчелеге (директор М.З. Зәкиев) тарафыннан кечерәк кенә бүлмә бирелә, анда компьютер, булачак энциклопедия лөгатьлегенә керәчәк шәхесләрнең фамилияләре, терминнар һәм төшенчәләр язылган карточкалардан тупланган каталог урнаштырыла. Чынлыкта әлеге бүлмә компьютерчы Резеда Габитованың һәм бүлек мөдире Фәрит Хәкимҗановның эш урыны иде. Резеда компьютерда лөгатьлек материалларын һәм мәкаләләрне туплады. Еш кына бу эшкә бүлек мөдире үзе дә тартылды, кичләрен материалларны җыю һәм системалаштыру белән шөгыльләнде. Бүлек хезмәткәрләре картотеканы яңа «кара сүзләр» белән баеттылар. Башта бүлекнең офисы Бауман урамында, К. Якуб исемендәге полиграфия комбинатының Г. Тукай клубында, 1991 елның июленнән Ленин урамында, Тел, әдәбият һәм тарих институтының бер бүлмәсендә, 1992 ел башыннан Бауман урамында – 1991 елның октябрендә оештырылган Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе бинасында урнашты. Кыска гына вакыт эчендә Институт коллективы берничә тапкыр күченде.

Кыенлыкларга карамастан, ике ел эчендә Татар Совет Энциклопедиясе бүлеге тарафыннан «Татар Совет Энциклопедиясе» фәнни концепциясенең беренче варианты эшләнде һәм аның нигезендә татар телендә 11 меңләп терминны, төшенчәне һәм шәхесләр исемлеген колачлаган беренче Генераль лөгатьлек әзерләнде һәм рус телендә беркадәр Татар энциклопедиясе сүзлеге өчен мәкаләләр язылды. 1991 елда СССР таркалганнан соң, «Татар Совет Энциклопедиясе» концепциясенең фәнни нигезе тамырдан үзгәрде. Нәтиҗәдә хезмәт басылмыйча калды. Тупланган материаллар киләчәктә «Татар энциклопедия сүзлеге» һәм күп томлы «Татар энциклопедиясе»нең нигезен тәшкил итте.

1992 елның 3 мартында Татар Совет Энциклопедиясе бүлеге РФА Казан фәнни үзәгенең Тел, әдәбият һәм тарих институтыннан ике сектордан (мөдирләре Г.К. Вайда, Ф.С. Хәкимҗанов) торган Татар энциклопедиясе бүлеге буларак яңа оештырылган Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә тапшырыла. Бүлекнең башлыгы итеп элек Казан мәдәният институтында эшләгән тарих фәннәре кандидаты Г.С. Сабирҗанов билгеләнә. ТР Министрлар Кабинетының 1993 ел 15 февраль «Татарстан Республикасының күптомлы Татар энциклопедиясен һәм энциклопедик белешмәлекләр әзерләү һәм нәшер итү турындагы дәүләт программасы турында», 1994 ел 3 май «Күптомлы Татар энциклопедиясен әзерләү һәм нәшер итү буенча өстәмә чаралар турында» карарлары нигезендә, «Татар энциклопедиясе»н эшләүне һәм бастыруны тизләтү өчен, Татар энциклопедиясе бүлеге җирлегендә мөстәкыйль фәнни-тикшеренү учреждениесе –

Татар энциклопедиясе институты (2014 елдан Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты) оештырыла. Институт Татарстан Республикасының фәнни-тикшеренү учреждениеләре дәүләт реестрына кертелә, юридик зат хокукы ала, финанс операцияләре башкару өчен, ТР Милли банкында аның үз хисабы ачыла.

ТР Президенты М.Ш.Шәймиевнең 1997 ел 10 февраль «Татар энциклопедиясе» программасы турында һәм Татар энциклопедиясенең баш мөхәррире турында нигезләмә» Указы, ТР Министрлар Кабинетының 1997 ел 4 май «1997–2004 елларга Татарстан Республикасының «Татар энциклопедиясе» программасын раслау турында» карары күптомлы «Татар энциклопедиясе» программасын законлаштыру җәһәтендә һәм матди яктан ныгыта, шул рәвешчә рус һәм татар телләрендә «Татар энциклопедия сүзлеге»н һәм күптомлы «Татар энциклопедиясе»н эшләү һәм нәшер итү өчен зарури шартлар тудыра. 1997 елга кергәндә Институт фәнни-тикшеренү һәм нәшрият учреждениесе буларак формалашып бетә.

Бу вакытка анда кадрлар мәсьәләсе дә хәл ителә, агымдагы һәм перспективадагы планнар раслана. 1998 елда, Татарстан җитәкчелеге карары белән, Институтка Пушкин урамындагы бина – Казан сәнәгатьчеләре һәм сәүдәгәрләре Крестовниковларның XIX гасырның икенче яртысында төзелгән йорты бирелә. 1999 елның февралендә, капиталь ремонттан соң, учреждениенең аңарчы төрле җирләрдә таралып эшләгән хезмәткәрләре бер түбә астында туплана. 2012–2016 елларда ТР Президенты Р.Н. Миңнеханов ярдәме белән Институт бинасында яңа капиталь ремонт уздырыла, 2017 ел башында коллектив үз эш урыннарына кайтып урнаша.

Озак еллар дәвамында Институт белән филология фәннәре докторы, ТР ФА академигы Мансур Хәсән улы Хәсәнов җитәкчелек итте. Бер үк вакытта ул ТР Министрлар Кабинеты рәисенең беренче урынбасары (1992 елга кадәр) һәм ТР Фәннәр академиясе президенты (2006 елга кадәр) вазифаларын да башкарды. Институт директоры вазифасында Мансур Хәсән улы 15 ел (2010 елның 13 мартына кадәр) хезмәт куйды. Татарстан АССР Министрлар Советы рәисенең беренче урынбасары буларак, татар җәмәгатьчелегенең Татар Совет Энциклопедиясе төзү турындагы фикерен хуплап күтәреп алуы белән ул зур ихтирамга лаек. Аның зур тырышлыгы аркасында Татарстан АССР Министрлар Советының «Татар Совет Энциклопедиясе»н әзерләү һәм бастырып чыгару турында» 1989 ел 6 сентябрь карары кабул ителде. Татар энциклопедиясе аның баласы кебек булды. Эшләре бик тыгыз булуга да карамастан, Мансур Хәсән улы Институтның оештыру-хуҗалык һәм фәнни-нәшер итү проблемаларын хәл итүгә генә түгел, Татар энциклопедиясенең фәнни концепциясен эшләүгә һәм текстларның эчтәлеген билгеләүгә дә вакыт тапты. Күп еллар дәвамында (1994–2011) аның беренче урынбасары булып Г.С. Сабирҗанов эшләде. М.Х. Хәсәновның оста җитәкчелек итүе нәтиҗәсендә

һәм Г.С. Сабирҗановның, шулай ук төп бүлекләрнең мөдирләре Р.М. Мөхәммәтшин, Р.В. Шәйдуллин, Р.Г. Усманов, Ф.С. Зыятдинов, А.Г. Яруллина, Г.Е. Трифонов, Т.П. Ключевская, Р.Р. Сәләхиев, Н.Г. Кадошникова, Р.Р. Мусабекованың актив катнашында кыска вакыт эчендә эшкә сәләтле фәнни-тикшеренү институты оештырылды.

Институтны булдыруга куелган хезмәт, аның матди һәм кадрлар мәсьәләләрен хәл итү озакламый үз җимешләрен бирде. 1994–1997 елларда «Татар энциклопедиясе»нең рус һәм татар телләрендә беренче лөгатьлекләре дөнья күрде. Лөгатьлек материаллары рус телендә «Татар энциклопедия сүзлеге»н («Татарский энциклопедический словарь») эшләү һәм бастыру өчен нигез булды, әлеге басма (16 меңләп «кара сүз») 30 мең данә тираж белән 1999 елда Лондонда нәшер ителде. 2002 елда 7 меңлек тираж белән татар телендә басылган сүзлектә «кара сүзләр»нең исәбе 17 меңгә җитә. Рус һәм татар телләрендәге генераль лөгатьлекләрне камилләштерү юнәлешендә күп еллар дәвамында алып барылган эш нәтиҗәсендә, Институт коллективы «Татар энциклопедия сүзлеге» нең һәм күптомлы «Татар энциклопедиясе»нең үзенчәлекле модель структурасын эшләү һәм әлеге энциклопедик басмаларга фундаментальлек, фәннилек, системалылык һәм комплекслылык сыйфатларын бирү югарылыгына иреште. Институт башлангычында 1997 елның 20 гыйнварында «Татар алфавитын тәртипкә китерү турында» Законы чыга, аның нигезендә өстәмә хәрефләрнең урыннары үзгәртелә: А хәреферннән соң – Ә, О дан соң – Ө, У дан соң – Ү, Ж дан соң – Җ, Н дан соң – ң, Х дан соң – Һ хәрефе урнаша. Татар телендәге энциклопедик басмаларда мәкаләләр яңа татар алфавиты тәртибендә урын ала. Татар телендәге лөгатьлекне эшләгәндә, фәнни терминнарны һәм төшенчәләрне руслаштырудан арындыру, системалаштыру һәм транслитерация, географик объектларның (таулар, елгалар, күлләрнең һ.б), хайваннарның һәм үсемлекләрнең, шулай ук торак пунктларның атамаларын тәртипкә салу буенча зур лексикологик эш башкарыла.

Рус һәм татар телләрендә дөнья күргән энциклопедик басмалар Татарстандагы киң җәмәгатьчелекнең милли-төбәк энциклопедияләренең белемнәрнең төрле тармакларына, Татарстанның икътисади, хуҗалык һәм мәдәни тормышына, шулай ук Евразиянең гаять зур киңлекләрендә сибелеп яшәгән 6 миллионлы татар халкына нисбәтле материалларны системалау һәм фәнни гомумиләштерү мөмкинлекләре турындагы карашларын тамырдан үзгәртте. Яңа фәнни-методологик алымнар һәм ысуллар, милли-төбәк кысаларындагы бурычлар яссылыгында «Татар энциклопедиясе»нең лөгатьлеге даими рәвештә актуальләштерелде, камилләштерелде, яңартылды һәм тулыландырылды. Нәтиҗәдә, рус телендәге 6 томлык «Татар энциклопедиясе»ндә (2002–2014) «кара сүзләр» исәбе 20 меңлек күрсәткечкә кадәр артты. Лөгатьлекне яңа терминнар, төшенчәләр һәм персоналияләр белән тулыландыру, шулай ук энциклопедик басмаларны актуальләштерү процессы даими үзенчәлеккә ия. Татар телен-

дәге 7 томлык «Татар энциклопедиясе»ндә (2008–2019) лөгатьлек исәбе 21 мең «кара сүз»гә җитте.

Әлеге күптомлы Татар энциклопедияләре – татар халкының һәм Татарстанның иң борынгы заманнардан безнең көннәргәчә тормышын һәм этрафлы образын дөрес һәм күпьяклы чагылдыручы тәүге универсаль милли-төбәк басмалары. Кызганычка каршы, Татар энциклопедиясенең татар телендәге томнарының тиражлары, рус телендәге томнардан (5 әр мең данә) аермалы буларак, бик кечкенә: 1–4 томнарның тиражы 2 шәр мең, 5 том – 500, 6 том – 1 мең данә.

Рус һәм татар телләрендәге Татар энциклопедия сүзлегеннән һәм күптомлы Татар энциклопедиясеннән гайре, Институт тарафыннан бик күп исемдәге басмалар дөньяга чыгарылды, алар арасында төбәк энциклопедияләре һәм фәнни белешмәлекләр «Татарстан: иллюстрацияле энциклопедия» («Татарстан: иллюстрированная энциклопедия», 2013), «Татарстан: кыскача иллюстрацияле энциклопедия» («Татарстан: краткая иллюстрированная энциклопедия», 2015), Татарстан Республикасының табигате һәм табигый байлыклары: иллюстрацияле энциклопедия» («Природа и природные ресурсы Республики Татарстан: иллюстрированная энциклопедия», 2017), «Әдәби Чистай. Энциклопедия» («Чистополь литературный. Энциклопедия», 2017), «Татарстан Республикасының торак пунктлары: иллюстрацияле энциклопедия», 1 т. («Населенные пункты Республики Татарстан: иллюстрированная энциклопедия», т. 1, 2018), «Татарстан Республикасының юкка чыккан торак пунктлары: белешмәлек» («Исчезнувшие населенные пункты Республики Татарстан: справочник», 2016), «Татарстан Республикасы: массачыл мәгълүмат чаралары өчен энциклопедик белешмәлек» («Республика Татарстан: энциклопедический справочник для средств массовой информации», 2016) аерым әһәмияткә ия.

Институт коллективы тарафыннан татарлар тупланып яшәгән урыннарны өйрәнү буенча зур эш алып барыла. Соңгы бишьеллыкта «Казакъстан татарлары: энциклопедик белешмәлек» («Татары Казахстана: энциклопедический справочник», 2016), «Казакъстан татарлары: кыскача иллюстрацияле энциклопедия» («Татары Казахстана: краткая иллюстрированная энциклопедия», 2017), «Россия Федерациясендә татарлар тупланып яшәгән төбәкләр: белешмәлек» («Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации: справочник», 2016), «Урта Идел буенда татарлар тупланып яшәгән җирләрдә татар авылы: тарих һәм хәзерге чор: фәнни белешмәлек» («Татарская деревня в местах компактного проживания татар в Среднем Поволжье: история и современность: научный справочник», 2017) басмалары дөнья күрде.

Институт эшчәнлегендә Татарстанның социомәдәни тарихын популярлаштыру аерым урын алып тора. Соңгы унъеллыкта «Татарстан Республикасы: табигать, тарих, икътисад, мәдәният, фән: иллюстрацияле очерклар» («Республика Татарстан: природа, история, экономика,культура, наука: иллюстрированные очерки», 2010, 2015),

«Татарстанның үзәк дәүләт хакимияте һәм идарә органнары (1920–2010 еллар): фәнни белешмәлек басма» («Центральные органы государственной власти и управления Татарстана (1920–2010 гг.): научно-справочное издание», 2010, 2017), «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль символлары» («Государственные и муниципальные символы Республики Татарстан», 2017). Татарстан АССР оешуының 100 еллыгын (1920–2020) бәйрәм итүгә багышланган дәүләт программасы кысаларында басмага «Татарстанга – 100 ел» иллюстрацияле энциклопедик очерклар» («Татарстану – 100 лет: иллюстрированные энциклопедические очерки»), «Татарстанның сәясәт эшлеклеләре: биографик очерклар» («Политические деятели Татарстана: биографические очерки»), Татарстанның 100 еллыгына багышланган иллюстрацияле альбом әзерләнә. Кечерәк кенә бер мәкаләдә Институтның чирек гасыр эчендәге казанышларын санап чыгу мөмкин түгел, әлбәттә.

Энциклопедик басмаларны булдыручылар һәм аларның авторлары арасында – үз өлкәләрендә танылган абруйлы тикшеренүчеләр: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе институтларының әйдәп баручы белгечләре, Татарстан югары мәктәбе галимнәре, сәнгать белгечләре, төбәк тарихчылары, диаспораның фәнни вәкилләре, хуҗалык җитәкчеләре. Институтның үз фәнни юлларын энциклопедик басмалар булдыру кысаларында башлаган һәм, яңа ысулларга ирешеп, хөр фикерләү һәм тирән эрудициягә ия булулары белән танылган хезмәткәрләре аерым игътибарга лаек.

Институт коллективы милли энциклопедистика өлкәсендәге әлеге үрләргә Россия Федерациясе һәм Татарстан халыклары өчен милли-төбәк энциклопедияләренең мөһим булуын тану, Татарстан җитәкчелеге, аның беренче Президенты М.Ш. Шәймиев һәм икенче Президенты Р.Н. Миңнеханов тарафыннан даими игътибар һәм яклау табу нәтиҗәсендә ирешә алды. Алга таба исә бу Татар энциклопедиясенең иллюстрация-текст контентын, аудио һәм видео мәгълүмат рәвешендә «Татарика-2» онлайн энциклопедиясенең электрон форматына күчерергә мөмкинлек бирде.

Шулай итеп, 2019 елда Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының күпмилләтле җәмәгатьчелеге белән бергә ике юбилей датасын – татар һәм рус телләрендә Татар энциклопедиясен булдыру буенча беренче дәүләт программасы кабул ителүнең 30 еллыгын (ТАССР Министрлар Советының «Татар Совет Энциклопедиясен әзерләү һәм нәшер итү турында» 1989 ел 6 сентябрь карары) һәм ТР Министрлар Кабинетының «Күптомлы Татар энциклопедиясен әзерләү һәм нәшер итү буенча өстәмә чаралар турында» 1994 ел 3 май карары нигезендә Институт оешуның 25 еллыгын билгеләп уза.

***Шәйдуллин Рафаил Вәли улы,***
*тарих фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының энциклопедистика үзәге мөдире*

УДК 821.512.145, 82:801.6

*Н.М. Юсупова*

# ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕНЕҢ ФИКЕР ОФЫКЛАРЫН КИҢӘЙТҮ ЮЛЫНДА
## (танылган әдәбият белгече, академик Дания Заһидуллинаның юбилее уңаеннан)

В статье освещается научная деятельность доктора филологических наук, академика Дании Фатиховны Загидуллиной. В ней анализируется методология и методика изучения литературного процесса, определяются принципы и подходы к системному исследованию татарской литературы, выявляются оригинальность и своеобразие историко-литературной концепции ученого. В статье показано значение научных трудов Д.Ф. Загидуллиной для развития татарского литературоведения.
**Ключевые слова:** Дания Фатиховна Загидуллина, татарское литературоведение, научная деятельность, научная концепция.

The article highlights the scientific activities of the Doctor of Philology, Academician of Daniya Fatihovna Zagidullina. It analyzes the methodology and methodology of studying the literary process, defines the principles and approaches to the systematic study of Tatar literature, reveals the originality and originality of the scientist's historical and literary concept. The article shows the importance of the scientific works of D.F. Zagidullina for the development of Tatar literary criticism.
**Keywords**: Daniya Fatikhovna Zagidullina, tatar literary criticism, scientific activity, scientific concept.

Филология фәннәре докторы, профессор, академик, Татарстан Фәннәр академиясенең вице-президенты, тәнкыйтьче-галим Дания Фатих кызы Заһидуллина – татар әдәбият белемендә саллы фикерләре, хезмәтләре белән гыйльми офыкларны киңәйткән, шушы юлда үз фәнни мәктәбен булдырган галим.

Фән дөньясына Дания Заһидуллина 1990 елларда килә. 1989 елда филология фәннәре докторы, профессор Тәлгат Нәби улы Галиуллин җитәкчелегендә Мәскәү милли мәктәпләр институты каршындагы аспирантурага керә һәм максатчан төстә әдәбият укыту методикасы мәсьәләләре белән шөгыльләнә башлый. Казан дәүләт университетында татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультеты оешканнан соң, укуын әлеге факультет каршында ачылган аспирантурада дәвам итә. 1993 елда филология фәннәре докторы, профессор Т.Н. Галиуллин, педагогика фәннәре кандидаты, доцент К.Л. Биктаһиров җитәкчелегендә «Татар әдәбияты дәресләрендә лирик әсәрләр өйрәнгәндә укучыларга әхлакый-эстетик тәрбия бирү (V–VIII класслар)» дигән темага кандидатлык диссертациясен яклый. 2001 елда исә остазы Т.Н. Галиуллин җитәкчелегендә «Татар әдәбият нәзариясенең формалашу һәм үсеш этаплары (XX гасырның беренче чиреге)»

дигән темага докторлык диссертациясен уңышлы яклый, әдәбият белеме фәнендә абруйлы тикшеренүчеләрнең берсе, татар гуманитар фәнендә XX гасыр татар әдәбиятын диахрон һәм синхрон система буларак өйрәнеп, тулы бер күзаллау, шушы юлда үз концепциясен булдырган галим, узган гасыр башында иҗат ителгән бик күп әдәби ядкярләрне татар укучысына кайтарган текстолог, җәмәгать эшлеклесе булып өлгерә.

Дания Фатих кызы Заһидуллинаның фәнни эзләнүләре берничә юнәлешне колачлый: урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы, ФДББС шартларында әдәбият укыту методикасын камилләштерү, шушы юлда белем бирү оешмалары өчен яңа уку программалары әзерләү; татар укучысына әдәби-нәзари мирасны кайтару, әдәбият теориясенең тарихын өйрәнү; теоретик эзләнүләрне камилләштерү, дөнья әдәбият белемендәге фәнни-теоретик мәктәпләрнең казанышларын милли нәзари фикергә яраклаштырып куллану юлларын тәкъдим итү; XX йөз әдәбиятында барган модернистик мирасны өйрәнү, ике гасыр чигендәге «яңа» әдәбиятның үзара «диалогын» билгеләү; XX гасыр татар әдәбиятының үсеш-үзгәрешен өйрәнү концепциясен яңарту; әдәби тәнкыйть. Бер-берсенә бәйле, әмма һәркайсы мөстәкыйль үсешкә ия бу тармакларның бер галим эшчәнлегендә үрелеп китә алуы үзе үк аның киң фәнни масштабта фикерләү сәләтенә ия булуын ассызыклый.

Методик мәсьәләләр Дания Заһидуллинаның фәнни эшчәнлегендә үзәк урыннарның берсен тәшкил итә. Бу юлдагы эзләнүләрен ул рус педагогикасында барлыкка килгән яңа технологияләрне барлап, өйрәнеп, аларның уңышлы, отышлы саналганнарын милли әдәбиятны укыту өлкәсендә максатчан куллану юлларын эзләүдән башлый. Шул эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак «Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту» (2000, 2004) дәреслеге дөнья күрә. Әлеге хезмәтендә галимә татар әдәбиятын укыту методикасының тарихын барлый, бу тармакка үз өлешен керткән, методик мәсьәләләр белән шөгыльләнеп, эз калдырган методист-галимнәрнең эшчәнлеген күздән кичерә, яңалыгын билгели. Шуның белән янәшәдә әдәбият предметын укыту барышында кулланырга мөмкин булган яңа технологияләр, әдәбиятны тикшерү юллары һәм ысуллары хакында мәгълүматлар бирә, аларны куллану мөмкинлекләрен әдәби төрләр, жанрларга мөнәсәбәтле конкрет әсәрләргә анализлар мисалында ныгыта. Хезмәтнең теоретик һәм гамәли кыйммәте дә шунда.

Алга таба Дания Заһидуллина методик эшчәнлеген мәктәпләр, урта һәм югары уку йортлары өчен дәреслекләр, методик кулланмалар әзерләү юнәлешендә дәвам итә. Яңа гасыр башында ук тиз үзгәрешле заман таләпләре татар әдәбияты дәреслекләрен, аларның эчтәлеген үзгәртүне көн тәртибенә куя. Галимә бу таләпне тоеп ала, шул ук вакытта гамәлдәге программаларны, дәреслекләрне яңартуның дәвамлы һәм шактый катлаулы, четерекле эш икәнлеген дә аңлап, кулланмалар әзерләү эшенә керешә. Аның җитәкчелегендә эшләнеп,

укучыларның татар әдәбиятыннан белемнәрен системага салуга һәм тулыландыруга йөз тоткан «Татар әдәбияты. Теория. Тарих» (2004, Д. Заһидуллина, Ә. Закирҗанов, Т. Гыйләҗев), «Татар әдәбияты. Теория. Тарих. Тулыландырылган икенче басма» (2006, Д. Заһидуллина, Ә. Закирҗанов, Т. Гыйләҗев, Н. Йосыпова), «Әдәби әсәргә анализ ясау» (2005, Д. Заһидуллина, В. Әминева, М. Ибраһимов), «Татар әдәбияты: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге» (2007, Д. Заһидуллина, В. Әминева, М. Ибраһимов, Н. Йосыпова, Ә. Закирҗанов, Т. Гыйләҗев, Г. Гайнуллина) һ. б. хезмәтләр шул таләпләрне күз уңында тотып эшләнә. Бу хезмәтләрдә Д. Заһидуллинаның үзгә карашка нигезләнгән уку-укыту программаларына җирлек салына, концептуаль яңалыклар гамәлгә куела башлый. Аларда, укучыларның кызыксынуын, фән үсешен исәпкә алып, яңа терминнар турында мәгълүматлар бирелә, фәннилеге искергән, көн таләпләренә җавап бирми башлаган терминнар яңа атамалар белән алыштырыла, әдәби үсеш хакындагы гыйльми күзаллаулар киңәйтелә.

Белем бирү системасындагы үзгәрешләр, яңа технологияләр системасы барлыкка килү татар әдәбиятын укыту методикасын да федераль дәүләт белем бирү стандартлары (ФДББС) нигезендә камилләштерүне таләп итә, соңгы елларда Дания Заһидуллинаның методик эшчәнлеге ФДББС шартларында татар әдәбиятын укыту программалары эшләүгә йөз тота. Аның җитәкчелегендә һәм авторлыгында әзерләнгән әдәбият укыту программалары («Татар телендә белем бирүче мәгариф оешмалары өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа (Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова), 2011; «Татар телендә белем бирүче мәгариф оешмалары өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа (Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова, Ф.Ф. Хәсәнова), 2014) балаларны үз милләтенең вәкиле итеп тәрбияләүгә, аларда милли үзаң, дөньяга караш формалаштыруга, үстерүгә юнәлтелә, әдәбият укыту әсәрне укып чыгуга гына түгел, яшь буынга матди һәм рухи мәдәниятнең, татар менталитетының үзенчәлекләрен күрсәтүгә, милли үзбилгеләнүгә йөз тотарга тиеш дигән фикер тирәсенә җыела. Гуманитар белем бирү системасында татар әдәбиятын шәхеснең интеллектуаль һәм әхлакый-эстетик үсеш дәрәҗәсен билгеләүче төп предметларның берсе итеп күтәрә. Икенчедән, шушы юлда укучыларны әдәби мирасның иң камил әсәрләре, аерым язучылар иҗаты белән таныштырырга, аларны тикшерү-анализлау юлларын үзләштерергә; зур сүз осталары иҗатының яңалыгын дөрес аңларга, объектив нәтиҗәләр ясарга, мөнәсәбәт формалаштырырга өйрәтергә, балаларның психик һәм физик сәламәтлеген саклауны тәэмин итәргә омтыла. Өченче яктан, заман укучысын әдәбиятка тарту, аның аңларга-анализларга өйрәнү юлында, классика белән янәшәдә, хәзерге татар әдәбиятына игътибарны арттыра.

Д. Заһидуллинаның фәнни эзләнүләре татар әдәбият белеме үсешенә зур йогынты ясый, бу өлкәдә академик тикшеренүләрне тирәнәйтүгә йөз тота. 2000 еллар башында ул әдәби нәзариянең

формалашу, үсү үзенчәлеген билгеләгән, аны күпсанлы хезмәтләр, фәнни-тәнкыйди мәкаләләр нигезендә раслаган, шактый әдәби, тәнкыйди ядкярләрне фәнни әйләнешкә кайтарган әдәбиятчы булып танылa. Бу олы нәтиҗәнең чишмә башы, татар әдәбиятын мәктәпләрдә укыту методикасы мәсьәләләре белән бәйләп, 1917 елга кадәр эшләп килгән татар укыту системасы, мәктәп-мәдрәсәләрдә гамәлдә йөргән әдәбият дәреслекләре хакында мәгълүматлар туплауга барып тоташа. Нәкъ менә әлеге эзләнүләр аны татар әдәбият белемендә бөтенләй өйрәнелмәгән, алга таба фәнни эзләнүләренең төп магистраль юлын тәшкил итәчәк өлкәгә – әдәбият теориясеннән беренче дәреслекләр һәм татар әдәбият нәзариясенең формалашуын тикшерүгә алып килә, XX йөз башына – татар әдәбиятының алтын чорына – Д. Заһидуллина фәнни эзләнүләренең үзәгендә торачак дәвергә якынайта. Шул эзләнүләрнең беренче тәҗрибәсе булып «Әдәбият кануннары һәм заман» (2000) китабы һәм «Татар әдәбият нәзариясенең формалашу һәм үсеш этаплары (XX гасырның беренче чиреге)» дигән темага язылган докторлык диссертациясе (2001) аваз сала. Аларда әдәбият белеменең моңа кадәр киң катлам укучыга гына түгел, күп кенә филологларга да аз таныш сәхифәләренә игътибар юнәлтелеп, идеологик кысулар тәэсирендә тарих тузанына күмелгән әдәби-мәдәни бәйләнешләр, татар әдәби-фәлсәфи фикеренең гарби һәм шәркый бәйләнешләре татар укучысына тәкъдим ителә, беренче тапкыр әдәбият теориясе барлыкка килү һәм үсү юлы эзлекле өйрәнелә. Фәнни тикшерүләр Урта гасырдан башлап, XX йөз башы аша, шактый катлаулы, четерекле саналган, бер үк вакытта әдәбият белемендә шактый гына үзгәрешләр дә китергән 1920–1930 елларга кадәр җиткерелә.

Әлеге тикшеренү нәтиҗәләре XX йөз башында формалашкан әдәби-нәзари концепцияләрне, фәнни-тәнкыйди мәктәпләрне ачыкларга мөмкинлек бирә. Үз чиратында алар татарларда әдәбият теориясе, мөстәкыйль фән тармагы буларак, соңрак – совет чорында гына формалашкан дип калыплашкан карашны үзгәртүгә алып килә. Галимә XX йөз башында ук татарларның үз, рус, Европа әдәбият белеменнән аермалы, иҗади фикерләү юлы, мөстәкыйль нәзари фикере формалашуы, бу процессның инде XIX гасырда ук башлануы хакында әйтеп чыга: Урта гасырдан башлап, XIX гасырның ахырларына кадәрге вакыт милли нәзария тууга әзерлек чоры буларак аерып куела. XX гасыр башындагы әдәби-нәзари агымнар, аларның оешу тарихы, төп кануннары, милли асылы, йөз тоткан, таянган юнәлешләре ныклап өйрәнелә, җәмгыятьчеләр, рухиятчеләр мәктәпләренең һәм милли сүз сәнгатендәге яңа әдәби концепцияләрнең туу алшартлары барлана, аларның үзгәреш-яңарышы ачыклана. Әлеге эзләнүләр галимәгә шул чорда милли аң үсешенең дә югары биеклеккә ирешүен исбатлау мөмкинлеген бирә. Шуның белән янәшәдә аның тарафыннан Г. Сәгъди, Г. Баттал, Г. Ибраһимов, Н. Хәлфинның һ. б. әдәбият теориясенә кагылышлы моңа кадәр аз таныш хезмәтләре фәнни

әйләнешкә кертеп җибәрелә, алар Европа, рус әдәбиятчыларының карашлары, тәгълиматлары белән бәйләнештә тикшерелә, бу исә татарларда нәзария фәненең мөстәкыйль тармак буларак формалашуын ныклы исбатлауга, дәлилләүгә юл ача.

Татар нәзари фикере тарихын тирәнтен өйрәнү, XX йөз башы татар әдәбияты белән кызыксынып китү галимәгә киләчәк фәнни эзләнүләре өчен тагын бер өлкәне ачып җибәрә. Ул – моңа кадәр игътибардан читтә калган, идеологик максатлардан чыгып, махсус өйрәнелмәгән яки тискәре яктан гына бәяләнеп килгән, әмма искиткеч кызыклы һәм мавыктыргыч модернистик эзләнүләр. Нәтиҗәдә Дания Заһидуллина, әлегәчә үзенең тикшерүчесен көтеп яткан әдәби катламнарны актарып, «Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы» (2003) хезмәтен татар укучысына тәкъдим итә. Хезмәт «татар модернизмы» төшенчәсен нигезләве, аны теоретик нигезгә салуы, модернизмның рус һәм Европа әдәбиятыннан үзгә, милли төсмерләрен, аның татар әдәбиятында формалашкан төп агымнарын, аларның поэтик алымнарын, принципларын аерып чыгаруы, модернистик әсәрләрне өйрәнүнең милли концепциясен булдыруы белән әһәмиятле, актуаль. Галимә модернизмның милли сәнгатькә килеп керү юлларын аерып куя һәм мәдәни үсешнең татар милләте формалашу, татарларда иҗтимагый, фәлсәфи, сәяси күтәрелеш белән бәйле төстә баруын билгели. Әлеге тикшеренүләр моңа кадәр декадентлык исеме астында тискәре бәяләнеп килгән яңа күренешкә бөтенләй башка яссылыктан якын килү мөмкинлеген бирә, шушы юнәлештә яшәп килгән фикерләрне кире кагып, модернизмның татарлар өчен ят булмавын, хәтта гасыр башында әдипләр тарафыннан үз итеп, яратып кабул ителүен дәлилләргә мөмкинлек бирә. Шул рәвешле татар әдәбият белемендә бүгенгәчә ачык калган «бездә модернизм булганмы, үсешкә ирешә алганмы һәм, гомумән, «изм»нар кирәкме, аларсыз да әдәбиятны өйрәнеп булмыймы?» кебек сорауларга анык җавап бирелә.

Әмма бу эзләнүләрнең тагын бер әһәмиятле ягы була: модерн әдәбиятның фәлсәфи-эстетик нигезләрен билгеләгән әдәби материал татар матбугатында дөнья күргән тәнкыйди, публицистик, фәлсәфи, нәзари, агиографик язмалар, татар әдипләре, галим-фәлсәфәчеләренең фикерләре белән дәлилләп барыла. Биредә татар укучысы өчен билгесез саналган М. Хәнәфи, Ә. Тангатаров кебек авторлар мирасы, аерым алганда, М. Хәнәфинең «Айсылу», «Милләтем», Н. Гасрыйның «Гыйшкымның хәрабәләре», Ф. Әмирханның «Фәрештәләр җуатсыннар сине», Ай өстендә Зөһрә кыз», Г. Рәхимнең «Эч пошканда», «Хан мәчетендә», «Көзге хикәя», З. Нуркинның «Бәхет», Б. Мансурның «Татар егете», М. Гафуриның «Хан кызы Алтынчәч», Ә. Тангатаровның «Ташландык кабер» кебек өйрәнүдән читтә калган әдәби әсәрләре халыкка кайтарыла, татар әдәбиятының тарих тузанына күмелеп, күренми яткан әдәби мирасы, байлыгы яктыртыла, М. Хәнәфи, Ә. Хәсәни, Самат, Г. Газиз кебек тәнкыйтьчеләрнең моңарчы махсус өйрәнелмәгән мәкаләләре әдәби-гыйльми әйләнешкә

кертеп җибәрелә (гомумән, М. Хәнәфи, Ә. Тангатаров, Ә. Хәсәни исемнәрен Д. Заһидуллина кире кайтарды дисәк, һич тә арттыру булмас), аларның мирасына лаеклы бәя бирелә. Икенче яктан, бу хезмәт үз чорында татар әдәбият белемендә үзгә фәнни-тәнкыйди тикшеренү методикасын булдыру зарурлыгын да көн тәртибенә куя. Мондый омтылышның әдәбиятны яңача өйрәнү кирәклеге ачыкланган, әмма фәнни җәмәгатьчелекнең төгәл нәтиҗәләргә килә алмаган чорда ясалуы аның әһәмиятен, гыйльми кыйммәтен тагын да арттыра, авторының еракка карап эш итә алуын, глобаль фикерләүгә ия булуын тагын бер кат раслый.

Модернистик әдәбият белән кызыксыну Дания Заһидуллинаны фәлсәфи әсәрләр дөньясына алып керә. «Дөнья сурәте үзгәрү» (2006) хезмәте шул эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак дөнья күрә. Ул татар сүз сәнгатендә дөнья сурәтенең үзенчәлеген, аның трансформациясен тикшерү үзәгенә куйган беренче хезмәтләрдән була. Әлеге монографиясендә галимә Тарту-Мәскәү семиотик мәктәбе, аерым алганда Ю.М. Лотман тәкъдим иткән әдәби әсәргә структураль-семиотик анализ ясау юлларын татар материалында чарлый, шушы тәгълиматка таянып, XX йөз башы татар әдәбиятының үзәгендә торган дөнья сурәтенең мәгърифәтчел, трансценденталь, гыйсъяный һ. б. төрләрен аерып чыгара, Көнчыгыш һәм Европа фәлсәфи концепцияләренең татар әдипләре тарафыннан кулланылу үзенчәлеген билгели. Шуның нәтиҗәсендә ул XX йөз башы фәлсәфи әсәрләренә хас һәм теләсә кайсы фәлсәфи әсәрне бәяләүдә нигез хезмәтен үти алырлык берничә нәзари сыйфатны, тенденцияне аерып чыгара: автор позициясе әсәр структурасында урын алган дөнья сурәте аша төгәлләшә; дөнья сурәте әдәби әсәр төзелешенең нигезендә яткан бинар оппозицияләр нигезендә ачыла; шул юлда символлар үзәкне тәшкил итә; фәлсәфи әсәр күпкатламлы булу сәләтенә ия; татар фәлсәфи әдәбияты, Көнчыгыш һәм Көнбатыш фәлсәфи концепцияләрен бербөтенгә туплап, милли җирлеккә яраклаштырып трансформацияли – аның, һичшиксез, үз милли йөзе бар. Д. Заһидуллина соңгы еллар гуманитар фәнендә игътибар үзәгенә менгән суфичылыкның татар мәдәниятенә фикри йогынты ясаган күренеш кенә түгел, әдәби дөнья сурәтен билгеләгән, аны үзгәртү көченә ия булган төп агымнардан булуын исбатлый. Шәрык һәм Гареб әдәбиятыннан, нәзариясеннән тирән белемен файдаланып, нәзари фикерләрен шушы чорның күренекле авторлары Г. Тукай, Дәрдемәнд, С. Рәмиев, Н. Думави, Ш. Бабич, Ф. Әмирхан, Г. Исхакый, Ш. Камал, М. Хәнәфи, Ә. Тангатаров, М. Гафури кебек тулы бер плеяда әдипләрнең иҗатлары, аларның игътибардан читтәрәк кала килгән әсәрләре мисалында гамәли төгәлләштерә, шул рәвешле XX йөз башы милли сүз сәнгате хакында комплекслы күзаллау булдыра.

Соңрак дөнья күргән «Модернизм в татарской литературе первой трети XX века» (2013) хезмәтендә Д. Заһидуллина XX йөз башы әдәбият мәйданында алып барылган эзләнүләрнең 1920 елларга

кадәр үстерелеп, баетылып килүен исбатлый. Нәзари, фәлсәфи характердагы материал аша галимә татар әдәбиятын дөнья әдәбиятларына тоташтыра: классик булмаган мәдәниятнең татар әдәбиятында формалашу алшартларын барлый, үзгәреш-яңарышын ачыклый. Үз чиратында татар әдәбиятындагы модернистик эзләнүләр Европа, рус әдәбияты казанышлары белән бер үремтәдә тикшерелә, мондый масштаблылык татар сүз сәнгатен дөнья әдәбияты фонында карау, шул ук вакытта милли әдәбияттагы модернизмның асыл сыйфатларын, үзгә хасиятләрен төгәлләштерү мөмкинлеген бирә. Шуның нәтиҗәсендә Д. Заһидуллина 2003 елда тәкъдим иткән татар әдәбиятында модернизмның үзгә формасы, үзгә алымнары формалашуы хакындагы фикерен тирәнәйтә.

Татар әдәбиятының яңа катламнарын татар укучысына кайтару юнәлешендә Д. Заһидуллина әдәбият галиме генә түгел, текстолог буларак та танылып өлгерә. Фәнни эзләнүләре барышында Гали Рәхимнең (Гали Рәхим. Сайланма әсәрләр, 2004), Г. Сәгъдинең (Габдрахман Сәгъди: фәнни-биографик җыентык, 2008), Ә. Тангатаровның, Хәнәфинең, Ә. Хәсәнинең һ. б. тарих тузанына күмелгән әдәби-тәнкыйди, гыйльми мирасын бүгенге укучыга кайтаруга үзеннән зур өлеш кертә. Бу хезмәтләр 1930 елларда мәгълүм сәбәпләр нәтиҗәсендә өзелеп калган әдәби, гыйльми фикерләрне бүгенге карашлар белән ялгап җибәрә, урынсыз онытылган бу шәхесләрнең тормыш һәм иҗат биографиясен, мирасын алга таба бербөтен итеп өйрәнүгә юл күрсәтә, тәүге сукмакларны сала.

Нәзари фикер үсешен, XX йөз башы әдәбияты тарихын өйрәнеп, Д.Заһидуллина әдәбият белеме фәнендә XX йөз әдәби процессын тикшерерлек, аның олы тарихи һәм мәдәни потенциалын күңелдән уздырып, һәр күренешнең үз урынын билгеләрлек, аңа объектив якын килерлек гыйльми концепция табылмавы хакында нәтиҗәгә килә. XX йөз башы, 1920–1930 еллар татар әдәбият белемендәге гыйльми мирасны тирәнтен өйрәнеп, алардагы фикри казанышларны үстереп, алга таба шушы нигездә әдәбият тарихын өйрәнүдә үз концепциясен эшли башлый. Әдәбият белемендә барган позитив үзгәрешләр дә сүз сәнгате тарихын өйрәнүнең кыйбласын яңартуны, үткәннәрне бөтенләй сызып ташламый гына, әдәби-мәдәни мирасны тагын бер кат күз уңыннан үткәрүнең үзгә концепциясен тәкъдим итүне көн тәртибенә куя.

XX гасыр татар әдәбиятының төрле дәверләрен аерым аспектларда тикшерү-анализлау аша Д. Заһидуллина XX гасыр татар әдәбиятын бербөтен процесс буларак өйрәнүгә килә һәм милли сүз сәнгатенең, әлеге катлаулы, каршылыклы чорын бәяләүдә үз концепциясен тәкъдим итә. Узган гасыр татар әдәбиятының үсеш-үзгәреш тарихын өйрәнү объекты итеп алган «XX гасыр татар әдәбияты тарихы» (2011, Д. Заһидуллина, Н. Йосыпова) дәреслеге шушы юнәлештәге беренче комплекслы хезмәтләрдән була. Галимә татар әдәбият белемендә тәүге тапкыр XX гасыр сүз сәнгатенең милли нигезләргә, милли

традицияләргә таянып үсү-үзгәрүе хакындагы тәгълиматны гамәлгә куя, татар әдәбият белеме өчен стандарт булмаган мондый караш аңа совет чорында да сүз сәнгатенең үзгә сукмаклар салып, югары үсешкә ирешүен исбатларга юл ача. Нәтиҗәдә, XX гасыр татар әдәбиятының, югалтулар һәм табышлар аша булса да, XX йөз башында ирешелгәннәрне үстереп, баетып, «совет чоры» дип исемләнгән һәм бәяләнгән дәвердә дә милли нигезләрне саклап яшәргә омтылуы, башка әдәбиятларны кабатламыйча, үз йөзен булдырып үсүе исбатлана.

Шушы тәгълимат нигезендә Д. Заһидуллина XX гасыр татар әдәбиятының тулы тарихын колачлап ала: XX йөз башы әдәбияты XX–XXI гасыр чикләре сүз сәнгате белән тоташтырыла. XX гасыр әдәбиятын бөтенлекле система итеп өйрәнү милли традицияләрнең дәвамчанлыгын, эстетик байлыкны, поэтик тирәнлекне, иҗади юнәлеш, агым, алымнарның күплеген күрергә мөмкинлек бирә. XX гасырның икенче яртысы татар прозасын һәм поэзиясен милли мәдәни традицияләр яктылыгында бәяләгән «1960–80 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр (2015)» хезмәте шушы яктан әһәмияткә ия. Поэтик һәм прозаик әсәрләрдә герой концепциясен, сурәтле фикерләү үзенчәлеген, үзенчәлекле символлар дөньясын колачлап өйрәнү моңа кадәр бу юнәлештә эшләгән галимнәрнең фикер-карашларын үстереп, иҗатларга яңача караш ташларга мөмкинлек тудыра. Д. Заһидуллинаның бу чор әдәбиятындагы күтәрелешнең авангард эзләнүләргә бәйле булуы, авангард күренешләрнең дөнья әдәбиятындагы охшаш тенденцияләр тәэсирендә, примар системаның бер өлеше төсендә формалашуы, әмма аның үзгә традицияләргә, милли үзенчәлекләргә нигезләнеп үсүе хакындагы фикере әдәбият гыйлемендә яшәп килгән стандарт фикер офыкларын киңәйтеп җибәрә. Милли традицияләргә таянып үсү галимә тарафыннан татар сүз сәнгате өчен чикләү түгел, киресенчә, традицион нигездә яңалыкларны үзләштерүнең, милли җирлектә нинди үзгәрешләр кичереп иҗади яраклашуын күзәтүнең бер принцибы буларак тәкъдим ителә. Шул рәвешле 1960–1980 еллар татар әдәбиятының һич кенә дә торгынлык чоры сүз сәнгате түгел, ә милли традицияләргә нигезләнгән күтәрелеш чоры, үсүнең өр-яңа сукмакларын салган, яңа кеше концепциясен формалаштырган дәвере буларак аерып куела, совет чорында да әдәби барышны үзгәртерлек, милли нигездән үстереп китәрлек яңа сукмаклар табылуы дәлилләнә. Күпсанлы әсәрләргә анализлар әдәбият белемендәге «милли яңарыш 1990 елларда башлана» дип калыплашкан карашны үзгәртә һәм үзгә фикер белдерүгә юл ача: милли нигезләргә әйләнеп кайту процессын татар әдәбияты XX гасыр уртасында ук башлый.

Әдәбият тарихын бербөтен система итеп, синхрон һәм диахрон яссылыкларда масштаблы өйрәнү теләге эзләнүләрне XX–XXI гасыр чикләренә кадәр киңәйтүне көн тәртибенә куя. Моңа кадәр дә күпсанлы тәнкыйть мәкаләләрендә, «Яңа дулкында» (2006) монографиясендә ассызыкланып килгән фикер-карашлар «Современная татарская

проза (1986–2016): основные тенденции историко-литературного процесса» (2017), «Татарская поэзия рубежа XX–XXI веков (1986–2015 гг.): эстетические ориентиры и художественные поиски» (2017) хезмәтләрендә системага салына, тирәнәйтелә. Бу монографияләрдә Д. Заһидуллина тарафыннан ике гасыр чиге татар сүз сәнгатендә формалашкан яңа күренешләр, агымнар аерып чыгарыла, «постреализм», «постромантизм», «неореализм», «постмодернизм» һ. б. төшенчәләрнең милли үзенчәлеге тәгаенләнә. Бер яктан, милли традицияләрнең хәзерге әдәбиятка кадәр килеп җитүе, ягъни татар әдәбиятының үз, милли йөзе булуы фикере исбатлана, икенче яктан, ике гасыр чигендә сүз сәнгатенең яңа, үзгә этапка кереп баруы ассызыклана. Шул рәвешле, бу тикшеренүләр татар сүз сәнгатен үз традицияләре формалашкан, шул ук вакытта яңалыкларны милли җирлеккә яраклаштырып кабул итә алган, башка алдынгы әдәбиятлар белән янәшәдә тәңгәл үсеш-үзгәреш кичерә торган, нинди генә шартларда да үз имманент, эчке закончалыкларын саклап кала алган бөтенлекле система итеп раслый.

Әдәбият фәненең төрле аспектларында тирәнтен эзләнүләр алып барган, еш кына яңа сүз булып кабул ителгән, үзеннән соңгы эзләнүчеләргә сукмаклар салып калдырган монографияләре, кулланмалары белән янәшәдә Д.Заһидуллина «Казан утлары», «Мәйдан», «Чын мирас», «Фәнни Татарстан» кебек журналларда бүгенге әдәби барышны бәяләгән, дөнья күргән яңа әсәрләргә җентекле фәнни анализ, шулар нигезендә кызыклы гомумиләштерүләр ясаган язмалары белән дә чыгыш ясый. Фәнни, академик тәнкыйтькә йөз тоткан, үзе өйрәнү үзәгенә алган шагыйрь, прозаик яки драматургның әдәби барыштагы урынын, нинди иҗат юнәлеше, агымы тарафдары булуын, башка авторлар иҗатында дәвам ителергә мөмкин үзенчәлекләрен анык билгеләп барган бу язмалар әдәбият белеменең тагын бер тармагын – әдәби тәнкыйтьне үстерүгә, аның фикри офыкларын киңәйтүгә йөз тота. Академик тәнкыйть белән бергә Д. Заһидуллина тәнкыйтьнең тагын бер тармагын – XX йөз башында зур үсеш алган, әмма бүгенге көн өчен актуальлеген киметкән оператив тәнкыйтьне тергезү омтылышын ясый. Гомумән, ул бүгенге көндә татар әдәби тәнкыйтен җанландыру юлын нәкъ менә оператив тәнкыйтьне популярлаштыруда күрә. 2017 елдан башлап «Казан утлары» журналында ул башлап җибәргән «Җәһәт тәнкыйть: сәхифәне Д. Заһидуллина алып бара» рубрикасы шул хакта сөйли. Әдәби мәйданда әлегә үз фикерен әйтергә өлгермәгән, яңа аяк басып килүче яки яшь авторларның әсәрләре артыннан ук, аның сыйфаты нинди булуга карамастан, галимәнең күләме зур булмаган рецензиясе тәкъдим ителә. Аларда әсәргә беренчел бәя бирелә, аның сәнгатьлелек дәрәҗәсе тәгаенләнә, кимчелекләре һәм киләчәккә камилләшү мөмкинлекләре билгеләнә, нәтиҗәдә авторга әсәрне үзгәртергә-төзәтергә киңәш биреп барыла. Д. Заһидуллинаның моннан тыш та республика газета-журналларында басылган күпсанлы язмаларында Р. Зәйдулла, Р. Аймәт, Н. Гамбәр

һ. б. авторларның әле генә табадан төшеп, кулга килеп кергән җыентыкларына беренчел бәя бирелә. Китаплардан алган тәэсирләрне уртаклашып язылган мондый рецензияләрнең басманы укучыга тәкъдим итүгә, популярлаштыруга һәм татар укучысына тарату эшенә өлеш кертүен дә ассызыклау мөһим. Ул мәкаләләр дә, Дания Заһидуллина каләменнән төшкән монография-хезмәтләр кебек үк, теоретик нигезле, фәнни җәһәттән тирән, бер үк вакытта иҗади рухлы булулары белән аерылып тора һәм авторының чын мәгънәсендә олпат, үз концепциясен булдырган, әдәбият белеме фәнен яңа югарылыкка күтәргән галим, бу өлкәдә идеяләр әйдаманы булуын тагын бер кат дәлилли.

***Юсупова Нурфия Марс кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты*
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты*
*Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбенең*
*татар әдәбияты кафедрасы доценты*

УДК 81´374

***Р.Л. Исхаков***

# ТАТАР ЛЕКСИКОГРАФИЯСЕНӘ ӨЛЕШ КЕРТКӘН ШӘХЕС: ГАБДЕЛХӘЙ ИСХАКОВ

В статье рассматривается биография младшего научного сотрудника ИЯЛИ Габдулхая Исхаковича Исхакова, связанная с работой в творческой группе над созданием в стране первого большого татарско-русского словаря в период национального языково-культурологического ренессанса: конца 50-х – первой половины 60-х гг. XX века. Приводятся факторы окружающей социальной среды, которые могли повлиять на организацию и деятельность научного коллектива при создании такого словаря.

**Ключевые слова:** биография младшего научного сотрудника ИЯЛИ КФ АН СССР Г.И. Исхакова, взаимоотношения в научном коллективе, факторы подъема национального самосознания в Татарии (конец 50-х – первая половина 60-х гг. XX века).

The article discusses the biography of the junior researcher at the Institute of Language, Literature and Art Gabdulkhai Iskhakovich Iskhakov, associated with working in a group on the creation of the first large Tatar-Russian dictionary in the country during the national linguistic and cultural renaissance: late 50s – first half of 60s of XX century. The factors of the social environment that could affect the organization and activities of the research group when creating such a dictionary are given.

**Keywords:** biography of a junior research fellow of the Institute of Language, Literature and Art at the Kazan branch of Academy of Sciences of the USSR Academy of Sciences G.I. Iskhakov, the relationship in the research group, the factors of the rise of national identity in Tatarstan (late 50s – first half of the 60s of the XX century).

*Абыем Габделхәй Исхак улы Исхаковның дөньядан китүенә чирек гасырдан артык вакыт узса да, бер сорау җаныма һич тынгылык бирми: ни өчен ул СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында бик аз – нибары җиде ай гына эшләде икән? Моның сәбәбен мин Габделхәй абыйның үзеннән дә сорап карадым. Бу вакытта ул инде авырый иде. Әллә шуңа, ачык кына җавап ала алмадым. Мөгаен, аның өчен фәнни эшчәнлек, шул исәптән карьера ясау да, үтә дәрәҗәле эш саналмаган, ә укытучылык итү, архивта эшләү яки мәгариф өлкәсендә оештыру хезмәте кебек интеллектуаль статуслы һөнәрләр белән бер рәттә торган. Соңгылары белән ул гомере буена һәм яратып шөгыльләнде.*

*Бездә аның Казанда узган вузара конференция материалларын үз эченә алган фәнни җыентыкта басылып чыккан бердәнбер кечкенә генә мәкаләсе [Исхаков, 1960], шулай ук ТӘһТИ җитәкчелеге һәм уналты фәнни хезмәткәр (Г.И. Исхаков та шулар арасында) тарафыннан әзерләнгән һәм нәшер ителгән татарча-русча сүзлек [Татарско-русский словарь, 1966] саклана.*

*Әлеге сүзлекнең кыска һәм ачык итеп язылган Сүз башы белән танышканнан соң, миндә абыебызның шушы басманы төзү өстендәге эшчәнлеге белән бәйле кыскача гына биографиясен язу идеясе туды, шулай ук сүзлекне төзегән зыялыларның үзара бәйләнешләрен ачыклау теләге дә көчле иде. Бер уңайдан XX гасырның 50 нче еллар ахыры – 60 нчы елларның беренче яртысындагы күренекле вакыйгалар өермәсендә советлар илендә 36 мең сүзне үз эченә алган зур татарча-русча сүзлек чыгару буенча уникаль милли проект туган үзенчәлекле дәверне дә яктыртасым килде.*

**ТӘһТИнең фәнни даирәсенә ул ничек килә**

Габделхәй Исхаков 1929 елның 10 мартында Татарстан АССРның Яр Чаллы районы Иштирәк авылында дүртенче төпчек бала булып дөньяга килә. Әти-әнисе – Исмәгыйлов Исхак һәм Исхакова Фәрхинур (кыз фамилиясе Гыйльманова) – крестьяннар.

1936 елда Габделхәй җиде яшендә Иштирәк авылы урта мәктәбенә беренче сыйныфка укырга керә. Әтисе Исхак бу вакытта инде репрессиягә эләгеп, 10 елга Магадан рудникларына сөрелгән була. Урта мәктәпне абый 1946 елда тәмамлый. Тарих укытучысы булу өчен Таҗикстанга укырга китәргә кемдер киңәш иткәнме, әллә үзе шул фикергә килгәнме, бүген әйтүе кыен. Бәлки мәктәптәге тарих укытучысы сәләтле укучысының, Урта Азиягә барып, катлаулы Шәрык дөньясының мәдәниятен һәм табигатен тирәнрәк өйрәнүен теләгәндер. (Сүз уңаеннан, патша заманында аларның ата-бабалары дөяләр өстендә Иштирәккә күченеп килгәннәр.) Мәктәпне тәмамлауга Габделхәй әле ике ел укытучы булып эшли алган, чөнки бөтен илдә педагогик кадрларга кытлык зур булган. Өстәвенә ул Ленинабадка барып җитәргә юллык акча да эшли алыр иде. Шуны ассызыклап әйтергә кирәк: ул инде мәктәп елларында ук гарәп, латин язуларын һәм кириллицаны үзләштергән. Тагын бер әһәмиятле момент бар: Габделхәйне шәхес буларак формалаштырган этик-танып белү атмосферасы нәкъ менә татар җирлегендә барлыкка килгән.

Ленинабад (хәзерге Хөҗәнд) шәһәренә аның ничек барып эләгүе, анда кайда, ничек яшәве безгә мәгълүм түгел. Югары белемгә ия булу турында дипломындагы язмалардан гына кайбер мәгълүматлар ачыклана: Г. Исхаков 1948–1952 елларда Ленинабад дәүләт педагогия институтында «Тарих» белгечлеге буенча белем алган.

Дипломга кушымтаны, ягъни «зачётлар исемлегеннән өземтә»не анализлау шуны күрсәтә: институтта укытылган 22 мәҗбүри предметтан имтихан тапшыру өчен, дипломант ким дигәндә дүрт тел – рус, татар, таҗик, немец телләрен белергә тиеш. Тарих, педагогика, психология кебек төп предметлардан тыш, ул архив белеме предметын да үзләштергән һәм имтиханны «яхшы» билгесенә тапшырган. Бу аңа киләчәктә Казанда архивчы булып эшләргә мөмкинлек бирә. Педагогик практика үтү графасында укытучы булып эшләве әйтелгән. Димәк, студент елларында ук ул Ленинабадта мөгаллимлек итеп көн күргән.

Совет заманында яшь белгечләрне эшкә рәсми рәвештә билгеләгәннәр. Пединститут дипломы алган Габделхәй Исхаковны да юллама белән Уратүбә шәһәренә укытырга җибәрәләр.

«Хезмәт кенәгәсе»ндәге мәгълүматларга караганда, Г.И. Исхаковның хезмәт биографиясе 1953 елның 1 сентябрендә Уратүбә шәһәренең эшче-яшьләр кичке мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укытудан башланып киткән. Аннан соң шул ук шәһәрнең Калинин исемендәге мәктәбендә 1956 елның 14 августына кадәр эшләгән. Шул ук көнне Ленинабад өлкәсе Исфара шәһәрендәге эшче-яшьләр мәктәбенә тарих укытучысы һәм завуч итеп билгеләнгән. Анда ул нәкъ бер ел, ягъни 1957 нең августына кадәр хезмәт куйган.

Алга таба энергиясе-көче ташып торган 28 яшьлек Габделхәйнең тормышында зур үзгәрешләр була: Таҗикстанда 10 ел мөгаллимлек иткәннән соң, ул аннан бөтенләйгә китеп бара. Бәлки егет үзенең туган җирен бик сагынгандыр, бәлки Казанда эшләргә хыялланып, иҗади перспективаны Татарстан белән генә бәйләп карагандыр. Ничек кенә булмасын, 1957 елның җәендә ул Исфара шәһәрен калдырып китә. Сүз уңаеннан, 1977 елда көчле җир тетрәү нәтиҗәсендә бу шәһәр тулысынча җимерелә, аннан яңадан торгызыла [Город Исфара]. Шунысы әһәмиятле, ул әле илдә, шул исәптән Татарстанда да, татар милли яңарышы белән бәйле зур сәяси һәм культурологик вакыйгалар башланасын белми.

1957 елның 6 июнендә КПССның Татарстан өлкә комитетында хакимият алмашына: беренче секретарь Зиннәт Ибәт улы Моратов урынына Семён Денисович Игнатьев куела. Соңгысы әлеге вазифаны 1960 елның октябренә кадәр башкара [Игнатьев...]. Тарихчы галим, профессор Булат Солтанбәков сүзләренә караганда, Игнатьев өч ел эшләү дәверендә «татар теленең статусын торгызуга зур өлеш кертүе белән истә кала», аннан соң ул «бер төркем татар зыялыларының татар мәдәниятенең, беренче чиратта татар теленең абруен күтәрергә тырышларуын хуплый. Партия структураларында бу эшнең башында Камил Фасеев тора» [Султанбеков]. Әлеге кыска вакытлы татар ренессансында 1958 елның 21 маенда уздырылган КПСС өлкә комитеты пленумы «татар теленең статусын күтәрү өлкәсендәге эшнең иң югары ноктасы булып тора». Анда «татар мәдәниятенең торышы һәм тулаем милли сәясәтне гамәлгә ашыру турында катгый сөйләшү була» [шунда ук] һәм татар гомуми белем мәктәпләренең эшен яхшырту, махсус уку йортларында татар телендә белем бирүне оештыру, Г. Тукай исемендәге премияне булдыру, татар энциклопедиясен төзү һ. б. турында карар кабул ителә.

Габделхәй Исхак улы 1957 елның җәендә Казанга кайта һәм август аеннан башлап декабрьга кадәр ТАССР Мәдәният министрлыгының культура-агарту эшләре бүлегендә инспектор булып эшли башлый (бу вакытта З. Байчурин министр урынбасары вазифаларын башкара).

1957 елның ахырында Исхаков ТАССР Үзәк дәүләт архивына бүлек җитәкчесе итеп куела. Бу вазифаны ул 1959 елның сентябренә



Габделхай Исхаков (уңда) энесе Зәки Зиһаншин белән

кадәр үти. Бу эштән дә үзе теләп китә, ә аннан соң елдан артык ни өчендер эшсез утыра. Мин бәлки аны татарча-русча сүзлекне эшләргә чакырып, ТӘһТИгә тиз генә рәсми рәвештә эшкә урнаштыра алмаганнардыр дип фараз кылам. Шушы вакытта ул акыллы һәм матур татар кызы Зәйтүнә Шакирҗанова белән таныша. Алар өйләнешәләр, һәм тиздән 1960 елның апрелендә беренче уллары Рөстәм дөньяга килә.

60 нчы еллар башында татар милли яңарыш хәрәкәте каршылыкка очрый. Хәер, Татарстанның туган тел статусын торгызу инициативасын Башкортстан һәм Кыргызстан да күтәреп ала. Ләкин КПСС ҮК комиссиясе буйсынулы республикалардагы мондый мәдәни башбаштаклыкны «милләтчелеккә юл кую» дип бәяли [шунда ук]. Игнатьев киткәннән соң, Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре итеп көчле стратег Фикрәт Әхмәтҗан улы Табеев (1928–2015) билгеләнә [Табеев...]. Ул милли үзаң үсешенә каршы төшми, киресенчә – хуплый. 1960 елда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы ТӘһТИ директоры итеп Камил Фатыйх улы Фасеев (1919–2005) куела [Фасеев...]. Ул институтны 1963 елга кадәр җитәкли.

1960 елның 6–8 июнендә «Тюркология һәм рус Шәрык белеме тарихы мәсьәләләре» дигән темага вузара фәнни конференция үткәрелә. Аның эшендә Г.И. Исхаков та катнаша һәм, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы ТӘһТИ вәкиле буларак, «Казан университеты профессоры Н.Ф. Катановның (1862–1922) тюркологик эшчәнлеге» дигән темага доклад белән чыгыш ясый.

Г.И. Исхаков, фәнни эшчәнлек белән беррәттән, 1960 елның ноябрендә Казан шәһәренең 6 нчы интернат-мәктәбенә тәрбияче булып та урнаша һәм 1961 нең апрелена кадәр эшли. 1961 елның апреле Габделхәйгә икеләтә бәйрәм алып килә: аны СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы ТӘһТИ гә лаборант вазифасына вакытлыча эшкә алалар, ә ике айдан кече фәнни хезмәткәр итеп күчерәләр. Биредә ул 1961 елның 30 октябрена кадәр эшли.

**Өч фәнни җитәкче**

Габделхәй Исхак улының хатыны Зәйтүнә ханымның сүзләренә караганда, 1960 еллар башында аның иренең өч фәнни җитәкчесе була: Николай Васильевич Никольский (тарих фәннәре докторы), Гаян Суфиян улы Әмиров (филология фәннәре кандидаты), Үзбәк

Шәриф улы Байчура (филология фәннәре кандидаты). Алар арасындагы дустанә һәм иҗади мөнәсәбәтләр турында әйтүе кыен, чөнки үзләре исән вакытта бу турыда бер дә сорашмадык. Әмма үземнең күзәтүләрдән чыгып, шуны әйтә алам: Никольскийга ул аеруча хөрмәт белән карый, аның турында һәрвакыт сокланып сөйли иде.

Н.В. Никольский 1961 елның ноябрендә вафат була [Никольский...]. Габделхәй Исхаков Г.С. Әмиров һәм Ү.Ш. Байчура белән берлектә (һәм тагын үндүрт белгеч) татарча-русча сүзлек төзү өстендә эшли. Бу турыда басманың керешендә дә әйтелгән [Татарско-русский словарь, 1966, с. 5–6].

Г.С. Әмиров ТӘһТИдә 1957–1962 елларда эшләгән, аннан соң Казаннан Омскига китеп барган [Амиров...]. Ү.Ш. Байчура 1959–1963 елларда биредә хезмәт куеп, Мәскәүгә юл алган [Байчура...].

Габделхәй абыйга фәнни җитәкчеләрсез калу җиңел булмагандыр. Һәм ул 1962 елның маенда Х. Ямашев исемендәге Татар мех җитештерү берләшмәсенә архив мөдире булып эшкә урнаша. Биредә 1968 елның сентябренә кадәр эшли. Шушы вакытта икенче улы Фәрһад туа. Гаилә тормышын рәтләргә кирәк була. Ул фәнни эшне вакытлыча читкә куеп тормакчы була. Ә чынлыкта фәнне бөтенләйгә ташлый.

1964 елда тагын ил җитәкчелеге алышына: Л.И. Брежнев КПСС ҮК Генераль секретаре була. Торгынлык чоры башлана. Габделхәй абый гарәп хәрефләре белән язылган борынгы кульязма китаплар җыю белән шөгыльләнә. Эзли, таба һәм танышларының сарайларында саклый. Әмма бу җәүһәрләр, ни сәбәпледер, югала. Китапларны өйгә алып кайта алмый, чөнки кечкенә генә коммуналкада иске китапларга урын булмый.

Ул гомеренең азагына кадәр фән һәм мәгърифәт кешеләренә аерым хөрмәт белән карады, китап яратты, 1966 елда нәшер ителгән, аны дөньяга чыгаруда үзенең дә өлеше кергән «Татарча-русча сүзлек» китабы турында чын күңелдән яратып сөйли иде.

* * *

Татар мех берләшмәсендә эшләгән дәвердә Габделхәй Исхаков гаиләсе аерым фатирлы була. Буш вакытын хуҗа кеше дачада үткәрә: җир кайтара, алмагачлар утырта, йорт сала... 1968 елдан ул Юдино посёлогындагы профессиональ-техник училищеда һәм Казан шәһәренең 97 нче мәктәбендә тарих укыта. 1976 елның гыйнварында Габделхәй Исхак улы Казан шәһәренең яшь техниклар станциясенә методист булып күчә һәм анда 1980 елга кадәр эшли. Аннан аны Казан вертолёт заводы каршындагы яшь техниклар клубына директор итеп чакыралар. Бу – Габделхәй Исхаковның соңгы эш урыны. Биредә ул 1991 елның мартына – вафатына кадәр хезмәт куя.

Габделхәй Исхак улын мин һәрвакыт Көнчыгыш акыл ияләренә охшатам: сабыр табигатьле, үткен акыллы, аз сүзле, нечкә күңелле...

шаярта да, үз фикерен ачык итеп әйтеп бирә белә торган да кеше иде ул. Табигате белән лирик-романтик дип тә өстисе килә. Ул бик матур һәм пөхтә киенә иде. Әмма беркайчан сакал-мыек йөртмәде, тәмәке тартмады.

Кызганычка каршы, улларының берсе дә әтиләренең эшен дәвам итмәде, тарихчы, филолог, педагог яки архивчы һөнәрен сайламады. Әмма икесе дә хөрмәткә лаеклы кешеләр булды.

## Фәнни традицияләрнең дәвамы

1957–1966 елларда «Татарча-русча сүзлек» дәүләт-милли проекты өстендә эшләгән фәнни хезмәткәрләрнең исемлеген китерик: К.С. Абдразаков, Г.С. Әмиров, А.Ш. Әсәдуллин, Г.Х. Ахунҗанов, Ү.Ш. Байчура, С.Б. Вахитова, Ф.М. Газизова, Ф.Ә. Ганиев, Г.И. Исхаков, М.Г. Мөхәммәдиев, М.М. Османов, Ф.С. Фасеев, Г.Г. Фәхретдинов, К.Х. Хәмзин, Э.Ш. Хәмидуллин, Ш.С. Ханбикова.

Әлеге хөрмәткә лаек белгечләрнең кайберләре тагын да зуррак сүзлекләр төзүдә дә катнашты. 2007 елда уникаль басма – 52 мең сүзне үз эченә алган ике томлы татарча-русча сүзлек [Татарско-русский словарь, 2007] дөнья күрде. Аны төзү өстендә түбәндәге авторлар эшләде: И.А. Абдуллин, Р.Р. Абдуллина, Р.Г. Ахметьянов, Г.Х. Ахунҗанов, С.Б. Вахитова, Ф.М. Газизова, Н.В. Максимов, М.Г. Мөхәммәдиев, Р.К. Рәхимова, Г.Г. Сабирова, Ф.Б. Ситдыйкова, Ш.С. Ханбикова, А.М. Хәзрәтов.

Әлбәттә, тулы бер китапның, бигрәк тә «Татарча-русча сүзлек»нең туу тарихын бер мәкаләдә генә яктыртып бетерү мөмкин түгел. Бәлки тарихчылар, язучылар арасында әлеге коллектив фәнни хезмәтне, аның төзелү тарихын өйрәнүне дәвам итүче табылыр. Аны төзүдә катнашкан һәр фәнни хезмәткәрнең исем-фамилиясен генә түгел, алар турында тулы мәгълүматны үз эченә алган язмаларны да күрәсе килә.

## Әдәбият


Амиров, Гаян Суфиянович // Энциклопедия Башкортостана [Электронный ресурс]. – Режим доступа: http://wiki02.ru/encyclopedia/Amirov_Gayan_Sufiyanovich/t/676.

Байчура Узбек Шарифович. Биография. [Электронный ресурс]. – Режим доступа: http://www.millattashlar.ru/index.php/Байчура_Узбек_Шарифович.

Город Исфара. [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://dvc.academic.ru/dic.nsf/ruwiki/23827.

Игнатьев, Семен Денисович. Биография. [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://ru.wikipedia.org/wiki/Игнатьев,_Семён_Денисович.

*Исхаков Г.И.* Тюркологическая деятельность профессора Казанского университета Н.Ф. Катанова // Проблемы тюркологии и истории русского востоковедения (тезисы докладов и сообщений на межвузовской научной конференции, посвященной 40-летию ТАССР, проходившей в КГУ 6–8 июня 1960 г.). / редакторы: М.З. Закиев (секция тюркологии), А.С. Шофман (секция истории русского востоковедения). Казань, 1960. С. 87–90.

Никольский, Николай Васильевич. Биография. [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://ru.wikipedia.org/wiki/Никольский,_Николай_Васильевич.

*Султанбеков Б.Ф.* Как главу Татарии наказали за татарский язык в СССР. [Электронный ресурс]. Режим доступа: http://www.asiarussia.ru›Статьи›8375.

Табеев, Фикрят Ахметжанович. Биография. [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://ru.wikipedia.org/wiki/Табеев,_Фикрят_Ахмеджанович.

Татарско-русский словарь: в 2-х томах. – Казань: Магариф, 2007.

Татарско-русский словарь. М.: Советская Энциклопедия, 1966. 863 с. Казанский институт языка, литературы и истории Академии наук СССР).

Фасеев, Камиль Фатыхович. Биография. [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://ru.wikipedia.org/wiki/Фасеев,_Камиль_Фатыхович.

***Исхаков Равил Лотфулла улы,***
*фәлсәфә докторы, Казан*

УДК 821.512.145

*Нәҗип Гасрый*

## «ХИСАМЕТДИН МЕНЛА» (АКЪЕГЕТЗАДӘ МУСА ӘСӘРЕ)

Данная статья представляет собой критический анализ литературоведа Наджипа Гасрый (1886–1937) на произведение Мусы Акъегетзаде «Хисаметдин менла». В своей работе критик пытается наиболее полно показать успех этого произведения как одного из первых реалистических романов в истории татарской литературы, оказавшее огромное влияние на труды последующих писателей. Для более детального описания романа, автор статьи предоставляет некий обобщенный анализ трудов написанных задолго до этого произведения.

Статья была опубликована на страницах журнала «Аң» (1910 год, № 9–10).

**Ключевые слова:** Наджип Гасрый, Муса Акъегетзаде, татарская литература, история.

This article is a literary critic Najip Gasry's (1886–1937) critical analysis on Musa Akegetzadeh's work «Hisametdin menla». The critic in his work tries to most fully show the success of this work as one of the first realistic novels in the history of Tatar literature, which had a huge impact on the works of subsequent writers. For a more detailed description of the novel, the author of the article provides a generalized analysis of the works written long before this work.

The article was published on the pages of the journal «Ang» (No. 9–10, 1910).

**Keywords:** Najip Gasry, Musa Akegetzadeh, Tatar literature, history

«Хисаметдин менла» – яңа татар әдәбиятының бисмилласы,

«Хисаметдин менла» – татар әдәбиятының беренче чәчкәсе,

«Хисаметдин менла» – утыз еллык яңа әдәбиятымызның сәхифәсе.

– Яңа татар әдәбияты, аның бисмилласы, аның чәчкәсе, утыз еллык яңа әдәбиятымыз, аның беренче сәхифәсе – болар яңа тәгъбирләр вә кыйсьмәне мөбһәм[1] нәрсәләр:

– Яңа татар әдәбияты булгач, аның искесе дә булырга кирәк, унбиш елдан бирле безнең телемезне баетучы, кулларындан каләмләрен ташламыйча языб, җилдләр[2] вөҗүдкә китерүче[3] мөхәррирләремезне беләмез, ләкин унбиш елның теге ягын белмимез диючеләр күб, хәтта «Хисаметдин менла», нәрсә соң ул, картада отдырылган кыз Зөлхәбирәнең атасы шикелле исем чыгарган бер-бер мулламы? Яки бер-бер китаб исемеме диб, сораучылар да бар вә булгалады...

Болар берсе дә гаҗәб түгел, төрек-татар тарихы гомумиясе[4] вә бу тарихы гомумиянең олуг вакыйгаларына ияреб, күтәрелгән, төшкән төрле дәверләр ясаган төрек-татар тарихы, әдәбияты вөҗүдкә ките-

[1] Кыйсьмәне мөбһәм – өлешчә аңлаешсыз.
[2] Җилдләр – монда: күпләп китаплар.
[3] Вөҗүдкә китерүче – барлыкка китерүче.
[4] Тарихы гомумиясе – гомуми тарихы.

релмичә торыб, мондый диючеләр вә сөальләрнең булуы гаҗәб түгел, бәлки табигыйдер.

Безнең иске әдәбиятымыз бар, ифадә[1] вә өслүб[2] җәһәтендән генә – ул да зәгыйфь нисбәтдә генә булса да, аның яңа әдәбиятымызга тәэсире дә булган.

Ник булмасын, безнең шәһәрләремезне тирбәткән куллар аларның самигъләренә[3] «Мөхәммәдия»ләр, «Бакырган»лар көйләгәч, аларга «Бәдәвам»ләр, «Ярты алма»лардан сабак укыткач, иске әдәбиятымызның яңа шагыйрьләремезгә вәзен[4], өслүб, ифадә вә хәтта нәсыйхәт тарзында[5] мәгънә җәһәтендән тәэсире булмыйча мөмкин түгел.

Иске әдәбиятымызның дәверләр иҗад иткән куәтле эпик вә лирик шагыйрьләре вә аларның бик күб мәкаләләре булган вә хәзердә дә бар.

«Хисаметдин менла» белән башланган яңа әдәбиятымызга кадәр шул иске әдәбият вә аның тәкълидләре[6] безнең әдәби ихтыяҗымызны үтәб килгән вә хәзердә дә кайбер йирләрдә үтәб ята.

«Хисаметдин менла» беренче чәчкә булыб атканга кадәр унтугызынчы гасырның бигрәк дә соңгы яртысында безнең Идел буе телемезнең эшләнә башлау дәвере вә ул дәвергә рус вә мәдрәсә тәэсире астында хезмәт иткән затлар бар вә аларга иске әдәбиятымызның бик ачык сурәтдә тәэсире вә шул юл әдәбиятымызның иске әдәбиятымызга мәгънәви бер җеб белән бәйләнеше сабитдер[7].

Төрек-татар тарихе әдәбиятына[8] даир[9] мәгълүмат җыелыб, бербөтен китаб итеб басылган булмаса да, бу елда нәшер ителгән әсәрләрдән файдаланыб, бу урында чыгтай әдәбияты аталган әдәбият белән җәнүб төрекләре – госманлы әдәбиятына гаид бәгъзе мәгълүмат язып китүне мөнасиб күрәмез.

Борын заманларда төрекләрнең үзләренә махсус язулары бар иде. 8 нче гасыр миладида Орхон елгасы вадисында[10] Күлтәгин вә Билге каганлар намына[11] утыртылган һәйкәлләрдәге тасвир вә хитабәләр[12] шул язу белән язылган иде.

Иранда сыеша алмыйча төрек йиренә барыб христианлык таратырга тотынган нистори раһибләре[13] төрек бикләренә тәэсир итделәр: төрек язуына нистори язуы катышды, уйгур каганлары бу язуны

---

[1] Ифадә – әйтелеш.
[2] Өслүб – стиль.
[3] Самигъләренә – тыңлаучыларына.
[4] Вәзен – форма.
[5] Тарзында – рәвешендә.
[6] Тәкълидләре – традицияләре.
[7] Сабитдер – ачыктыр.
[8] Тарихе әдәбиятына – әдәбият тарихына.
[9] Даир – караган.
[10] Вадисында – үзәнендә.
[11] Намына – данына.
[12] Хитабәләр – язу, мөрәҗәгать.
[13] Нистори раһибләре – несториан монахлары.

истигъмаль итеб[1], ахырдан бу язу – «уйгур язуы» исемен алды, Чыңгыз балалары дәверендә бу язу рәсми язу булыб кабул ителде.

Беренче милли әсәр булган «Кудатку билик» унберенче гасырда шушы миллиләшкән язу белән язылган бу әсәрдән башка уйгур телендә вә уйгур язуы белән «Бәхтиярнамә» исемендә фарсыдан тәрҗемә ителеб, бер роман, мигъраҗнамә вә «Тәзкирател-әүлия» исемендә дини әсәрләр язылган, бу әсәрләр белән бергә Хуҗа Әхмәд Ясәвинең уникенче гасырда язылган «Диване хикмәт»енең Сөләйман Бакыргани – Хәким атаның «Бакырган» исемле диваны уйгур әдәбиятының үрнәкләредер.

Уйгур әдәбияты Урта Азиядә эшләнгән иске төрек әдәбиятының башлангыч кыйсемедер. Күләм җәһәтендән зур булмаган вә мәгънә ягыннан да дини, әхлакый вәгазьләр вә шагыйрьнең изге тойгыларын ифадә иткән бу әдәбият вакыты берлә миллият өчен шактый нык терәк булыб хезмәт иткән. Гарәбләр Төркестанны фәтех иткәннең[2] соңында төрекләр гарәб хәрефләре, гарәб сүзләре, гарәб вә Иран мәдәнияте каршысында, тәэсирендә калдылар. Тәймүр балаларының зур хөкүмәтендә төрек халкы иранлылаша башлады: иранлыларча кием кияргә, сүз арасына бик күб фарсыча сүзләр катышдырыб сөйләргә, төрек телен онытырга башлады.

Менә шул вакытда милли телдә, милли хәрефләр белән – уйгурча язылган «Кудатку билик» бәетләренең телләрдә саф төрекчә булыб әйтелүе – фарсы теленә каршы үз алдына бер нәмаиш[3] иде.

Унөченче гасырдан унсигезенче гасырга кадәр бөтен Урта Азиядә вөҗүдкә китерелгән әсәрләр чыгтай әдәбиятын тәшкил итәләр. Бу әдәбиятның иң парлаган заманы – унбишенче вә уналтынчы гасырлардыр. Бу әдәбият чыгтай илендә бик алга киткәнгә күрә, шул исем белән аталган. Чыгтай әдәбиятында истигъмальдән[4] чыкган иске төрекчә сүзләр белән бик күб гарәбчә вә фарсыча сүзләр кулланылган. Һират, Бохара, Сәмәрканд шәһәрләре бу әдәбиятның мәркәзләре иде.

Чыгтай әдәбияты уйгур әдәбиятына нисбәтән[5] шагыйрьләрнең эчке вә тышкы тойгылары тасвирларына бик бай.

Миргали Ширнәваи – чыгтай әдәбиятының падишаһы, Урта Азия шагыйрьләренең таҗыдыр. Нәваидән кала бу әдәбиятда солтан Хөсәен Бәйкара, Бабыр Мирза, Лотфи Сәкаки кебек мәшһүр төрек шагыйрьләре йитешә. Болар мәүзугъ[6], мәгънә ягы вә чыгтай әдәбиятындан фарсы шагыйрьләрен тәкълид итсәләр дә[7], төрек теленең фәсахәтен[8] мәйданга чыгарырга күб хезмәт итәләр.

---

[1] Истигъмаль итеб – кулланып.

[2] Фәтех иткәннең – яулап алганның.

[3] Нәмаеш – тантана.

[4] Истигъмальдән – кулланылыштан.

[5] Нисбәтән – чагыштырганда.

[6] Мәүзугъ – сюжет.

[7] Тәкълид итсәләр дә – ияру, охшатып эш иту.

[8] Фәсахәтен – матурлыгын, ятышлылыгын.

Искедә уйгур вә чыгтай әдәбияты кебек бай әдәбиятка малик булган Төркестан күб заманлар әдәбият мәйданында ат уйнаткан бөек шагыйрьләрен тәкълид итде.

Яңа аякланыб килә торган Төркестанның әдәби теле менә шундый мазыйга[1] маликдер.

Җәнүб-госманлы төрекләренең әдәбиятына килсәк. Боларда да әдәбият яхшы тәрәккый итде.

Госманлылардан әүвәл Анатолиядә ике гасырдан артык хөкем сөргән сәлҗукыйләр телләрендә бигрәк тәмсил итеб[2] фарсы телен кулландылар. Сәлҗукыйләр хөкүмәте заманында йитешкән Җәлалетдин Руминың әллә ничә мең бәетдән гыйбарәт диван вә «Мәснәви»се күбрәк фарсыча тел белән язылган. Сәлҗукыйләр хөкүмәтләренең соң заманларында гына төрекчә яза башладылар.

Госманлыларда да башда хөкүмәт теле – фарсы иде, соңынтын төрекчә мәйдан алды.

Сәлҗук шагыйрьләрендән Баһаветдин Вәлид, Җәлалетдин Руми тәсаувыф[3] шагыйрьләре иде. Болардан соң тәсаувыф әдәбиятында Гашыйк Паша, Юныс Әмрулла, «Мәүлүд» китабының иясе Сөләйман Чәләби, «Мөхәммәдия» сахибе[4] Язычы углы кебек затлар йитешде.

Госманлы әдәбиятының асыл тәкямел иткән[5] гасыры – уналтынчы гасырдыр. Солтан Сөләйман Кануни дәвере аталган бу дәвердә госманлы гаскәрлеге кебек госманлы шигыре дә әүҗ кәмалгә[6] ирешә. Мәшһүр Фөзули белән Бакый бу дәвердә йитешәләр. Шәех Галиб белән Нәфигый, хыялның биеклегендә Иран шагыйрьләренә ярышрак дәрәҗәгә ирешәләр. Бу шагыйрьләрнең һәммәсе дә тәкия[7], солтанат, тәхет шагыйрьләре: болар шәүкәт[8], газәмәт[9], сәрвәт[10] вә тәсаувыф җырлыйлар...

Госманлыларның Яурупа мәдәнияте белән темасында булган шиддәт[11] колакга ишетелерлек дәрәҗәдә булган рәвешдә ватанпәрвәр Нәмыйк Кәмаллар, гарәб шигырен үзләшдергән шәрык даһисе Габделхак Хәмидләр, асыл тойгылы Мәхмүд Әкрәмләр, сәнгатькәр Тәүфыйк Фикрәтләр йитешделәр.

Госманлы әдәбиятының үзенең дәвре шәүкәтендә[12] тәхте тәсаувыф вә гыйшык тирәсендә әйләнеб сарай әдәбияты булганын Яурупа белән тәмас иткәннең[13] соңында да француз әдәбиятында зоһур иткән[14]

---

[1] Мазыйга – үткәнгә.
[2] Тәмсил итеб – чагыштырып, охшатып.
[3] Тәсаувыф – суфи.
[4] Сахибе – хуҗасы.
[5] Тәкямел иткән – җитешү, төгәлләнү.
[6] Әүҗ кәмалгә – югары ноктасына.
[7] Тәкия – зекер әйтү өчен җыелып утыра торган урын.
[8] Шәүкәт – куәт.
[9] Газәмәт – бөекле.
[10] Сәрвәт – байлык.
[11] Шиддәт – көч.
[12] Дәвре шәүкәтендә – бөеклек дәверендә.
[13] Тәмас иткәннең – бәйләнгәннең.
[14] Зоһур иткән – барлыкка килгән.

һәртөрле әдәби мәсләкләргә тәкълид итеб, мәгънәсендә, ләфызында халыкка һич илтифат итмәгәнен берәр мөнәсәбәт белән бер-ике мәкаләмездә зикер иткән идек. Бу кыска хөласамездә[1] ул җәһәт максуд да түгел.

Безгә турыдан-туры яки тәкълид ителү юлы белән җан азыгы булыб хезмәт иткән чыгтай вә госманлы әдәбиятлары дәүләт, ихтишам[2] вә газәмәт саясенең башындан сыйпаб үстерелгән иркәсе, үсеб җиткәннең соңында аның асравы булганга, боларның язмышы, дәүләтнең күтәрелү вә түбәнләнүе белән бәйләнгән иде: падишаһ кылычын кынына тыгыб, тәхетенә менеб утырганның соңында сөялле кулына кадәх[3] ала, ул никадәр киң өлкәләр фәтех иткән булса[4], сарай әдәбияты да аның кадәхендәге шәрабдә өлкәләренең киңлеге белән мөнәсәбәт төрле рәнекләр[5] күрергә вә тасвир итәргә бурычлыдыр. Падишаһның фәтва хатын мактау өчен, ул әдәбият үзенең кувәи-хыялиясен[6] асманның[7] тирәнлекләренә ашырырга мәҗбүрдер. Сарайларда ямь бетеб, аларга ялгышлар оялый башлагач, сарай вә шәрабнең рухы булган әдәбият тәкия вә ханәка почмакларына сыеныб, ялган гыйшыклар, сахтә[8] тәсаувыфлар җырларга тотына... Ул шунда пыскый!..

Һәм, хакыйкатән, чыгтай вә госманлы әдәбиятларының Тәймүр вә балалары солтан Сөләйман Кануни дәверләрендә әүҗ кәмалга ашканын, соңра дәрвишханәләрдә пыскыб ятканын күрәмез.

Безнең шимальдә корган ике дәүләтемез (Болгар вә Казан дәүләтләре)нең беренчесендән безнең кулымызга хисси әдәбият намына һичбер мәзбут[9] әсәр кичмәде, әсасән[10], икътисадый нигезләргә корылыб, сәясәтдә күб вакыт тәдафгый[11] вазгыять алучан булган бу дәүләтдә сарай әдәбияты туа алмаячак иде, гарәби Асия вә җәнүби Яурупада күзләрне чагылдырган ислам мәгарифе шимальдәге бу почмакга үзенең шөгагъләрен[12] бик зәгыйфь рәвешдә генә, кәкре итеб кенә төшерде...

Казан дәүләтенең сарай тормышы, бигрәк дә соңгы дәверләрендә тәхет интригаларына, сәясәт башбашдакларына оя булганга, анда назик[13] әдәбият нигезләнә алмаячак иде.

Әдәбиятларны сарай тарихы дәверләренең характерлары тудыра, без чыгтай вә госманлы әдәбиятларын җан азыгы итеб кабул вә тәкълид иткәндә дә, алардан үземезгә ошаган төрләрне генә сайладык: без

[1] Хөласамездә – нәтиҗәбездә.
[2] Ихтишам – тантаналы күренеш.
[3] Кадех – бокал.
[4] Фәтех иткән булса – яулап алса
[5] Рәнекләр – төсләр.
[6] Кувәи хыялиясен – хыял куәтен.
[7] Асманның – күкнең.
[8] Сахтә – ялган.
[9] Мәзбут – кулга төшерелгән.
[10] Әсасән – нигездә.
[11] Тәдафгый – дошманга каршы торылган.
[12] Шөгагъләрен – нурларын.
[13] Назик – нәфис.

«Бакырган»ны күңелдән беләмез, «Сөбател-гаҗизин»ләргә шәрехләр баглаб, «Фәзаилеш-шөһүр»ләр язамыз, Галишир Нәваине ишеткәнемез дә юк. «Мөхәммәдия»не бик шәб көйлимез, Фөзулинең «Ләйлә вә Мәҗнүн»ендән ләззәт алмыймыз, Шәмсетдин Суфиларымыз мөтәсаувиф[1] төрек шагыйрьләрен тәкълид итә, Төркиядә Надим исемле сарай вә табигать шагыйре булганы төшемезгә дә кергән юк...

Без рус вә Яурупа мәдәният вә әдәбиятына тәмас иткәнчәгә кадәр госманлы вә чыгтай әдәбиятының дини вә әхлакый кыйсеме безнең мәгънәви ихтыяҗымызны разый кыйлыб, йитешмәгәнлегемезне тутырыб торган, ләкин хисен, зыялы асыл шәрык әдәбияты біздә тәкълид ителеб чәчәк ата алмаган.

Без шигырь вә әдәбиятка сәнгать күзе белән карый алмыймыз, без әдәбиятны эшләтергә, андан файдаланырга, андан мадди файда күрергә тотынамыз. Яңа әдәбиятымызның беренче сәхифәсен тәшкил иткән «Хисаметдин менла» монага кисеб куйган үрнәк.

«Хисаметдин менла» – хәзерге яңа әдәбиятымызның башлангычы.

«Бу китабның басмасына рөхсәт бирелде Питербургда, 30 нчы май 1886 нчы елда».

Бу әсәр хәзерге әдәбиятымызның иң эшлекле әгъзасы булган кадерле Гаяз – «Бидан әсгадек Алла фи әл-дарәйн»[2] диб дәрес башлаган вакытда: «Казан университетының табгыханәсендә басма улынмышдыр!»

«Хисаметдин менла» язылыб басылган вакытда «Сәлимә яки гыйффәт», «Әсма яки гамәл вә җәза» исемле әсәрләргә турыдан туры илһам биргән, хәтта «Шәкерд яки студент»ларга да чаткысын йокдырган. «Дарер-рәхәт мөселманлары» әле мәрхүм Исмәгыйль бәкнең кувәи-хыялиясендә – бәлки эшләнә дә башламаган, яки Шәмсетдин Сами бәкнең кулъязмалары арасында солтан Габделхәмиднең каһәрендән куркыб ята, Кара диңгезнең бу тарафына чыкмаган иде.

«Хисаметдин менла» мөхәррире Акъегетзадә Муса әфәнде рус мәктәбендә тәрбия алган зат булса да, әсәрендән дә аңлаячагымыз үзрә, ул ислам әсәрләрендән дә файдаланган, ислам мәдрәсәләрендә дә тәхсил иткән[3]. Ләкин анда Заһир абзый Бигиевләр, Риза хәзрәтләргә караганда милли хиснең куәтле булганлыгы яки милли тойгының анда иртәрәк яфрак ярганлыгы янә әсәрендән аңланадыр. Анда милли хиснең иртә яфрак яруына бер якдан «Тәрҗеман» сәбәб булган булса, икенче якдан рус мәктәбендәге тәрбиянең гакес[4] тәэсире яки аның Акъегетзадә укыган вакытдагы тәэсирсезлеге сәбәб булгандыр.

«Хисаметдин менла»ның кыз каһарманы Хәнифә туташ – чын татар кызы, хәзерге хокук дәгъва кыла торган татар кызының гәүдәләнгән идеалыдыр. Хәзерге татар кызында чәчәк атыб килә торган тотрыклы ирадә элек әдәби каһарман кыз Хәнифә туташның

[1] Мөтәсаувиф – суфи.

[2] Аллаһ сине ике йортта да бәхетле итсен.

[3] Тәхсил иткән – белем алган.

[4] Гакес – кире.

ләтыйф[1] тамырларында ал кан булыб йөгергән «Хисаметдин менла»да Хәнифә туташ хыялыйлашдырылган күк кызы – әкият кызы түгел, бәлки җир кызы – татар кызыдыр. «Алдым-бирдем»дәге Галия кебек татар кызыдыр.

Хәлбуки, «Сәлимә яки гыйффәт»дәге кыз – каһарман Сәлимә ханым: «хыялыйлашдырылган «ислам» кызыдыр, ул ислам әдәбе, ислам тәрбиясенең гәүдәләндерелгән идеалыдыр.

Менә шул милли, ләкин татар тормышындан алынганлыгы белән «Хисаметдин менла» яңа милли әдәбиятымызда «Сәлимә»ләр, «Әсма»лардан өстен тора да.

«Сәлимә» белән «Хисаметдин менла» – ислам мәдрәсәләрендә озак тәрбия кылынган каләм белән башдан ук Яурупа әдәбиятына тәмас итеб, элек илһамын андан алган ике төрле каләмнең ике төрле мәхсулларыдыр[2].

Мөтәвәффа[3] Ильминский: «Сез, безнең мәктәбемезгә кереб укудан куркасыз, хәлбуки рус мәктәбе Акъегетзадә Муса кебек милли мөхәррирләр, милли кешеләр йитешдерәдер!» – диб, мактаныб сөйләгән.

Яңа әдәбиятымызның утыз ел әүвәлге беренче сәхифәсен ачамыз: «Хисаметдин менла» романының шул ук исемдәге ир каһарманы, Идел буенда «Н» авылында яши. Ул – шул авылда указлы бер имамның баласы. Атасы үлгән, Хисаметдин менла аның урынына имам була алмаган. Төркиядә укыб кайткан бу егет үз өендә хосусый сурәтдә балалар укыта: балаларны ысуле җәдидә белән укытыб, «ике елда» балаларны язу язарга, хат танырга өйрәтә, гыйльме халь, гыйльме хисаб белдерә. Шуның өчен аны авылдагы карт мулла Бикбулат Әхмәдша углы көнли. Аңа дошман була. Хисаметдин менланың тәгассыбка[4] каршы сугыш ачуына сәбәбче була.

Хисаметдин менланы күб кеше яратмый. Ләкин Хисаметдин менланың өендә сабак укыб, тиз вакытда укырга-язарга өйрәнгән балаларның аталары, аңа рәгъбәт куялар[5].

Хисаметдин менла халыкга сүзе белән файда иткән кебек, эше белән дә аңа үрнәк була: кырда үзе иген эшли, кул көче берлән тамак туйдыра.

Хисаметдин менла матур әхлаклы егет: ул дошманларына дошман күзе белән бакмый, аларны җәлли генә.

Аның миллият тойгысы бик кайнар, ул «Тәрҗеман» укыб җылый... «Тәрҗеман» нөсхәләрен сабырсызлык белән көтеб ала.

Хисаметдин менла үз милләтенең әфрады[6] булган татарларны бик ярата, андан кала «иннамә әл-мөэминүнә ихвәтүн» аяте

[1] Ләтыйф – нәфис.
[2] Мәхсулларыдыр – уңышыдыр.
[3] Мөтәвәффа – мәрхүм.
[4] Тәгассыбка – фанатизмга.
[5] Аңа рәгъбәт куялар – аны үрнәккә куялар.
[6] Әфрады – затларыннан.

кәримәсенең мәфһүменчә[1] җөмлә исламлары да үз карендәшләре кеби сөрә иде.

Хисаметдин менла шәһәргә барган вакытда юлда шәһәргә бара торган бер татар гимназисты, аның артындан җитеб, икәү танышалар, гимназист Хисаметдин менланың шөһрәтен күбдән ишетеб йөри икән. Икәү дустлашалар. Киләчәкдә бергә-бергә эш күрәләр.

Хисаметдин менла шәһәрдә бер мөселман мөсафирханәсенә төшә. Мөсафирханәнең ишек алдында: «Урта буйлы, башында Казан калпагы киелмеш, өстендәге йонныкы күк камзулы назик вә зифа буенына яхшы ятышыр, буенында саф көмеш монетлар (тәңкәләр) багланмыш уфак-уфак атлаб кәчән вакытда йомрык вә тагчык шикелле ике күкесенә (имиләренә) акчалары (тәңкәләре) челдер орылыр. Аягында тамбурлы читек башмак, саче вә күзләре вә кашлары ялтыравык кара, йөзе нурлы кызгылт ак, борыны кечкенә вә гүзәл».

Бер кыз күрә. Аның «күзләре бу җәмилийә бакыб зәвыкләнәләр».

Бу кыз – романның кыз каһарманы Хәнифә туташ:

– «Мума иләйһи[2], сахибе мосафирханә[3] кызы гүзәл вә күркәм Хәнифә иде, нигә Аллаһ бөйлә[4] җәмиләләр ярата икән! Хисаметдин менламыз хәйрәтдә калды».

Хәнифә туташ Хисаметдин менланы күреб, оялыб, өенә качыб кереб китә.

Хисаметдин менла мосафирханәгә кереб утыргач, күрше бүлмәдә утырган Хәнифә туташ «тукыб утырган оегын» ташлаб, бер пычак белән Хисаметдин менла утырган бүлмәгә ярык ясаб, аны «багыб хушлана».

– Бондан бөйлә татар бәете хак икән:

– «Ак эшләпә мамыкдан –
Кызлар карый ярыкдан.
Карамаз иде ярыкдан –
Бер күрергә зарыкган».

Хисаметдин менла да ярыкка караб утырган, егет белән кыз бер-беренә гыйшык игълан итәләр, башкалар боларның бер-беренә гыйшык игълан итүен сизмиләр...

Менә Хисаметдин менла белән Хәнифә туташның гыйшыклары шулай башлана.

*«Аң» журналы, 1915 ел, № 9–10*

*Текстны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре* ***Гарипова Ләйлә Шамил кызы*** *әзерләде*

[1] Мәфһүменчә – мәгънәсенә күрә, аңлашылганча.
[2] Мума иләйһи – югарыда сөйләнгән.
[3] Сахибе мосафирханә – кунакханә хуҗасы.
[4] Бөйлә – мондый.

## Э.И. САФИНАНЫҢ «ТАТАРЧА-РУСЧА-ЛАТИНЧА КОШ АТАМАЛАРЫ СҮЗЛЕГЕ» (фәнни редактор: филология фәннәре докторы А.Ә. Тимерханов; бәяләүчеләр: биология фәннәре докторы И.И. Рәхимов, филология фәннәре докторы Ә.Ш. Юсупова. – Казан: ТӘһСИ, 2018. – 184 б.) ТУРЫНДА

Мәгълүм булганча, татар телендә беренче терминологик сүзлекләр XIX гасыр ахырында төзелә башлый. Бу өлкәдә беренче тәҗрибә булып К. Насыйриның «Истиляхате җәгърәфия»се (1890) санала. Бүгенге көндә төрле фән тармакларына караган күп кенә терминологик сүзлекләр дөнья күрде. Аларның бер өлешен биология терминнары сүзлекләре алып тора. Мәсәлән, «Русча-татарча биология терминнары сүзлеге» (Казан, 1972; 1985), «Биологиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек» (Казан, 1998), «Азбука природы: Насекомые: Русско-татарский, татарско-русский словарь биологических терминов» (Казан, 1997), «Азбука природы: Птицы: Русско-татарский, татарско-русский словарь биологических терминов» (Казан, 2001), «Азбука природы: Млекопитающие: Русско-татарский, татарско-русский словарь биологических терминов (Казан, 2001)», «Азбука природы: Рыбы: Русско-татарский, татарско-русский словарь биологических терминов» (Казан, 2001). Бу сүзлекләргә әлеге фәннең төп тармакларына – ботаника, зоология, анатомия, физиология, цитология, биотехнологиягә караган атамалар тупланган. Биология терминнары бүгенге көндә, кайбер тармакларны исәпкә алмаганда, инде формалашкан төгәл системаны хасил итә. Әмма аерым тематик төркемнәрне өйрәнү озак еллар дәвамында эшкәртелеп килгән өлкәләрдә дә төгәлсезлекләр булуын күрсәтә. Шуңа да тармак атамаларын камилләштерүдә, системага салуда терминологик сүзлекләрнең роле бәяләп бетергесез.

Э. Сафинаның «Татарча-русча-латинча кош атамалары сүзлеге» борынгыдан таныш булган һәм телгә яңа кереп килә торган атамаларны теркәве белән генә түгел, ә орнитонимнар системасында булган җитешсезлекләрне ачыклап, берничә кошның бер үк исем белән аталуы, ягъни «атамасызлык» һәм тәрҗемәсез атамаларны куллану мәсьәләләрен хәл итүе белән кыйммәтле. Мәсәлән, элегрәк төрле чыганакларда бер үк атама белән теркәлгән *тиркушка, веретенник, песочник* һәм *тетерев, куропатка* орнитонимнарының татар телендә үз эквивалентлары күрсәтелә: *тиркушка – сакаллы шөлди, веретенник – саз шөлдие, песочник – ком шөлдие, тетерев – озан, урман тавыгы, куропатка – көртлек, кыр тавыгы*. Кайбер алынма терминнар урынына да татарча яңгырашлы атамалар тәкъдим ителә: *деряба – баркылдык, зонотрихия – кәләпүшле чыпчык.* Шунысы әһәмиятле: автор яңа атамаларны сайлаганда татар теленең сүз ясау мөмкинлекләреннән файдаланган, диалектларга, башка төрки телләргә мөрәҗәгать иткән.

Сүзлектә 1700 дән артык орнитоним 255 ояга тупланган. Иң элек төп атама һәм аның рус телендәге эквиваленты күрсәтелгән. Диа-

лекталь атамалар булганда, төп сүздән соң алар да санап кителгән. Аннан ояга алфавит тәртибендә составында әлеге сүз булган башка орнитонимнар теркәлгән, аларның латинчасы бирелгән:

**КАРЛЫГАЧ**, *диал.* айрықойрық (*перм.*), аеркойрык (*гәй.*), кәмәцә (*төм.*, *тбл.*), чәберчек (*нокр.*), қанқарлыйқ (*твр.*), қарлиғач (*перм.*, *тара.*), қарлуғас (*злт.*), қарлуғац (*том.д.*) Ласточка
**КАРЛЫГАЧ КОШЛАР** Ласточковые *Hirundinidae*

**Авыл карлыгачы** Ласточка деревенская *Hirundo rustica*

**Агач карлыгачы, елга карлыгачы** Ласточка древесная, ласточка речная *Tachycineta bicolor*

**Ак маңгайлы карлыгач** Ласточка белолобая *Petrochelidon purrhonota*

Биологик систематикада гомумкабул ителгән латин атамаларын күрсәтү орнитонимнарны төгәлләштерү, системага салу максатына хезмәт итә, чөнки төрле чыганакларда бер үк кошның төрле исем астында теркәлү очраклары күзәтелә.

«Отряд һәм семьялык исемнәре», татар һәм рус телләрендәге төп орнитонимнар исемлекләре, «Татар диалектларында һәм сөйләм телендә кулланылган орнитонимнар» бүлекчәләре сүзлек эчендә сүзлек рәвешендә эшләнгән. Отряд һәм семьялык исемнәрен төп сүзлек өлешеннән тыш аерым бүлекчәдә карау, безнеңчә, үзен аклый. Тикшеренүләргә карганда, татар телендә классификация терминнары өлкәсендә системасызлык күзәтелә. Әлеге терминнарны өстәмә сүзлекчәгә теркәү аларның телдә махсус чаралар белән ясалуын, билгеле бер системада булуларын күрсәтүне максат итә һәм махсус әдәбиятта да дөрес куллануга ярдәм итәр дип көтелә. Диалекталь атамаларны, татар телендәге төп орнитонимнарны аерып бирү дә сүзлек белән эшләүне җиңеләйтә, тел байлыгын ачып бирүгә хезмәт итә. Рус телендәге төп орнитонимнар һәм русча-татарча кош атамалары исемлеге рус телендә сөйләшүче укучыларга да кирәкле атаманың татар телендәге эквивалентын табуны җиңеләйтә. Орнитонимлы сынамышлар, мәкаль-әйтемнәр, канатлы сүзләр сүзлеккә туплаган мәгълүматны милли мәдәни компонент белән баета. Киләчәктә атамаларга аңлатмалар да бирелсә, сүзлекнең кыйммәте, безнеңчә, тагы да артачак.

Э. Сафинаның «Татарча-русча-латинча кош атмалары сүзлеге» уңай бәяләнергә хаклы. Монда бай материал җентекләп тикшерелеп теркәлгән, системага салынган. Ул телчеләр, сүзлекчеләр, тәрҗемәчеләр, укытучылар, биологлар, орнитологлар өчен генә түгел, гади кулланучы өчен дә файдалы һәм мәгълүматлы чыганак булып хезмәт итәчәк.

***Галимова Ольга Николаевна,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

# «ЛАШМАНЫ В СТРОИТЕЛЬСТВЕ РОССИЙСКОГО ФЛОТА: СБОРНИК ДОКУМЕНТОВ И МАТЕРИАЛОВ» (төзүчесе, кереш сүз, искәрмәләр, фәнни-белешмә аппарат авторы И.З. Фәйзрахманов. Казан: ТР ФА нең Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2018, 584 б.) КИТАБЫНА РЕЦЕНЗИЯ

Морзалар һәм йомышлы татарларның корабльләр төзүгә китә торган агач материалы әзерләү һәм аны транспорт юлларына чыгарудан гыйбарәт лашманлык йөкләмәсен (1718–1860) үтәү тарихы Россия историографиясендә бик озак вакытлар аз өйрәнелгән проблемаларның берсе булып кала килде. Асылда исә, аларның Россия хәрби суднолары төзелешенә керткән өлешен бәяләп бетерерлек түгел. Россиянең беренче класслы диңгез державасына әйләнүе, XVIII гасырда – XIX гасырның беренче яртысында рус диңгезчеләренең зур җиңүләргә ирешүе – татар һәм өлешчә (йөкләмә кертелә башлаган чорда) мордва һәм чуваш йомышлыларының авыр хезмәте нәтиҗәсе. Закон актларында һәм ведомстволарның үзара язышкан хатларында аларны немецлар манерына *лашманнар* (урман кисүчеләр) дип исемлиләр.

Соңгы вакытта әлеге теманы өйрәнүдәге бушлыклар акрынлап тутырыла башлады. Төрле авторларның басылып чыккан язмалары аша укучылар казна өчен агач хәзерләүнең үзенчәлекләре белән таныштылар, лашманнарның саны, социаль һәм хокукый статуслары турында гомуми күзаллау булдырдылар, урман кисүчеләрнең хезмәт шартларын һәм эшнең масштабын бәяли алдылар. Шуңа да карамастан, ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты И.З. Фәйзрахманов тарафыннан әзерләнгән документлар һәм материаллар җыентыгын историографик фактлар исемлегендә мөһим вакыйга дип бәяләргә кирәк. Бу җыентык басылып чыкканчы, лашманнар турындагы мәгълүматларны нигездә Россия империясенең тулы законнар җыентыгында, «Рус тарих җәмгыяте җыентыгы»нда, шулай ук революциягә кадәр чыккан һәм һәркем файдалана алмаган басмаларда урын алган аз санлы документларда гына табарга мөмкин иде. И.З. Фәйзрахманов әлеге таркау чыганакларны бергә туплап кына калмады, аларны үзәк һәм төбәк архивлары (Санкт-Петербургтагы Россия дәүләт Хәрби-диңгез флоты һәм Россия дәүләт тарих архивлары, Россия дәүләт борынгы актлар архивы (Мәскәү), Татарстан Республикасы Милли архивы (Казан), Мари Эл Республикасы дәүләт архивы (Йошкар-Ола)) фондларында яткан материаллар исәбенә шактый гына киңәйтте дә. Китапка кергән 182 документның 124 е моңарчы бер җирдә басылмаган булуы әнә шул хакта сөйли.

Җыентыкның композицион төзелеше традицион. Документ текстларына төзүче автор тарафыннан әзерләнгән фәнни белешмәлек, кереш сүз, кирәкле искәрмәләр, географик һәм исемнәр күрсәткечләре,

искергән һәм аз кулланыла торган сүзләр һәм гыйбарәләр сүзлеге, чыганаклар һәм әдәбият исемлеге, җыентыкка кергән документлар исемлеге теркәлгән. Кушымталар (барлыгы 27) басманың аерым бер бүлеген тәшкил итә, аларны шартлы рәвештә өч өлешкә бүләргә мөмкин. Беренче өлешкә лашманнарга багышланган яки алар телгә алынган тарихи язмалар, риваятьләр, шигъри һәм чәчмә әсәрләр кергән. Икенчесендә таблицалар рәвешендә төрле тарихи чорларда урман эшчеләренең административ буйсынулы хәлендәге үзгәрешләрне чагылдырган материаллар, шулай ук алар эшчәнлегенең сан һәм сыйфат характеристикалары бирелгән. Өченче өлешне архив документларының фотокүчермәләре тәшкил итә.

И.З. Фәйзрахмановка татар һәм гомумроссия тарихында лашманчылык феноменын аерым, уникаль үзенчәлекләргә ия күренеш буларак күз алдына китереп бастыру өчен, басмага материаллар эзләгәндә һәм сайлап алганда, гаять зур һәм бик күп көч куюны таләп итә торган эш башкарырга туры килә. Безнең карашка, автор бу катлаулы бурычны уңышлы үтәп чыккан. Китапка 1767 елда Уложение комиссиясенә Казан өязенең Нугай, Җөри, Арча, Алат һәм Галич даругалары йомышлы татарлары наказы («Наказ служилых татар Ногайской, Зюрейской, Арской, Алатской и Галицкой дорог Казанского уезда»), яисә 1817 елгы «Лашманнар турында нигезләмә»нең («Положение о лашманах») кебек билгеле документларның кертелүе дә аклана. Бу – лашманчылык йөкләмәсен тулаем күз алдына китерү өчен кирәк. Моннан тыш, һәркем файдалана алмаган чыганакларны бастырып чыгару татар халкы һәм тулаем Урта Идел буе тарихы белән шөгыльләнәнүче башка тикшеренүчеләрнең дә игътибарын җәлеп итә.

Сайлап алынган документларны фәнни-археографик эшкәртүгә дә ул таләпчән якын килгән. И.З. Фәйзрахманов бүлек башларын да уйлап язган, керештә басманың структурасын да җентекләп дәлилләгән, документ текстларын тапшыру принципларын да ачык бәян иткән.

Әлеге җыентыкның эчтәлеге белән танышкач, аны чыганаклар корпусы дип бәяләргә мөмкин. Әһәмияте ягыннан ул лашманчылык йөкләмәсе тарихы белән генә чикләнеп калмый. Асылда, бу – XVIII гасыр – XIX гасырның беренче яртысында татар җәмгыятенең үзенчәлекле бер кисемтәсе, аның көндәлек тормышының төрле аспектларын комплекслы чагылдыру. Басмада элеккеге татар хәрби-йомышлы аксөякләре вәкилләренең хокукый хәле турында күппланлы мәгълүмат китерелә. Петр I нең корабльләр төзү өчен агач материаллары әзерләүгә теркәү турындагы 1718 ел 31 гыйнвар указы алар өчен рус булмаган халыкларның өстенлекләргә ия катламыннан дәүләт крестьяннарының бер категориясенә әйләнү юлында мөһим этап булып тора. Хокукый нормаларны билгеләгән закон актлары белән бергә, җыентыкта аларның тормышка ашырылуын күрсәткән чыганаклар да урын алган. Китапта лашманнарның һәм казнага урман кисү процессындагы, һәм туган авылларында яшәгән вакыттагы хокук һәм бурычлары ачыкланган.

Чыганакларда халыкның әлеге төркеме белән идарә итү һәм аларның хезмәтен оештыру турында кыйммәтле мәгълүматлар тупланган. Лашманчылыктан кала да өсләренә күпсанлы башка натураль һәм акчалата йөкләмәләр өелгән элеккеге татар йомышлыларының матди хәлләрен яктыртуга да зур игътибар бирелгән. 1724 елда «Бакуга һәм Курага» хәрби ныгытмалар төзелешенә 5000 кешене җибәрү белән бәйле документлар – моның ачык мисалы. Бик күп документлар Адмиралтейство түрәләре һәм җирле хакимиятнең властьтан законсыз файдаланулары һәм урман эшчеләрен җәберләүләре турында сөйли. Бу, барыннан да элек, «Казан губернасы лашманнарының авыр хәлгә төшү» сәбәпләре турында подполковник А.И. Свечинның 1765 елгы «Экстракт»ы. Документларның составы ягыннан шактый зур төркеме лашманнар арасында җир һәм мөлкәт хокукы мөнәсәбәтләренә хас үзенчәлекләрне чагылдыра. Әлеге материалларның кыйммәте шунда, бу өлкәне көйләп торган юридик нормалар бер үк вакытта ясаклы татарларга кагылган. Соңгылары тулаем элеккеге морзалар һәм йомышлы татарлар белән бердәй хокукларга ия булган (турыдан-туры Адмиралтейство эшләре белән бәйләнгән моментлардан кала).

Лашманнар тормышының төп аспектларын ачкан документлар белән бергә, И.З. Фәйзрахманов үзенең хезмәтенә беренче карашка корабльләр төзү йөкләмәсенә турыдан-туры катнашы юк кебек тоелган чыганакларны да керткән. Әмма Адмиралтействога теркәлгән татарлар яшәгән һәм эшләгән тарихи шартларны аңлауда аларның әһәмияте гаять зур. Бу чыганакларда Яңа чукынганнар конторасы бетерелгәннән соңгы вазгыять чагылыш таба (татар халкы императрица Елизавета Петровна идарәсе вакытында урын алган ислам динен эзәрлекләүләрдән арынып, 1740 елларда җимерелгән мәчетләрне яңадан торгыза башлаган заман).

Якын киләчәктә морзалар һәм йомышлы татарлар арасыннан татар сәүдәгәрләренең нигезен тәшкил итәчәк эшлекле кешеләр катламы бүленеп чыгуын раслаучы материаллар да кызыклы. Казанның татар бистәләрендә, шулай ук Казан артының йомышлылар яшәгән авылларында милеккә бәйләнгән катлауларга аерылу һәм капитал туплау процесслары аеруча актив бара. Байлыклары арту татар сәүдәгәрләренә һәм эшмәкәрләргә, акча түләп, лашманчылык йөкләмәсеннән котылырга, үзләре урынына урман кисәргә яллы эшчеләрне җибәрергә мөмкинлек бирә.

Җыентыкта кайбер документларның рус һәм татар телләрендәге вариантлары китерелгән. Алар буенча Казан Адмиралтейство конторасы тәрҗемәчеләренең квалификациясен билгеләү генә түгел, шул замандагы татар теленең үзенчәлекләре, анда Адмиралтейство эшләре белән бәйле терминнарның файдаланылуы турында фикер йөртергә була. Басманың фәнни-белешмә аппараты аерым игътибарга лаек. Төзүче өстәмә һәм аңлату таләп иткән бер генә моментны да күз уңыннан ычкындырмый. Географик һәм исемнәр күрсәткечләре, искергән һәм һәркем файдалана алмаган сүз һәм гыйбарәләр сүзлеге

җентекләп эшкәртелгән һәм дөреслеге тикшерелгән, файдалану өчен уңайлы. Китап белгечләргә генә түгел, ә барлык тарих белән кызыксынучыларга адреслану сәбәпле, бу аеруча мөһим.

Шунысы кызганыч, китапта басмага кергән документларның мәгълүмати потенциалын ачкан аерым мәкалә юк. Ул укучыга авторның төп фикерен яхшырак аңларга, киләчәктәге фәнни эзләнү юнәлешләрен билгеләргә ярдәм итәр иде. Шуңа карамастан, биредәге текстларның мәгълүмати мөмкинлекләре шулкадәр югары ки, аларны бары монографик тикшеренү кысаларында гына тәфсилле рәвештә характерлап булачак.

И.З. Фәйзрахманов тарафыннан әзерләнгән документлар һәм материаллар җыентыгы лашманчылык йөкләмәсе тарихын, татар халкы, Урта Идел буе һәм гомумән Россия тарихын өйрәнүдә яңа мөмкинлекләр ача. Әлеге басма тарихчылар, филологлар, чыганакларны өйрәнүчеләр, туган як тарихы белән кызыксынучы киң катлау укучылар, шул исәптән Россия хәрби-диңгез суднолоры төзелешенең нигезен салышкан морзалар һәм йомышлы татарларның турыдан-туры нәсел дәвамчылары арасында һичшиксез популярлык казаныр.

***Ногманов Айдар Илсур улы,***
*тарих фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге*
*Тарих институтының Татарстан Республикасы халыкларының*
*тарихи-мәдәни мирасы бүлеге мөдире*

## КУБРАТ ХАН ТОКЫМНАРЫ ЯЗМЫШЫН АЧЫКЛАУ

VII гасырның 30 нчы елларында болгар кабиләләре Дуло төрки ыруыннан чыккан Кубрат хан (605 елда туган, Константинопольдә Ираклий сараенда тәрбияләнгән) җитәкчелегендә берләшә. Азак (Азов) һәм Кара диңгез арасында тарихка «Бөек Болгар» исеме белән кереп калган көчле дәүләт төзелә (635 ел). Әмма Кубрат хан вафатыннан соң (665 еллар) әлеге дәүләт таркала.

Тарих дәреслекләре Кубратның биш улының, үз илләре-кабиләләре белән төрле якларга таралуын хәбәр итә. Кара диңгез буе далаларында калган икесе – Баян (Батбаян) һәм Котраг (Византия һәм рус чыганакларында «Кара болгарлар») җитәкләгән кабиләләрнең Хәзәр каһанлыгы кул астына керүе мәгълүм. Соңрак Котраг хәзерге Украина җирләреннән безнең төбәккә килә, Идел буе Болгарын нигезли. Аспарух хан үзенең болгарлары белән 679 ел тирәсендә Дунайга китә һәм биредә Беренче Болгар патшалыгын төзи. Кубратның тагын ике улының Үзәк Европага юл алуы тарихи чыганакларга теркәлгән. Аның берсе – Әлчек Европада маҗарлар дәүләтен (бүгенге Венгрия – Һунгария нигезен) кора.

Тарихта Кубрат хан улларының уңайлы урыннарны ни өчен ташлап китүе, бу хәлнең ничек баруы турында төрле фаразлар яши. Татарстан археологларының маҗар (венгр) археологлары белән республикабыз җирләрендә алып барган казу эшләре, аның нәтиҗәләрен иң соңгы фән технологияләре ярдәмендә тикшереп карау бу «Бөек күчеш»нең маҗарларга караган тарихына кўтелмәгән яңалыклар алып килде.

Әлеге яңалыклар Татарстандагы Алексеевский районы Зур Тигәнәле авылы янында 1974–1984 елларда табылган, Көнбатыш Европадагы иң олы каберлектәге казу эшләре белән бәйләнгән. Бу казу эшләрен төрле елларда Казан галимнәре А.Х. Халиков, Е.А. Халикова, В.Ф. Генинг, Е.П. Казаков җитәкли. Каберлектә 150 кабер барлыгы ачыклана, аларда бик күп сугыш-кирәк яраклары, бизәнү әйберләре, савыт-сабалар, көмеш битлекләр табыла. Әлеге эзләнүләр нәтиҗәсендә А.Х. Халиков, Е.А. Халикованың «Кама һәм Урал буйларында борынгы маҗарлар (Зур Тигәнәле каберлеге)» дигән монографиясе языла һәм 1981 елны алман телендә Венгриядә нәшер ителә.

Мондагы археологик табышларны өйрәнеп, Казан археологы Е.П. Казаков (Татарстан Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институты) Зур Тигәнәле материалларының Кушнаренко һәм Кара-якуп культуралары белән охшашлыгын дәлилли. Маҗар галимнәреннән, бу мәсьәлә белән фән докторлары Иштван Фодор («Маҗарлар: борынгы тарих һәм Ватанны табу» китабының авторы, Венгрия Милли музее директоры, Татарстан Фәннәр академиясенең чит ил әгъзасы), Аттила Төрк (Петер Пазмань исем. Католик университет) һ. б. шөгыльләнә.

Күп кенә фаразлар соңгы елларда ясалган ДНК-экспертизалар, антропологик һәм палеогенетик тикшеренүләр ярдәмендә дәлилләнә.

Шуларга таянып, татар һәм маҗар галимнәре зур ачыш ясый: Европага киткәнче, маҗар кабиләләре Идел-Урал буйларына килеп урнашканнар, монда яшәгәннәр. Тарихи чыганакларда «Magna Hungaria» («Бөек Маҗарстан» яки «Бөек Һунгария») дип аталган, маҗар этносы формалашкан урын Уралдан – Идел-Кама-Агыйдел-Ык буйларына кадәрге зур территорияне биләп торган.

Бу яңалыклар 2018 елның 15–20 октябрендә Казан шәһәрендә уздырылган IV Халыкара Маҗар симпозиумында яңгырады. Венгр галиме Аттила Төрк (Будапешт) – угыр-маҗар темасына кагылышлы археологик һәм фәнни тикшеренүләрнең, татар галиме А.Г. Ситдыйков – 2017–2018 елларда Зур Тигәнәле каберлегендәге казу-разведка эшләренең яңа нәтиҗәләре белән таныштырдылар. Материаллар борынгы маҗарларның матди һәм рухи мәдәнияте, көнкүреше, йолагадәтләре хакында шактый тулы күзаллау булдыра.

***Ситдыйков Айрат Габит улы,***
*тарих фәннәре докторы, Татарстан Республикасы*
*Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы,*
*А.Х. Халиков исемендәге Археология институты директоры*

## КҮЗӘНӘК ЫСУЛЛАР – КЕШЕЛӘРНЕ ДӘВАЛАУДА

Арка миенә зыян килү, шул сәбәпле кешенең йөри алмавы – бүгенге медицина фәнендә иң катлаулы мәсьәләләрдән санала. Аны дәвалауның нәтиҗәле ысулларын эзләү дәвам итә. Әгәр баш һәм арка миләре арасында бәйләнеш өзелмәгән булса, бу очракта экзоскелет һәм нейропротезлар кулланыла. Әмма алар, дәвалаудан бигрәк, авыруга гәүдәсен тотарга ярдәм итүче чаралар булып тора.

Арка мие зыян күргәндә, кеше организмы тиз арада җәрәхәт урынын капларга керешә, бу исә нерв күзәнәкләренә үсәргә мөмкинлек бирми. Шуңа күрә аны дәвалау авырлыклар тудыра.

Хәзерге вакытта дөньяның иң күренекле галимнәре арка мие җәрәхәтләнгәндә, кәүсәр (стволовой) күзәнәкләр һәм ген инженериясе казанышларын кулланып, күзәнәкләрнең сизерлеген торгызу юлларын эзли.

Казан федераль университетының прецизион һәм регенератив медицина фәнни-клиник үзәге базасында профессор, Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы Альберт Ризванов җитәкчелегендә арка мие зарарлануны дәвалау өчен нәтиҗәле һәм зыянсыз күзәнәк дарулары эзләү эше алып барыла. Галимнәр кәүсәр мезенхим күзәнәкләрне күчереп утыртуның зыян күргән урынны дәвалауга һәм нерв күзәнәкләре арасында бәйләнешне тергезүгә йогынтысын күселәрдә сынап карыйлар. Бу вариант уңай нәтиҗәләр күрсәтә.

Казан галимнәре арка миенең җәрәхәтләнүе сәбәпле зыян күрү очрагын сайлап алалар, чөнки бу иң еш очрый торган имгәнү булып санала. Кәүсәр күзәнәкне исә авыруның май катламыннан суыру организмның чит күзәнәкне кабул итмәү мөмкинлеген юкка чыгара, димәк, операциядән соң тернәкләнүне тизләтә. Моннан тыш, кәүсәр күзәнәкләрне арка миенең җәрәхәтләнгән урынына күчерү өчен фибрин матрикс – хирургиядә еш кулланыла торган ябыштыргыч алына. Күзәнәкләрне аппликация кебек итеп җәрәхәткә ябу өчен, өстәмә уколлар яки башка төрле гамәлләр башкару соралмый. Шул рәвешле, авыруның үз мезенхим кәүсәр күзәнәкләрен кабат операция ясаганда күчерергә дә мөмкин.

Ачышның авторлары кәүсәр күзәнәкләрне җәрәхәтләнүгә түгел, бәлки берничә атнадан соң күчерү нәтиҗәлерәк дип саныйлар. Бу да бик мөһим – чөнки җәрәхәтләнгәннән соң ук, зарарланган урынны чистарту өчен оештырыла торган беренче хирургик операция вакытында мондый гамәлләр башкару өчен шартлар булмаска да мөмкин. Шул ук вакытта мондый авырулар еш кына кабат операциягә мохтаҗ була, бу вакытта әлеге технологияне куллану уңай.

Арка мие җәрәхәтләнү кешенең тормышын чикли, аны актив көнкүрештән читтә калдыра. Соңгы ун елда дөньяда барган тикшеренүләр кәүсәр күзәнәкләр белән дәвалау ысулларының, вак җәнлекләрдә (тычканнарда һәм күселәрдә) сынау алып барылган вакытта ук, гадәттән тыш уңай нәтиҗәләргә китерүен күрсәтә. Әмма кешегә күчергәндә, тәҗрибә дәвалау баскычына бик акрын килеп җитә: чөнки әлеге дәвалау ысулының кеше өчен куркынычсызлыгын төрле яклап дәлилләргә кирәк. Моның өчен эре хайваннарда сынау уздыру таләп ителә.

Казан галимнәренең ачышы хәзер дуңгызларда сынау узды. Аның нәтиҗәләре дә, күселәрдәге кебек үк, уңай. Димәк, кешеләрне дәвалауга да килеп җитәренә ышаныч бар.

Ачыш патент белән ныгытылган, бу да арка мие зарарлану очракларын күзәнәкләр ярдәмендә дәвалау ысулының тиз арада клиникаларда файдаланыла башлавына нигез була ала. Дөрес, бүгенге көндә күзәнәк продуктларын файдалану мәсьәләсенең хокукый ягы да әзер түгел әле. Норматив документлар кабул ителүгә, Казан галимнәре ысулны клиника шартларында сынау башлап җибәрергә җыеналар.

***Ризванов Альберт Анатольевич,***
*биология фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы, Казан федераль университеты Фундаменталь медицина һәм биология институты бүлек мөдире*

**2019 елның 2 – 6 июлендә** Казанда Россия антропологлары һәм этнологларының XIII Конгрессы узды.

Конгресс Россия антропологлары һәм этнологлары ассоциациясе тарафыннан Россия Фәннәр академиясенең Н.Н. Миклухо-Маклай исемендәге этнология һәм антропология институты, Казан федераль университеты, Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты белән берлектә оештырылды. Татарстан Республикасы хөкүмәте, Россия Федерациясе Мәгариф һәм югары белем министрлыгы, Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык, Россиянең фундаменталь эзләнүләр фонды чараны оештыруга теләктәшлек итте.

Пленар утырышта һәм 66 юнәлеш буенча оештырылган секцияләрдә Россия Федерациясенең 2025 елга кадәрге чорга исәпләнелгән милли сәясәт буенча дәүләт стратегиясе үтәлеше, милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрнең торышы һәм башка мәсьәләләр каралды.

Чарада Россиядән һәм 20 дән артык илдән хакимият органнары вәкилләре, этнологлар, антропологлар катнашты.

**2019 елның 15 августында** «Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәгендә Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов катнашында Мәгариф һәм фән хезмәткәрләренең республика август киңәшмәсенең пленар утырышы үтте. Агымдагы елда август киңәшмәсе «Белем бирүнең сыйфатын күтәрү факторы буларак тәрбия» темасына багышланды.

Киңәшмәдә Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Россия Федерациясе мәгариф министры урынбасары Ирина Потехина, республика министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләре, муниципаль берәмлекләр башлыклары, эре предприятиеләр вәкилләре, педагогик һәм фәнни җәмәгатьчелек катнашты.

Р.Н. Миңнеханов үзенең чыгышында Россия гомуми белем бирү сыйфаты буенча дөньяның әйдәп баручы 10 иле арасына керсен өчен, Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин тарафыннан җитди бурычлар куелуын, моның глобаль көндәшлеккә сәләтлелекне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәген ассызыклады.

Чара кысаларында мәгариф һәм фән өлкәсендә нәтиҗәле эшчәнлеккә ирешкән хезмәткәрләргә дәүләт һәм тармак бүләкләре тапшырылды.

**2019 елның 23 – 31 августында** Республика көне уңаеннан Казанда «Татарстан киносы атналыгы» оештырылды. Атналык кысаларында «Мир» кинотеатрында Татарстан режиссерлары тарафыннан соңгы ике елда төшерелгән фильмнар киң җәмәгатьчелеккә күрсәтелде.

«Татарстан киносы атналыгы» 23 август көнне Аксенов бакчасында тантаналы рәвештә ачылды. Атна дәвамында Салават Юзиевның «Шиһаб хәзрәт» документаль фильмы, Рамил Фазлыев һәм Әмир Галиәскәровның Туфан Миңнуллин әсәре нигезендә төшерелгән «Мулла» фильмы, «И в шутку, и всерьез» юмористик кыска метражлы телесериалы, Алексей Барыкинның «Водяная» («Су анасы») фильмы, Фәрит Дәүләтшин Рабит Батулланың «Гафу ит, әнием» пьесасы буенча төшергән «Инсаф» фильмы тәкъдим ителде. Шулай ук «Остазбикә» (режиссеры Ренат Кәримов-Сайга), «Отчий дом» (Нәсүр Юрушбаев һәм Әмир Галиәскәров),

«Волчий яр» (Әмир Галиәскәров), «Җиде малай» (Рафил Галимуллин һәм Марсель Мәхмүтов), «Байгал» (Илдар Ягъфәров), «LaPrimavera» (Светлана Серова), җырчы Гөлзада Сафиуллина турында «Сложный узор» (Илшат Рәхимбай), «Әпипә» (Илшат Рәхимбай) фильмнары күрсәтелде.

«Татарстан киносы атналыгы» кысаларында тамашачыларга фильмнарны төшергән иҗади төркем вәкилләре белән аралашу мөмкинлеге дә тудырылды.

**2019 елның 22–27 августында** Казан шәһәре «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча 45 нче дөнья чемпионатын кабул итте. Чара «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәге базасында узды.

WorldSkills International (WSI) чемпионаты эшче һөнәрләрнең дәрәҗәсен арттыру һәм дөньяда һөнәри әзерлек һәм квалификация стандартларын һөнәри осталык буенча конкурслар оештыру һәм уздыру юлы белән үстерүне максат итеп куйган халыкара ассоциация яклавы астында уздырылды.

63 ил һәм төбәктән җыелган 1354 яшь белгеч 56 компетенция буенча ярышты. Аларның эшләрен 1 304 эксперт бәяләде. Төп чемпионат кысаларында тарихта беренче тапкыр 10 яшьтән алып 17 яшькәчә булган мәктәп укучылары арасында WorldSkills Juniors чемпионаты да оештырылды.

Ярымфиналларда һәм финалда катнашу нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына беркетелгән 52 компетенция буенча конкурсантлар 19 алтын, 10 көмеш, 12 бакыр һәм осталык өчен 8 медаль яулады. Финал нәтиҗәләре буенча Россиянең җыелма командасы 22 медаль яулап, икенче урынга лаек булды.

**2019 елның 10 сентябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Татарстанның гыйльми бергәлеге, Россия һәм якын чит илләр тюркологлары, Татарстан Республикасы дәүләт органнары, фәнни һәм фәнни-белем бирү учреждениеләре, Татарстан Язучылар берлеге, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашында Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 80 еллыгы уңаеннан тантаналы чара үтте.

Татарстан Фәннәр академиясе президенты М.Х. Сәләхов, тантананы ачканда, гуманитар профильле институтлар хәзерге заман академик фән системасының төп таянычларыннан берсе булуын ассызыклады. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин Институт юбилеен Татарстан фәне һәм тулаем республика тормышында күренекле вакыйга дип атады. Институт тарихының якты сәхифәләрен берничә буын галимнәрнең хезмәтләре тәшкил итүен билгеләп, ул учреждение хезмәткәрләренең социаль-икътисади һәм иҗтимагый-сәяси тормышның иң авыр чорларында да фәнни эзләнүләрне, татар милләтен саклауга һәм үзен-үзе танып белүгә, халыкның рухи һәм мәдәни яңарышына юнәлтелгән хезмәтләр бастыруын югары бәяләде.

Юбилей уңаеннан Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Л.Р. Фазлыева, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры урынбасары И.Г. Һадиуллин, Азәрбайҗан Милли Фәннәр академиясе вице-президенты, Низами Ганҗәви исемендәге Әдәбият институты директоры, филология фәннәре докторы, академик И.А. Габиббейли, Халыкара төрки академиянең өлкән эксперты Тимур Козырев, А. Байтурсынов исемендәге Тел белеме

институты директоры Е.З. Кажыбек, Л. Гумилев исемендәге Евразия милли университетының казакъ әдәбияты кафедрасы профессоры, филология фәннәре докторы А.Д. Әлтай, Үзбәкстан Фәннәр академиясенең Үзбәк теле, әдәбияты һәм фольклоры институты директоры, филология фәннәре докторы Н.М. Махмудов, Каракалпак гуманитар фәннәр фәнни-тикшеренү институты директоры, филология фәннәре докторы А.И. Әлниязов, Кыргыз Республикасы Милли Фәннәр академиясе Ч. Айтматов исемендәге Тел һәм әдәбият институтының кыргыз әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидаты Н.Т. Ыйсаева, Россия Фәннәр академиясенең А.М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институты әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Т.М. Хаҗиева, Россия Фәннәр академиясе Уфа фәнни үзәгенең Тарих, тел һәм әдәбият институты директоры, география фәннәре докторы А.В. Псянчин һәм Россия Фәннәр академиясе Урал бүлекчәсе Удмурт федераль тикшерену үзәгенең Удмурт тарих, тел һәм әдәбият институты директоры, тарих фәннәре кандидаты И.Л. Поздеев, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисе Д.Х. Салихов котлау сүзләрен җиткерде.

Чара кысаларында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты коллективына, Институт хезмәткәрләренә Татарстан Республикасының дәүләт һәм тармак бүләкләре тапшырылды.

**2019 елның 11 сентябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан «Манеж» күргәзмәләр залында «Милли әдәбиятлар хәзерге этапта: фәнни концепцияләр һәм гипотезалар» дигән темага Түгәрәк өстәл оештырылды. Сөйләшүгә түбәндәге проблематикага караган мәсьәләләр чыгарылды: әдәбиятара үзара бәйләнешләрнең теоретик мәсьәләләре; милли тарихи-әдәби процесс теориясе; хәзерге этапта милли әдәбият белеме: концепцияләр, мәктәпләр, традицияләр, эзләнүләр.

Түгәрәк өстәл эшендә чит илләрдән (Азәрбайҗан, Кыргызстан, Казакъстан), шулай ук Мәскәү, Новосибирск, Йошкар-Ола, Ижау, Казан, Алабуга һ. б. шәһәрләрдән килгән галимнәр катнашты. Чыгыш ясаучылар арасында – Азәрбайҗан Милли Фәннәр академиясе вице-президенты, академик Габиббейли Иса Акпер оглы, Кыргыз Республикасы Милли Фәннәр академиясе Ч. Айтматов исемендәге Тел һәм әдәбият институтының кыргыз әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидаты Ыйсаева Нурзинә Туктарбәк кызы, Л. Гумилев исемендәге Евразия милли университетының казакъ әдәбияты кафедрасы профессоры Әлтай Аманжол Дуйсенбай улы, М.О. Ауэзов исеендәге Әдәбият һәм сәнгать институтының (Казакъстан) аналитика һәм тышкы әдәби бәйләнешләр бүлеге мөдире, филология фәннәре кандидаты, доцент Ананьева Светлана Владимировна, Россия Фәннәр академиясенең А.М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институты әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Хаҗиева Тәнзилә Муса кызы, Казан федераль университеты профессоры Миңнегулов Хатыйп Йосыф улы, Казан федераль университеты профессоры, филология фәннәре докторы Әминева Венера Рудәл кызы һ. б. бар иде.

Чарада шулай ук Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, республиканың фәнни һәм фәнни-белем бирү учреждениеләре, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашты.

**2019 елның 11 – 12 сентябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 80 еллык юбилее уңаеннан «XXI гасыр төрки тел белеме: лексикология һәм лексикография» темасына Халыкара фәнни конференция узды.

Конференция Россия Фәннәр академиясенең Тел белеме институты (Мәскәү) һәм Лингвистик тикшеренүләр институты (Санкт-Петербург) белән берлектә оештырылды.

Чарада чит илләрдән (Азәрбайҗан, Казакъстан, Кыргызстан, Үзбәкстан) һәм Мәскәү, Санкт-Петербург, Новосибирск, Уфа, Чебоксар, Казан, Саранск, Йошкар-Ола, Ижау, Яр Чаллы һ. б. шәһәрләрдән галимнәр катнашты.

Конференция кысаларында «Төрки диалектология, ономастика һәм терминология мәсьәләләре», «Төрки телләр лексикологиясе: лингвокультурологик һәм лингводидактик аспектлар» һәм «Төрки телләр лексикографиясе: актуаль мәсьәләләр, торышы һәм үсеш перспективалары» темаларына секция утырышлары оештырылды.

**2019 елның 11–12 сентябрендә** Казан федераль университеты Халыкара мөнәсәбәтләр институтында «Археолог һәм музей: мәңгелек турында әңгәмә» темасына Бөтенроссия фәнни-гамәли семинары узды. Семинар Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге археология институты һәм Казан федераль университеты Халыкара мөнәсәбәтләр институты тарафыннан Россия тарихи җәмгыятенең «Ватан тарихы» фонды ярдәме белән оештырылды.

Семинар барышында археологик мирасны саклауның актуаль хокукый аспектлары, музейларга археологик коллекцияләрне кабул итү һәм исәпкә алу, археологик предметларны Дәүләт каталогына кертү һәм башка мәсьәләләр турында сүз барды.

Семинарда Россиянең зур музейлары, музей-тыюлыклары хезмәткәрләре, Россия Фәннәр академиясе һәм Татарстан Фәннәр академиясе галимнәре катнашты.

**2019 елның 12 – 13 сентябрендә** Томск шәһәрендә Бөтенроссия татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр форумы оештырылды.

Форумның төп тематикасы милләт үсешендә татар бистәләренең ролен үстерүгә багышланган иде. Пленар утырыштан тыш, шәһәр бистәләре проблемалары, татар бистәләренең яшәеш факторлары һәм һәйкәлләр кую мәсьәләләре буенча секцияләр эшләде. Форум эшендә 200 гә якын кеше, шул исәптән Татарстаннан 50 дән артык вәкил һәм Удмуртия, Мордовия Республикалары, Ульяновск, Свердловск, Чиләбе, Троицк, Магнитогорск, Әстерхан, Курган, Пермь шәһәрләреннән, Төркия, Казакъстан, Үзбәкстан һәм Амстердамнан галимнәр катнашты.

**2019 елның 11 – 14 сентябрендә** тел белеменең актуаль мәсьәләләре буенча Чит телләр институты (Санкт-Петербург) тарафыннан, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән берлектә, «Дөнья тел картинасы» XXXI Халыкара Көзге фәнни мәктәп эше оештырылды. Мәктәп эшендә Россия һәм чит илләрдән фәнни җәмәгатьчелек катнашты.

**2019 елның 18 – 20 сентябрендә** Казанда «Глобальләшү шартларында татар халкының этнодини бердәйлеге» II Халыкара фәнни-

гамәли конференциясе узды. Конференция эшендә этнологлар, этнографлар, социологлар, тарихчылар, ислам, дин белгечләре, политологлар һәм башка белгечләр катнашты. Чараны Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ислам тикшеренүләре үзәге оештырды.

**2019 елның 20 сентябрендә** Габдулла Тукайның әдәби музеенда күренекле шагыйрь, тәрҗемәче һәм җәмәгать эшлеклесе Сәгыйть Сүнчәләйнең тууына 130 ел тулу уңаеннан «Сөй гомерне, сөй халыкны...» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә узды.

Кичәдә Сәгыйть Сүнчәләйнең шигырьләре һәм Габдулла Тукайның Сүнчәләйгә язган хатларыннан өзекләр укылды, аның тормышы һәм иҗаты хакында мәгълүмат бирелде, Сәгыйть Сүнчәләй тарафыннан иҗат ителеп, Татарстан Республикасы Милли музее фондларында саклана торган ноталарның көйләре тәүге тапкыр яңгырады.

Чара кысаларында шагыйрьнең шәхси документлары, якыннарына, дусларына язган хатлары, үзе чыгарган көйләргә язган ноталары, үз кулы белән эшләнгән рәсемнәреннән электрон күргәзмә эшләде. Кичәдә күренекле галимнәр, сәнгать осталары, театр училищесы студентлары катнашты.

**2019 елның 24 – 25 сентябрендә** Казанда VII Мөселман мәгариф оешмалары мөгаллимнәре форумы үтте. Форум эшендә мәчет каршындагы курсларда белем бирүче өч йөзгә якын мөгаллим катнашты. Алар өчен мөселман мәгарифенең башлангыч сегментында мөгаллимлек эшчәнлеген камилләштерү буенча лекцияләр һәм мастер-класслар уздырылды. Спикерлар буларак, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте вәкилләре, Болгар ислам академиясе, Әл-Әзһәр университеты һәм республика мөселман уку йортлары мөгаллимнәре, имам-мөхтәсибләр, казыйлар чыгыш ясады. Башлангыч дини белем бирү, гарәп теле һәм әхлак дәресләрен укыту үзенчәлекләре, җәйге чорда мәчетләр базасында балаларга белем һәм тәрбия бирүне оештыру мәсьәләләре, мәктәпкәчә аудиториядә укыту методикалары һ. б. темаларга лекцияләр укылды.

**2019 елның 24 – 27 сентябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы татар авылларында комплекслы экспедиция оештырылды. Экспедиция вакытында тел, гамәли-декоратив сәнгать, археография буенча материаллар тупланды.

**2019 елның 26 – 27 сентябрендә** Казан федераль университетында «Мультимәдәни дөньяда ислам» IX халыкара форумы узды. Форумда Россия төбәкләреннән, Якын һәм Ерак Көнчыгыш илләреннән ислам белгечләре, Россия һәм Татарстанның хакимият органнары вәкилләре, Россия ислам вузлары һәм мәдрәсәләре вәкилләре, мөселман җәмәгатьчелеге катнашты. Форумны Казан федераль университеты оештырды.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2019. № 3

Бизәлеш авторы – Э. Бәшәрова
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 30.09.2019. Басылды: 23.10.2019.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,5. Тираж 500 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20

Журнал бушлай таратыла